PRESSA

1926–1991 ЕЛЛАРДА **АЗАТ ХАТЫН**



2018 **ИЮНЬ № 6**

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398



БАЛА — БӘГЫРЬДӘ
сүздә түгел, эштә

ЯҢА ПРОЕКТ
әбием сабаклары

ЭЛЬМИРА КӘЛИМУЛЛИНА СЫЙЛЫЙ
кош теле

Рузилә ШӘЙМӘРДАНОВА:

ХЫЯЛЛАР ҺИЧШИКСЕЗ ТОРМЫШКА АША УЛ

Минем өчен син һаман да – 17 дә!..

Минем өчен син һаман да – 17дә!..

Бу фотосурәтләр еракта калган кабатланмас мизгелләргә – Яшьлеккә алып китә... ...Шундый зур галәмдә меңнәр арасыннан бер-береңне эзләп табу – үзе үк могҗиза! Аны күргәч кабынган хисләр – иң саф, иң ихлас, иң садә... Йөрәктәге сагышы да – якты, татлы, моңлы... Беренче очрашу... Аның кебек башка берәү дә юктыр! Дөнья – матур, яшәү шундый рәхәт! Очар өчен канатлар кирәкми дә!.. Ярату, йөрәккә генә сыялмыйча, җанда шигырь булып бөреләнә... Һәм мәңгегә Син – Шагыйрь, Ул Илһамчың булып кала...



Харрас ӘЮПОВ

КЫЗ БАЛА

Карлар эреп бетә бугай инде,
Эх, җанымда бозлар кузгала!
Торналарга зәңгәр яулык болгый,
Йөрәгемә кагылып, кыз бала...

Зәңгәр күктә уйный зәңгәр яулык,
Зәңгәрлектә – торна тавышы,
Сине сагынып, кышны үткәргән ул,
Сине эзләп килә яз кошы.

Зәңгәр юлдан килгән мәхәббәткә
Сузылып-сузылып яулык болгама, –
Китәр өчен түгел бу килүе,
Озатырмын диеп уйлама.

Күңелләрнең актарылган чагы,
Эх, җанымда бозлар кузгала!
Торналарга зәңгәр яулык болгый,
Йөрәгемә кагылып, кыз бала...

Рәсемдә: шагыйрьнең хатыны Люзия ханым. 1968 ел.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2018

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

6’2018



Фото: Ксения Богданова

Җитәкче-баш мөхәррир
Гөлнара Ильяс кызы САБИРОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Рузиля Шәймәрданова
Фото: Ксения Богданова

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Фәнзилә Мостафина
Ландыш Әбүдәрова
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Равил Газизов

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 29.05.2018 ел
Заказ Е-1312
Тираж 5401




Диана Невзорова. 6 яшь. Казан.

Баш мөхәррир сүзе



Җаваплы сәркатибебезнең эш өстәле янында эленеп тора бу рәсем. Бәхетле бала рәсеме, килешерсез. Рәсемдәге бөтен нәрсә елмая; кояш нурларын тамызып кына калмый – яудыра; бал кортының да чиләге тулы. Зебрасы да әллә нинди үзгә, мөлаем, матур һәм ачык. Психологлар баланың күңел халәтен ачу өчен юкка гына рәсем ясатып карамыйлар шул. Бу рәсемне аңлау өчен психолог булырга да кирәкми.

Бүгенге санybызда сез балаларга кагылышлы шактый язма укырсыз. Җәйне дә ничек башлыйбыз бит: 1 июнь – Халыкара балаларны яклау көненнән! Безгә балалар турында сөйләгән ханымнар, чын мәгънәсендә, дөньядагы бөтен баланы үзенекедәй күреп, аларны бәхетле итәргә һәм тормышта үз юлларын табарга булышучылардан. Ә алар колачлап бетерә алмаган, бер җылы сүзгә, әни назына тилмергән сабыйлар күпме?! Кайбер язмышларны ишетәсең дә, йөрәк өзелеп китә. Ә бәхеттән авызы ерылган, ике яктан әти-әнисе җитәкләгән балаларны күрү шундый рәхәт! Аларның һәрберсе – нинди гаиләдә тууына, укуда уңышлары нинди булуына, сәламәтлегенә карамастан, бәхеткә лаек бит! Һәм яратуга лаек! Бәхетле бала – сәламәт киләчәк дигән сүз. Яклап кына калмыйк без аларны, яратыйк...

Гөлнара САБИРОВА



БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА







КОЯШ, ХЫЯЛ, ӨМЕТ БҮЛӘК ИТӘСЕ КИЛӘ!

Эльмира Закирова

16

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ



6



«ИҢ МӨҺИМЕ – БАЛА ХОКУКЛАРЫ»

Ландыш Әбүдәрова

12



«МИНЕМ БЕЛӘН ЭШЛӘВЕ ҖИҢЕЛ ТҮГЕЛДЕР»

Мәдинә Авзалова



10

ОЧАСЫЛАРЫ БАР!

Лилия Гәрәева

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ





22

ГАИЛӘ ӨЧЕН ЯРАТЫЛГАН

Мәдинә Авзалова

ЭЧТӘЛЕК


МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



26

«БЕЗ ЙӨРӘК БЕЛӘН ЯШИБЕЗ БИТ...»
Ландыш Әбүдәрова

32



АХИРӘТЛӘР
Нурания Төхбәтуллина

ЯШӘЕШ 

ХЕЛЬСИНКИ: ГАДИЛЕКТӘ – МАТУРЛЫК
Римма Газизова



48

ШУЛАЙ УК: 

42 БЕЗ ИСӘН ЧАКТА...
Ризидә Гасыймова

46 ТҮЗ, ЙӨРӘК!..
Эльмира Шәрифуллина

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 

61



ЯКТЫ «ТАП»ЛАР КИРӘК

КИЛӘСЕ САННАРЫБЫЗДА: 

КЫЗ БАЛА ЮЛДАН ТАЙПЫЛСА. МАХСУС РЕПОРТАЖ

БАЛА ТӨШЕРҮНЕҢ ГӨНАҺЫСЫ КЕМГӘ: ХАТЫНГАМЫ, ИРГӘМЕ

«ЯРКАНАТ». АСИЯ ЮНЫСОВА. ХИКӘЯ

КАЙНАТМАЛАР ВАКЫТЫ ҖИТТЕ: ЯҢА РЕЦЕПТЛАР



PRESSA

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ

Мәктәпләрдә химия һәм физика лабораторияләре ни хәлдә? Кайбыч, Буа, Югары Ослан, гомумән, Иделнең аръягында бер коррекцион мәктәп тә юк. Ул районнардагы мөмкинлекләре чикләнгән балалар белән нишләргә? Ювеналь технологияләр безгә кирәкме? Инвалид балалар ни өчен параллель дөньяда яши? Эчкече әниләрне гадәти тормышка кайтару күпме тора? Ятимлекнең тамыры кайда? – Балалар дөньясындагы әлеге проблемаларның кайсы беренче урында? Татарстанның Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле Гүзәл Любис кызы УДАЧИНА өчен – боларның һәркайсы көнүзәк мәсьәлә.



Ландыш ӘБҮДӘРОВА

«ИҢ МӨҺИМЕ – БАЛА ХОКУКЛАРЫ»

Бала хокуклары – химия лабораториясендә

Гүзәл Любис кызы мәктәпкә килгәч, иң беренче химия һәм физика лабораторияләренә керә. Кабинетта электр үткәргечләр тырпаеп торганда, балалар физиканы тиешле дәрәҗәдә өйрәнә дип әйтеп булмый. Балалар алдында оят түгелме сезгә, дип оялтырга туры килә андый вакытта, чөнки балаларның уңайлы шартларда белем алырга хокукы бар. Эш мәктәпкә ремонт ясауда гына түгел, ә балаларга карата мөнәсәбәттә. Моның өчен укытучы эш урынында үзен хөрмәт итәргә тиештер...

– Соңгы айларда Әтнә, Саба районнарында булдык. Тегендә дә, монда да алдан уйлаган мәктәпкә кермичә, башка мәктәпләргә керергә туры килде. Беләсезме, директорлар бик куандырды. Аларның мәктәп хуҗалары икәне әллә каян күренеп тора иде: һәр кабинетны күрсәтеп чыктылар, ашханәдә кайда нәрсә ятканын беләләр. Кухняда, мәсәлән, монда ит, монда йомырка, монда ярмалар саклана, дип күрсәтәләр. Бу – мәктәптә тәртип дигәнне аңлата. Кызганыч, шуның капма-каршысын да күргән бар. Югары Ослан, Питрәч районнарында, мәсәлән, уку-укыту процессына карата да, эшне оештыру ягыннан да кисәтүләр күп булды.

Кайбер мәктәпләрдә лабораторияләрне складка әйләндергәннәр: утыртырга дигән суган, кирәк-ярак белән тутырганнар. Без, билгеле, шунда ук чара күрү турында җитәкчелек белән сөйләшәбез. Хикмәт бит акча юклыкта түгел, хикмәт эшкә мөнәсәбәттә. Чиста яшәр өчен өстәмә акча кирәк түгел.

Асрамага түгел, тәрбиягә

Тәрбиягә бала алган гаиләләрнең күпчелеге – гаҗәеп киң күңелле кешеләр. Алар балаларны үзләренеке итеп ярата. Ләкин, кызганыч, бер мичкә балга бер кашык дегет җитә дигәндәй, сирәк кенә булса да мондый хәлләр дә очрый, һәм алар күңелдә кала. Узган ел, мәсәлән, бер гаиләдән җиде баланы кире алырга да туры килә. Балаларны асрамага акча өчен алалар, дигән стереотип фикер дә шундый очраклардан формалаша.

– Андый вакытта мин «Төгәл адресны, фамилияне әйтегез, бүген үк кузгалабыз», – дим. Тәрбиягә бала алган гаиләләрдә балаларны финанслар белән тәэмин итүне дәүләт үз өстенә ала. Моның берниндн гаебе дә юк, билгеле, ул гаиләләр акчаны балалар кирәк-ярагына тота. Ата-аналарның ул акчаларны үз кирәгенә тоткан очраклар булганы юк әле. Кызганыч, быелтыр тәрбиягә бала алган берничә гаиләдә бу җәһәттән бала хокукын бозу очрагына юлыктык. Сүз дә юк, гаеп теге гаиләләрдә, шулай ук монда контрольлек итүче – урындагы опека органының җитәрлек дәрәҗәдә күзәтчелек итеп бетермәвен дә әйтергә кирәк. Нурлат, Спас, Әтнә районнарында прокуратура белән берлектә чаралар күрелде. Опека органнарына тикшерүләр үткәрелде. Опека органнары кая карый?

Әйе, дәүләт бер балага айга 9-10 мең сум күләмендә пособие бирә. Бу акчаны тәрбиягә алган гаилә баланың кирәк-ярагына тотарга хокуклы. Моңа ашау-эчү, киенү кебек көндәлек чыгымнар керә. Инвалид балаларга, әти-әнисез калган ятим балаларга пенсия түләнә. Тәрбиягә алган гаиләдә яшәгән вакытта бу пенсия җыелып бара. Һәм безгә әлеге гаиләләрнең шушы пенсияне дә үз кулларына төшерергә тырышуларын күрергә туры килә. Асылда, пенсия акчасын бары тик бала мәнфәгатьләренә генә тотарга ярый. Өйгә ремонт ясау, веранда корып кую өчен түгел, ә тәгаен балага. Мәсәлән, компьютер яки тун кебек кыйммәтле әйбер сатып алырга була. Ел саен ул гаиләләр февраль аенда хисап тота, хисапка чекларның барысы да теркәлә. Еш кына опека органнарыннан пенсия акчасын баланы дәвалау өчен дип сорыйлар. Алга таба дәвалану турында бер документ та теркәлми. Балигълык яшенә җитмәгән инвалид яки ятим балага нинди түләүле дәвалану таләп ителә? Опека органында эшләүче бала хокукларын яклау буенча белгеч дип атала торган кешенең беренче соравы шул булырга тиеш! Әгәр ата-ана менә шунда-шунда бездән дәвалану өчен акча сорадылар, дип әйтә икән, белгечләр шул хастаханә белән хәлне ачыкларга тиеш, чөнки безнең илдә дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләре балаларга бушлай медицина ярдәме күрсәтә. Мәсәлән, күптән түгел бер гаилә республика балалар клиник хастаханәсендә операция ясату өчен дип 20 мең сум пенсия акчасын ала. Урында ук Казанга шалтыратып хәл иттек: әйе, бала хастаханәдә ятып чыккан, ләкин аннан бер тиен дә акча сорамаганнар.

Видеопаспорт үтемлерәк эшли

Моннан берничә ел элек Гүзәл Любис кызы Балалар йортында Камил исемле малайны күреп ала. Камилгә 3 яшь кенә була әле ул вакытта. «Күңелемә кереп калды бит шул малай. Күз алдыннан китми инде менә. Бик җитди ДЦП белән туган, ләкин яшәүгә теше-тырнагы белән ябышкан. Башка балалар белән өстәл артында утыра иде ул. Һәм үзе ашарга тырыша. Елмая, көлә». Тәрбиячеләр дә шушы яшәү көче өчен ярата икән үзен: ятып кына тора торган булган, 3 яшендә утырырга өйрәнгән. Соңрак – йөрергә...

– Балаларның язмышларына кагылышлы шундый проектлар бар, аларның күбесе безнең башлангыч белән барлыкка килә, һәрхәлдә, андый проектларның финанс ягын хәл итүне сорап, Рөстәм Нургали улына мин барам. Шундый проектларның берсе – «Видеопаспорт» дип атала. Һәм Президент ел саен аны гамәлгә ашыру өчен финанслар бүлеп бирә.

Опека органнарының төп хатасы да шунда: алар түләүле дәвалануга рөхсәт бирәләр.

Видеопаспорт – балалар йортында тәрбияләнүче ятим бала турында 40 минутлык видеофильм. Аның максаты – балаларны гаиләгә урнаштыру буенча эшне көйләү, җайлаштыру. Бала алырга теләүче гаиләләр булачак балалары белән, гадәттә, ничек таныша? Федераль мәгълүмат базасы бар, анда бала турында кыска гына мәгълүмат (кем ул, каян, ничә яшь һәм башкалар) һәм фотография бар. Булачак әти-әниләргә болар гына аз. Шул мәгълүматка таянып, алар булачак балаларын карарга киләләр. Нәрсәдер бирәләр, ә калганын үзләре уйлап бетерәләр. Уенчык алалар, тәмле әйберләр... Киләләр, күрешәләр... Ләкин якыннан танышкач, ялгышуларын аңлыйлар. Ә Балалар йортындагы бала һәрбер яңа кешене булачак әти-әнисе дип кабул итә. Тегеләр киткәч, психотравма кала.

Видеопаспорт менә шушыларны булдырмый калу өчен уйлап чыгарылган проект. Фильмнарны профессионаллар төшерә. Шуннан соң фильм www.videopasport.ru сайтына урнаштырыла. Бу фильмнарны өйдә иркенләп карарга була.

Бүген Татарстан Республикасында 11500 ятим бала бар. Аларның 95 проценты гаиләдә яши. Бездә гаиләгә бала алырга әзер әти-әниләр дә чират тора. Ятимнәр йортларында 500 бала яши. Күпчелегенең сәламәтлекләре буенча җитди проблемалары бар. Алар йә мөмкинлекләре чикләнгән, яки инвалид балалар. Икенче категория – үсмерләр. Яшерен-батырын түгел, андыйлар, гадәттә, социаль гаиләдән. Андый балаларны алырга әзер булмаган әти-әниләрне дә аңлыйбыз. Өченче төркем – гаиләле балалар, ягъни апалы-сеңелле, энеле гаиләләр. Аларны аерасы килми, без андыйлар-

Фото: www.tatar-inform.ru

PRESSA

ның бер гаиләгә китүе ягында. Бүгенге көндә Алабугада бер кыз, алты малай булган искиткеч бер гаилә бар.

Әле 21 майда гына тагын 50 видеопаспорт төшерелеп бетте, быел барлыгы 61 булачак. 2011 елдан башлап, 430 видеопаспорт төшерелде, шулардан 300 дән артык бала гаиләле булды. Җитди күрсәткеч, дип саныйм мин моны. Шулай ук балаларны кире кайтарганнары юк.

Ә иң беренче видеопаспортны Камилгә төшердек. Беренчесеннән үк гаилә табылмады, үсә төшкәч, кабатладык. Һәм, ниһаять, Камил гаиләле булды...

Ач кешегә нәрсә кирәк? Балык бирмә син аңарга, кармак бир!

Аеклык ноктасыннан торып

Моннан өч ел элек Гүзәл Любис кызына «Джонсонс и Джонсонс» компаниясе вәкилләре килеп керә. Алар эчкечелектән дәвалый торган яңа препарат уйлап табулары турында сөйлиләр. Бала хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил: «Нигә миңа килделәр икән болар?» – дип аптырап кала. Бездә, шөкер, эчкечелектән дәваларлык үсмерләр юк әле, дип уйлый. Шунда ук башына шәп идея килә: ятим калу ихтималлыгы булган балаларны саклап калу өчен әниләрен дәваласак?

– 2015 елдан башлап икенче бер проект эшли башлады. Быел өченче этабын башладык. Проект республикада социаль ятимлекне профилактикалауга юнәлгән. Бу бик мөһим, чөнки әти-әнисе үлгән чын ятимнәр әлеге 11500 дән 20 процентка якын. Калган ятимнәр, нигездә, ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгәннәрнең балалары. Күп вакытта ата-ана хокукы эчкечелек аркасында алына. Статистика сөенерлек түгел: бездә эчкече хатын-кызларның саны тотрыклы рәвештә артуы күзәтелә. Ә ул хатын-кызларның балалары бар.

Социаль яктан имин булмаган гаиләләр ведомствоара профилактика зонасына керә: аларны кризистан чыгару, реабилитацияләү һәм аларның балаларын үз гаиләсендә калдыру профилактика субъектларының – опека, мәгариф, сәламәтлек саклау органнары, балигъ булмаган балалар белән эшләр бүлеге, прокуратураның – бурычына керә. Районнарга килгәч, барыбыз бергә җыелып, иң элек реабилитация программасын тикшерәбез.

Әле дүрт ел элек кенә кайбер районнарда, әйтик, соңгы чиккә җитеп эчә торган әниле гаиләгә район газетасын яздыруны профилактика чарасы итеп күрсәтәләр иде. Балаларны 1 сентябрьгә әзерләп җибәргәннәр. Кемгәдер бер тапкыр матди ярдәм күрсәткәннәр. Зур эш эшләдек, дип уйлыйсызмы инде, дим. Иң элек айнытырга кирәк андый әнине! Чөнки хатын-кыз алкоголизмы – куркыныч әйбер, аны җитди кабул итәргә кирәк. Хәтердә: иң беренче Азнакай районыннан «Эчә торган хатыннарны айныта торган нәтиҗәле методика кирәк!» дип килделәр. Чыннан да, инновацион методика кирәк иде, һәм ул табылды. «Аеклык ноктасы» дип атала ул. Аны Сәламәтлек саклау министрлыгы да хуплады. Ярты еллык дәвалану курсы ул, дәваланучы кешенең айга бер тапкыр амбулаториягә килеп укол ясатуыннан һәм 14 сеанс психотерапиядән гыйбарәт. Бер кешене алты ай дәвамында дәвалау 120 мең сумга төшә. Пилот проектны 2015 елда башлап җибәрдек, ул балигъ булмаган балалар эшләре бүлеге канаты астында үтә. Проектның бөтен мәгънәсе – ведомствоара хезмәттәшлектә. Сәламәтлек саклау органнары үз эшен башкарганнан соң, районда профилактик чаралар дәвам иттерелә: әни кешене эчкечелеккә китергән проблемаларны хәл итәргә булышалар. Эшкә урнаштыру, торак белән ярдәм итү, баланы бакчага урнаштыру кебек реаль эшләр турында сүз бара. Менә шунда гына баланы мәктәпкә җыеп җибәрергә булышу урынлы була. Бездә һәрбер районның наркологы балигъ булмаган балалар эшләре буенча комиссия әгъзасы.

Проектны гамәлгә ашыра башлаганчы, пилот районнардан барлык ведомство вәкилләрен җыеп, өч көнлек семинар үткәрдек. Эшне наркология диспансеры булган шәһәрләрдән башладык һәм нәтиҗәдә – 198 бала үз әнисе янында, гаиләдә калды. Ә бит ул әти-әниләр хокукларыннан мәхрүм ителүгә реаль кандидатлар иде. Республикада ел саен меңгә якын ятим бала барлыгы ачыклануын искә алганда, бу сан – яхшы күрсәткеч. Быел проектның бюджеты 9 миллион сум – 70 пациентны алачакбыз, гаиләләре белән эчүчеләр дә бар бит.

Мәсәлән, Яшел Үзәннән өч балалы бер хатынның, әни булу хокукы чикләнеп, балалары приютка билгеләнгән, аларны инде икенче бер гаилә тәрбиягә алган иде. Дәваланганнан соң, балалар әниләренә кайтарылды. Ә бит әни кеше мәктәпне алтын медальгә тәмамлап, югары белем алган булган. Музыкаль белеме дә бар. Ни генә әйтсәң дә, үз әниең үзеңнеке инде ул!

Алар кайда да, балалар кайда?

2010 елда Татарстанда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасы булдырыла. Шул ук елны федераль вәкил Павел Алексеевич Астахов субъектлардагы вәкилләрне I съездга җыя. Ул Европадан балалар омбудсменнары җыеныннан кайткан гына була. Һәм Европа ассоциациясендә күтәрелгән мәсьәләләрне коллегаларына җиткерә: – Күз алдына китерәсезме, Европада гомосексуаль никахларны рәсми рәвештә теркәү мөмкинлеге турында сүз йөртәләр. «Безгә шок булды», – дип искә ала Гүзәл Любис кызы.

– Алай гына да түгел, никахларын теркәгәч, тәрбиягә бала алу мөмкинлеген дә көн кадагына куялар. Ул балаларның хокукларын ничек билгеләп бетермәк кирәк?!

Әле 2010 елларда мондый темаларга сөйләшүне буш сүз итеп кенә кабул итә идек. Әкрен-әкрен безне дә бу күренешне кабул итәргә өйрәтеп яталар. Әле ТВ дә, газета-журналларда мондый темаларга цензура булса, интернетта мәгълүмат чикләнмәгән.

Узган ел вәкаләтле вәкилләргә ЛГБТ тарафыннан үсмерләр арасындагы традицион булмаган ориентацияле балаларга игътибарлырак булу турында мөрәҗәгать килде. Аларны какмасыннар-сукмасыннар диелгән иде

мөрәҗәгатьтә. Шулай итеп, телибезме-теләмибезме, безнең эшчәнлеккә дә килеп кагыла бу җилләр.

Ювеналь технологияләрсез генә

Гүзәл Любис кызы вазыйфасы буенча түгел, ә әни кеше буларак, җыелышта утырганда ишетә бу турыда. Укытучы ханым ышандыра, язып куркыта:
– Суыткычыгызны тикшереп торыгыз: әфлисун бармы анда? Опека органнары килеп тикшерер дә, балагызга әфлисун да ашатмыйсыз икән, дип алып китәр. Аннан соң әйбәт кенә акчаларга икенче бер гаиләгә тәрбиягә бирер.

– Россиядә юстиция ювеналь түгел, ягъни дәүләт Көнбатыштагы кебек күрше сүзенә карап, гаилә эшләренә аяк тибеп кереп тыкшына алмый. Безнең илдәге ятимнәр йортында әйбәт гаиләдә яшәп яткан җиреннән тартып алынган бер бала да юк. Узган ел Мәскәү янында булган резонанслы вакыйгадан соң, без кабат тикшерүләр үткәрдек (анда да балалар гомеренә куркыныч янаган булуы ачыкланды). Россия һәм Татарстан Президентлары кушуы буенча, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил җитәкчелегендә даими эшли торган, балаларны гаиләдән алу практикасын анализлау буенча эш төркеме булдырылды. Без приютларда тәрбияләнүче һәр баланың шәхси эшен өйрәнеп чыктык, һәркайсын күзәтеп торабыз. Узган ел җиде тапкыр шундый хәбәр килде, өчесендә факт расланды. Дөресрәге, балаларны гаиләдән алу кирәк булган, ләкин документлар юридик яктан дөрес итеп рәсмиләштерелмәгән.

Әти-әнисе исән булган баланы социаль приютка яки балалар йортына ике генә орган алып китәргә хокуклы:

– Эчке эшләр министрлыгы, әгәр бала әти-әнисеннән башка үзе генә калса яки әти-әниләре өйдә булмаса, яисә өйдә булып та, баланы карау хәленнән килмәсә (спиртлы эчемлекләр яки наркотик матдәләр куллану аркасында). Бу хәлдә баланы иң элек сырхауханәгә урнаштыралар, кагыйдә буларак, аларны дәваларга кирәк була, аннан соң кая урнаштыру эше хәл ителә;

– Опека һәм попечительлек органнары – асылда, ата-аналарның теләгенә каршы баланы гаиләдән алырга хокуклы булган бердәнбер орган. Гаилә кодексының 77 нче маддәсендә язылганча, «баланың гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч янау очрагы» булганда, опека органы баланы гаиләдә калдыра алмый.

Монда муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты җитәкчесе карары булырга тиеш. Бары тик шушы карар гына законга ярашлы була ала.

Тагын ике очракта баланы приютка урнаштыралар: әни кеше үзе яки бала гариза язганда.

Гап-гади алар, ләкин үзгәрәк

2008 елда Германиягә ике атналык курслар вакытында Россия делегациясен муниципаль балалар бакчасына алып баралар. Капкадан керүгә үк Гүзәл Любис кызы шуңа игътибар итә: коляскалы инвалид бала, Даун синдромлы бала, аның тирәсендә сәламәт балалар – бергәләп сөйләшеп, уйнап йөриләр. Мөдирдән кат-кат сорыйлар: «Без кая килдек? Монда нинди балалар йөри?» Итагатьле итеп кенә җавап бирә мөдир: «Балалар...» Тәрҗемәче сүзгә кушыла: «Сез бу хәлне аңламаган кебек, ул да сезнең сорауны аңламый. Сәламәт балалар белән коляскадагы инвалид балаларның бергә укуы биредә гадәти хәл».

– Кайткач, иҗтимагый палата утырышында шушы инклюзив турында күргәннәрем белән бүлешәм. Безгә дә шундый булырга кирәк, дим. Шунда исеме республикага билгеле бер психиатр табиб мине бүлдерде дә: «Сез ни сөйләгәнегезне аңлыйсызмы? Безнең мәктәпләрдә күзлекле балаларны да кыерсытырга гына торалар, ә сез коляскалы балалар, дисез...»

> *Бездә бит менталитет нинди: берәр гарип бала күрәбез икән, йөрәк тибүеннән туктый!*


Мине бер нәрсә борчый: инвалид балалар һаман да параллель дөньяда яши, алар безне, без аларны күрмибез. Без бер җәмгыять булып яшәргә тиеш, һәм бу безнең өчен гайре табигый булырга тиеш түгел. Юлия Самойлова минем өчен күрсәткеч булды. Безнекеләрнең аны Евровидениегә чыгаруын аңа карата каты бәгырьлелек дип саныйм. Син жәлләмә аны, ярдәм ит! Алар да шундый ук бала, бары тик үзгәрәк кенә. Юлиягә дә шундый ук мөнәсәбәт булыр дип уйладылар, ахрысы. Берәр бәйгедә гарип бала катнаша икән, жюри бездә эреп төшә. Көнбатышта исә күптән объектив бәялиләр.

2013 елда безнең илдә Инвалид балалар хокуклары буенча халыкара конвенциягә кушылды. Шуннан бирле, без инклюзив турында һәрдаим һәрбер районда тукып торабыз, чөнки инклюзив белем бирү турында федераль закон да бар. Инвалид баланың әти-әнисе үзе яшәгән районда мәктәпкә килә дә баласын укырга алуларын сорап гариза яза. Белем бирү учреждениесенең гаризаны кире кагарга хокукы юк. Шул ук вакытта мәктәп бу балага укырлык шартлар да тудырырга, махсус программа буенча укытырга тиеш.

Бездә мондый балалар, шул исәптән, акыл ягыннан зәгыйфьләр дә, күпчелек махсус коррекцион мәктәптә укый. Андый мәктәпләр безнең республикада бүгенге көндә – 52. Тәтеш, Югары Ослан, Кама Тамагы, Буа, Кайбыч – Идел аръягында бер коррекцион мәктәп тә юк. Андагы инвалид балалар кайда укый? Өйләреннән еракта яки бөтенләй укымыйлар. Яисә башка балалар белән бер шартларда укып, БДИ бирә алмыйча, мәктәптән белешмә белән чыгалар да шуның белән вәссәлам. Алга таба һөнәр дә үзләштерми, эш тә таба алмый.

Ә махсус методика буенча укытканда, аларга һөнәр бирергә, җәмгыятькә кирәкле кеше итеп яшәвен тәэмин итәргә була. Алар менә дигән балта остасы, урманчы, тегүче, ашчы, буяучы булалар. Һөнәрле булгач, эшли дә, гаилә дә кора, балалар да үстерә алалар.

PRESSA



ОЧАСЫЛАРЫ БАР!

Дөньядагы иң көчле ярату – әнинең баласын яратуыдыр, мөгаен. Аның хакына әллә ниләр корбан итәргә әзер ул. Кодрәтеннән килсә, сабыен йөрәгенә генә куеп, тормышның бар авырлыгыннан йолып калыр иде. Ә менә шул иң көчле хиснең дә чикләре бармы? Гомумән, яратуга чикләр кирәкме?
«Башыңа ки! Алайса беркая чыкмыйсың!» «Башта аша!» «Ник соң кайттың?»
Без – әниләрнең еш кабатлый торган сүзләредер инде бу. Без дә кайгыртмасак, кем кайгыртыр балаларыбызны? Ләкин шулкадәр өзгәләнүебез кирәкме соң аларга? Җитеп килгән ул-кызларыгыздан сорагыз әле, күбесе «юк» дип әйтәчәк. Гиперопека соң чиктә аның тормышын бозарга ук мөмкин. Гаилә кора алмый йөргән егетләр, утызга җитсә дә әниләренең бәбие булган кызлар – күбесенчә шул гиперопека корбаннары. Биология фәннәре кандидаты, доцент, психолог Саҗидә РУСИНОВА чамадан тыш опека турында сөйләшкәнче, башта аның башлангыч ноктасын һәм нормаларын билгеләргә тәкъдим итә. Сүзне галимәнең үзенә бирик.

Дөрес итеп тәрбияләгәндә, бала тормышындагы һәр этап – аның билгеле бер тәҗрибәгә ирешүе. Артык кайгыртып, без аңа бу тәҗрибәне үзләштерергә комачаулыйбыз. Соңыннан ярдәмгә мохтаҗ, инициативасыз, китереп биргәннәрен көтеп яткан кеше формалашуына аптырыйсы юк.

Нәрсә соң ул опека? Ул – булышу һәм кирәкле ярдәмне күрсәтү.

Кайгыртуның чиге баланың яшенә карап билгеләнә. Әйтик, күкрәк баласы өчен опеканың артыгы буламы? Без аны вакытында ашатып, карап-тәрбияләп торырга тиеш. Бер яше тулганчы ул кайгыртуыбызга бик тә мохтаҗ әле. Әмма монда да артыгын кайгыртып җибәреп, туңмасын дип, бүлмәне эсселәтү, калын киендерү; салкын тияр дип, саф һавадан мәхрүм итү балага зыян гына китерә.

1 яшьтән 3 яшькә кадәр баланың физик интеллекты формалаша. Ул күп хәрәкәтләнә, әйләнә-тирә белән таныша. Әгәр дә шушы вакытта, егылыр, бәрелер, дип, аны кирәгеннән артык кайгыртып, иреген чиклибез икән, баланың физик интеллектына зыян китерәбез. Ә физик интеллектның тиешенчә формалашмавы психикага тәэсир итә.

Мин әниләрне аңлыйм, хәтта бераз яклыйм да. Аларга эшләргә, тормышны кайгыртырга кирәк, баланы манежга да утыртырга туры килгәли, хәтта бәйләп тә куярга (авылда элек баланы өстәл аягына бәйләп калдыру шул чарасызлыктан булган бит инде). Әйе, ул анда азмы-күпме хәрәкәтләнер, физик интеллектын берникадәр үстерер дә, ләкин бу аның психикасы өчен эзсез узмас. Бөтен кеше йөри, бер аның ирегенчиклиләр. Мондый халәт озакка китсә, балада үзен ким сизү хисе барлыкка килә. Бу очракта «нишләргә соң?» дигән сорауны әлегә күтәрмибез. Бала караган әнине эшләргә мәҗбүр итмәү дәүләт сәясәте чикләренә үк кереп китә.

Шушы урында фил турында бер кыйсса сөйлим әле. Зур филнең

аягын нечкә бау белән тышаулап куйганнар. Моны күргәннәр аптырый: «Бу бауны өзү аңа берни дә түгел бит. Ник өзми икән?» Ә җавап гади генә – ул кечкенәдән шушы бауга бәйләнгән булганга хәзер аны өзә алуын белми дә.

Ирекне чикләү агрессив негатив уята. Бала табигатьтән бирелгән дөрес фәрманга – ирекле булу фәрманына буйсына. Ул ирек артында нәрсә булуын, нинди куркынычлар сагалавын без беләбез, ә бала әле аны белми.

Еш кына нәрсә соң ул бәхет, дип сорыйлар. Бәхет ул – әйләнә-тирә мохиткә һәм шушы мохит эчендә үзеңә эмоциональ бәя бирү.

Бәхет өчен эмоциональ интеллект (аны икенче төрле психик интеллект та диләр) җавап бирә. Ул балага яшь ярым булганда формалаша башлый. 2 яшьлек бала бәхет хисен инде бик шәп тоя. Шушы вакытта күрсәтелгән чамасыз опека балага бәхет төшенчәсен дөрес кабул итәргә комачаулый. Бәхетнең аңлатмалары күп аның. Шуларның берсе – тирә-юньдәгеләргә зыян китерми генә үз ирегеңне тою. Ирегеңне тою! Һәм синең ирегеңне башкаларның да тануы!

3 яшьтә балалар үзләренә нәрсә ярый, нәрсә ярамаганын өйрәнә. Ирекнең чикләре барлыкка килә. Бу чорда социаль интеллект формалаша. Социаль интеллект ул – җәмгыятьтә ирешкән уңышларның нигезе. Башкалар белән аралашырга, дуслашырга, мөнәсәбәтләр корырга өйрәнүе – баланың социумдагы тәүге тәҗрибәсе.

5 яшенә ул инде үзе өчен социаль кысаларны ачыклап бетерә. Бу яшьтә бала үзенең тәртибен көйли. Әлеге чорда бала сүз тыңламаучанга әверелә. Аның һәрнәрсәне үзенчә эшләп карыйсы килә. Бу – дөрес, ул нәкъ шундый булырга тиеш. Үзебезгә буйсынуын таләп итсәк, башкалар сүзенә карап эш йөртүче кеше үстерәчәкбез. Тормыш юлында аңа дөрес юл гына күрсәтүчеләр очрар дигән гарантия бармы?

Дөрес итеп тәрбияләнгән очракта 5 яшьлек баланың һәм физик, һәм психик, һәм социаль, һәм рациональ интеллекты (баскычтан йөгереп төшсә, егылырга мөмкин икәнен белә ул хәзер) формалашкан була инде.

6 яшендә балада мөстәкыйльлек барлыкка килә, тирә-ягына карарга, чагыштырырга өйрәнә. Бу яшьтә аны куәтләп, дөрес юнәлешкә турылап торырга кирәк. «Син дөрес эшләмисең, алай кирәкми» дигән формада түгел, «Үзең ничек уйлыйсың соң?» – дип, киңәшләшү рәвешендә барырга тиеш тәрбия.

8 яшендә иҗади интеллект формалаша башлый. Бу вакытта иҗади ирек бирергә кирәк. Җырларга тели икән – кулыннан тотмагыз (гәрчә аны җырлый белми дип санасагыз да). Бала үз проблемаларын үзе хәл итәргә өйрәнә, үзенә ышаныч барлыкка килә, курку хисе бетә.

9 яшендә берникадәр пауза булып ала. Әлегә кадәр бала белән янәшә барган булсагыз, хәзер бер адымга арттарак барырга тиешсез. Үзе уйласын, үзе хәл итәргә өйрәнсен. Бу яшьтә баланың иреген никадәр ныграк чикләсәң, аның киләчәктә бәхетле булыр өчен шанслары да шуның кадәр үк кими.

10 яшендә әхлаклылык принциплары алга чыга. Шушы яшьләрдә инде «синең белән дус, аның белән дус түгел»ләр башлана – әхлакый интеллект формалаша. Күп галимнәр аны социаль интеллектның бер өлеше итеп карый, тик мин аны нәкъ менә әхлакый дип атар идем. Баланың бу этапларны узуы – тәрбиянең дөрес булуын сөйли.

Әгәр дә тәрбия дөрес булмаса? Балага 12–14 яшендә табигать безгә ул хатаны төзәтергә тагын бер шанс бирә әле. Ул бу яшенә кадәр ала алмаган тәҗрибәсен шушы ике елда үзләштерергә сәләтле. 14 яшеннән соң кешенең баш миен «төзәтү» инде мөмкин түгел. Бала чагында артык тыңлаучан булган һәм социумда үзен ничек тотарга кирәген өйрәнә алмаган балалар, гадәттә, яшүсмерлек чорында «бәйдән ычкына».

Бу яшьтә әти-әниләр ярдәм сорап еш мөрәҗәгать итә миңа. Бер мисал: егет 9 нчы сыйныфта укый. Мәктәпкә барганда – бара, бармаганда – юк. Баланы мәктәпкә озатып йөрү өчен әти-әнисе кеше яллаган. «Сез аны дуслары алдында хур итәсез бит, – дим. – Аның бу яшенә җитеп, вазыйфаларын белмәвенә үзегез гаепле!» Гиперопека – тәрбияләү түгел, ул – баланың канатларын «кисү». Күбәләк курчагын искә төшерегез. Берзаман аңа кабыгыннан чыгар вакыт җитә. Бик авырлык белән, көч куеп чыга ул аннан. Әгәр дә шул вакытта күбәләкне кызганып, кабыгыннан тизрәк арынырга ярдәм итәсең икән, ул инде беркайчан да оча алмаячак. Кабыгыннан көчәнеп чыкканда гына аның канатлары очарлык булып ныгып җитә. Гыйбрәт алам дигән әти-әни өчен бик яхшы мисал.

Баланың үз-үзен тотышындагы чатаклык – ул тәрбиядәге чатаклык.

Икенче бер мисал: баланың «өчле»гә генә булса да укырлык мөмкинлеге бар. Ләкин тырышмый, укымый. Аның начар укуында әнисе укытучыларны гаепли, алар белән инде тәмам ызгышып беткән. Мондый әнисе барында ник укысын ул. Аның бөтен проблемасын әнисе хәл итеп бирәчәк бит. Ана кеше укытучылар, күршеләр, туганнар белән ызгышып, үз вазыйфасының бер өлешен аларга йөкләмәкче.

Нигә читләтеп торырга, баланы чамасыз кайгырту ул безнең үзебез өчен кулай. Безнең үзебезгә шулай җайлырак. Аның белән шөгыльләнергә вакыт юк – манежга утыртабыз. Ишегалдындагы комлыкта күзенә ком сибәрләр тагын дип, аннан тизрәк алып китү җаен карыйбыз. Аның янына утырып, дәрес әзерләшәбез, үзе эшләсә, хата җибәрер, «ике»ле алыр, безгә ояты булыр...

Аның да, күбәләккә әверелеп, көннәрдән бер көнне очасы барын гына онытабыз.

Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.

PRESSA




Фото: Ксения Богданова

БӘЛКЕМ, ХЕЗМӘТТӘШЛӘРЕНӘ АРТЫК КЫРЫС, АРТЫК ТАЛӘПЧӘНДЕР УЛ. ӘММА МЕДИЦИНАДА «АГАЙ-ЭНЕ, АК МЫЕК» ДИГӘН НӘРСӘ БУЛА АЛМЫЙ.

Мәдинә АВЗАЛОВА

«МИНЕМ БЕЛӘН ЭШЛӘВЕ ҖИҢЕЛ ТҮГЕЛДЕР»

Аның белән очрашуга без, көн кичкә авышкач, эш сәгате бетеп килгәндә җыена башладык. Җитәкче кешенең эше беркайчан бетмәс, ә сүзе кыска булыр. Шуңа әзерләнеп, «дилбегәбезне» кысыбрак тотып бардык. Эш бүлмәсенә кадәр озата барган ак халатлы мөлаем кызлар: «Кырыс та ул, таләпчән дә, гадел дә... Аннан башка эш тә бармый», – дип көлешеп озатып калдылар.

Казанның 12 нче клиник хастаханәсенә беренче генә килүем түгел. «Кырыс, таләпчән» начмед белән дә беренче генә күрешүебез түгел. Сүзен: «Нәрсә сөйләргә дә белмим», – дип башлаган Вәсилә Зөфәр кызы Һадиева белән сәгатьләр буе барган әңгәмәдән барыбызга да сабак булырдай нәтиҗә ясыйм. Ләкин бу хакта бераз соңрак...

«Китәргә дип килмәдем»

...Шулай инде, һәркемнең күңелендә үзе генә белгән һәм беркемгә дә белдерәсе килмәгән, дөньяга чәчеп, кадерен-тәмен югалтасы килмәгән серләр була. Озак еллар аны түкми-чәчми саклап йөрисең. Ләкин көннәрдән бер көнне ул сине тынгысызлый башлый: аның иреккә чыгасы, күкләргә очасы килә. Башкача әйткәндә, бервүнең дә сандыгы буш түгел. Ул сандык та бер ачылып китә. Ул үзенең шушы хастаханәне дер селкетеп тотучы җитәкче булуын, ә мин исә үземнең бирегә

нинди максат белән килүемне беразга онытып, үткәннәр турында сөйләшәбез. Күптән күрешмәгән ике якын кеше шикелле бер-беребезгә ачылабыз.

Бер уйлаганда, тормыштан бер дә читкә тайпылмаган, гел дөрес юлдан барган, кем әйтмешли, закон кушканча гына яшәгән кешеләр турында язуы авыр, аннары кызык та түгел. Һәрхәлдә, мин шулай уйлый торган идем. Юк икән, алай түгел икән. Туган ягым Кукмара белән җитәкләшеп диярлек утырган Саба районы кызы иллеләп кенә хуҗалыгы булган кечкенә генә Теньки авылында туган. Аннан күп балалы Һадиевлар гаиләсе район үзәгенә күченә. Шунда безнең кызыбыз урта мәктәпне «бишле» билгеләренә генә тәмамлый. Ләкин адәм баласын язмыш гел кулыннан җитәкләп кенә йөртми. Сынар өчен, ара-тирә, төпкелгә дә ыргытып карый. Вәсилә дә ул сынауны читләтеп үтә алмый. Аягына әйбер төшеп, имтиханнар барганда, урын өстенә кала.

– Хастаханәдә ай ярымлап ятканмындыр, – ди әңгәмәдәшем, ул вакытларны искә төшереп. – Имтиханнарга култык таягына таянып йөрдем.

Ул чагында авыл баласының өч хыялы: йә укытучы булу, йә табиб, йә бухгалтер... Хастаханәдә ятып, институтка керер вакыт инде узган. Туганнары кызның документларын Арча педагогика училищесына илтеп тапшыралар. Әлбәттә инде, уку отличнигын укырга алалар. Вәсилә уйлана кала. Шул идеме аның хыялы? Теләге башка иде бит: авыруларны дәвалыйсы килә. Шулай итеп, Вәсилә медицина училищесына барып керә. Очып кына узган ике ел аның өчен төш кенә... Дипломлы шәфкать туташын, группадаш кызлары белән бергә, Казан шәһәренең Авиатөзелеш районында урнашкан 12 нче клиник хастаханәгә эшкә җибәрәләр.

– Хастаханәнең кайда икәнен дә белми идем, – дип дәвам итә сүзен Вәсилә Зөфәр кызы. – Бер иптәш кызым китереп куйды.

Күк төсендәге зәңгәр ефәк күлмәк кигән зифа буйлы, чибәр кызны күргәч, кадрлар бүлеге хезмәткәре бер генә сүз әйтә: «Озак эшләмәс, мондый кызлар бездә тоткарланмый».

Их-х, белсә иде ул сүзен сүз итмичә калмый торган үҗәт кызга куелган диагнозның никадәрле ялгыш булуын. «Китәргә дип килмәдем», – ди кыз. Һәм бу сүзләр тора-бара тормыш мәгънәсенә әверелә.

– Августта килгәнемә 36 ел була, – ди нәнә, күңеленә уелып калган ерактагы якын мизгелләрне янә күз алдыннан кичерә башлап әңгәмәдәшем.

Әнисе Тәскирә апа янына кунакка кайткан бер чагында, бәлкем, шул турыда сүз чыккандыр: «Әнә гәҗиттә укырга чакыралар анда. Институтка бар, белемең җитмәсә», – ди әнисе. Кистереп әйтә. Сигез кыз тәрбияләп үстергән ана балалары белән ничек сөйләшергә кирәклеген генә белә анысы. Өйрәтеп торасы юк. Бу сүзләр Вәсилә өчен боерык булып та яңгырагандыр, бәлки. Ихтимал, шулай булгандыр. Аннары... аның җитәкчесе – ул чагында ук инде республикада танылган баш табиб Тәүфыйк Фәтхерахман улы Сафин да шуны әйтеп тора: «Укырга кирәк сиңа», – ди.

Димәк, укырга!

– Кереп карыйм, – дип кенә барган идем, – бөтен фәннәрне дә «бишле»гә биреп, Казан дәүләт медицина институтының кичке бүлегенә – дәвалау факультетына барып кердем. Укуы җиңел булды, дип әйтә алмыйм. Миңа бит, укыгач-укыгач, гел «бишле» булсын! Укуны да, эшне дә аннан-моннан гына үтәргә күнекмәгән. Мине шулай өйрәттеләр.

– Эштән киттегез инде...

– Юк, китмәдем. Көндез эшлим, кичен укыйм. Өч ел укыгач, көндезгегә күчерделәр. Хәзер инде көндез укыйм, төнлә эшлим. Уйлыйм-уйлыйм да, хәйраннар калам. Иң авыры автобуста йөрү булган. Ул заманнарда автобуслар начар йөри иде бит. Бигрәк тә безгә кирәкле 56 нчы автобус. Бер сумка китаплар белән башта – институтка, аннан соң – хастаханәгә, аннан – тагын институтка... Төнлә укып булмасмы дип, китапларны иптәш кызым белән алып киләбез дә, кире алып китәбез. Эштә кая вакыт булсын инде?! Тулай торакның без яшәгән бүлмәсе китапханәне хәтерләтә иде: идәндә – китаплар, өстәлдә – китаплар, стенада – искәрмәләр... Шулай укыдык...

Институтны да Вәсилә Һадиева кызыл дипломга тәмамлый. Таныш-белешләре аңа хастаханәдән китәргә киңәш итә: «Сиңа ул коллективта күтәрелергә авыр булыр, саннамаслар», – дип әйтәләр. Ә Вәсилә кала. Әлеге дә баягы... китәргә дип килмәде ич ул.

> *«Үзем шелтә-кисәтүләрне авыр кичерәм. Шуңа һәр эшне җиренә җиткереп үтәргә тырышам».*

Аның эш кагыйдәсе

Әле өлкән шәфкать туташы булып эшләгән чагында ук, үз кул астындагы артык иркенәеп, «азынып» киткән кызларны бик тиз акылга утырта торган иде ул. Табиб кадәр табибны санламаган шәфкать туташын: «Ул – дипломлы, югары белемле белгеч. Аның белән беррәттән буласың килсә, институтка кер, бер кешегә дә ишекләр ябылмаган», – дип, катгый итеп кисәтергә дә күп сорап тормый иде. Шәфкать туташы белән табиб арасында субординация сакланырга тиеш!

«Белем җитеп бетми», – дип, башта интернатураны, аннары ординатураны тәмамлый. Ул арада кардиология бүлегендә эшләп ала. Бераздан иң җитди, иң җаваплы бүлекләрнең берсе булган интенсив терапиягә күчә. Һәрьяклап белем туплый. Гомереңне шул эшкә багышлагансың икән, артка әйләнеп карарга хакың юк. Медицинадагыча: гел алга, бер урында таптану, синең күзеңә карап, ярдәм, өмет итеп яткан авыруның гомеренә тиң. Пафослы яңгыраса да, бу шулай! Ак халатлы һөнәр ияләре өчен Гиппократ анты шул инде ул...

2007 елның 1 гыйнварыннан аны – инде хәзер зур тәҗрибә туплаган, гади булмаган коллектив белән уртак тел табарга, кайда камчылап, кайда үгетләп, кайда аңла-

PRESSA

тып, тапшырылган вазыйфаны тиешенчә, кирәгенчә үтәргә күндергән, өйрәткән Вәсилә Һадиеваны «начмед» итеп билгелиләр. Һәм ялгышмыйлар. Төрле чак булгандыр, тик ул беркайчан да үз принцибыннан, үзенең эш кагыйдәләреннән тайпылмый. Хәтта коллегаларының нинди аяк киеменнән йөрүе дә бик мөһим аның өчен. Чиста халат, ялт итеп торган аяк киеменнән булсыннар. Ә иң мөһиме: авырулардан шикаять булмасын.

«Сезнең адреска шикаятьләр булдымы?» Соравыма шактый вакыт уйланып тора. Әйтергәме, әйтмәскәме... Хәер, нигә әйтмәскә?! Башкалар өчен дә сабак булыр.

Бу хастаханәнең язылмаган үз кагыйдәсе: авырудан, әгәр ул шуны тели икән, хаклымы ул, юкмы, гафу үтенәсе...

Ришвәтчелеккә каршы

– 36 ел эшләү дәверемдә бер мәртәбә булды шундый хәл. Кардиология бүлеге мөдире булып эшләгән чагым. Дәваланып өенә кайтырга җыенган бер әби миңа конфет керткән. «Әби җаным, рәхмәт. Кайткач, үзең чәй эчәрсең», – дим. Алмадым, билгеле. Гомергә авырулардан, гомумән, беркемнән дә ришвәт алганым юк. Әбием тәмам үпкәләгән, күрәсең. «Бер хатыннан чиләк белән җиләк алды. Миннән алмады», – ди икән бу. Өенә кайткач, улына да шулай дигән. Ә тегесе шундук баш табиб исеменә шикаять сипләгән. Баш табиб чакыртты да: «Әбинең өенә бар, мәсьәләне хәл итеп кайт», – дип, каты гына әйтеп чыгарып җибәрде. Авыр булды, чөнки бер гаебем юк... Эзләп киттем әбине. Таптым. Ишекне бөтен тәне җөй белән капланган таза гәүдәле бер ир ачты. Куркып киттем. Ул әбинең улы булып чыкты. Әбидән гафу үтендем. «Чиләк белән җиләк биргән кеше минем хезмәттәшем, дустым», – дип акланып та маташтым әле... Соңыннан бергәләшеп утырып чәй дә эчтек.

«Минем белән эшләргә җиңел түгелдер», – дип сөйләсә дә, аның беркайчан да хезмәттәшләрен ут астына керткәне, авыр хәлдә калдырганы булмый. Киресенчә, ул фронтның алгы сызыгындагыча: авырлыкны һәрчак үз өстенә ала. Моңа мисаллар җитәрлек. Авырулар белән аңлашылмаучанлык, низаглар килеп чыкканда, бүген ул инде үзе табибларны өйләренә җибәрә. Сүз уңаеннан, Вәсилә Зөфәр кызы янә шундый бер очракны хәтергә төшереп ала: «Бервакыт бот сөяге сынган олы яшьтәге ханымны алып килделәр. Авыртуны баса торган дарулар биргәннән соң, өенә кайтарып җибәрдек. (Ул вакытта бездә әле андый катлаулы операцияләр ясалмый иде. Хәзер ясыйбыз.) Ә хатынны, бездән чыккач, республика клиник хастаханәсенә алып киткәннәр, операция ясатканнар. Шуннан безгә шикаять килеп төште. Янәсе, без ярдәм итәргә теләмәгәнбез... Ул көнне Казанда гөрләп Сабантуй бара. Түзеп булмаслык эссе. Ә без травматолог белән шул ханымның яшәгән җирен эзләп йөрибез. Әмәт тавында тора икән, көчкә эзләп таптык. Авыруның хәлен тикшереп, ярдәм күрсәтеп кайттык. Рәхмәтләр әйтә-әйтә калдылар».

«Табибларың акча ала, беләсеңме шуны?»

– Бервакыт танышым миңа шулай дип шалтыратып ята. Чакыртып керттем шул табибны. Аптырап китте: «Сез нәрсә инде, нишләп алыйм, башыма тай типмәгән ич минем», – ди. Ул кеше, чыннан да, аның кесәсенә мең сум акча салырга маташып караган. Табиб алмагач, акчасын ординаторскийда – аның өстәлендә калдырып киткән. Бер уйласаң, табибның ни гаебе бар монда?!. Әңгәмәдәшем бермәл дәшми тора. – Акчасын илтеп кайт дидем. Хурлык та бит әле ул табиб өчен. Нишләсен, илтеп кайтты.

«Начмед» – кабинетта гына утыру түгел ул. Кабинетта утырган килеш, бөек полководецлар шикелле, яу кырында барган бөтен хәлләрне белеп, сәгать саен, минут саен килеп чыккан проблемаларны сиңа чиксез ышанган авырулар файдасына шунда ук хәл итү дигән сүз ул.

– Авыруга ярдәм күрсәтмичә кире борып җибәрү очракларын, бигрәк тә шуны нигезсез эшләүләрен кичерә алмыйм. Үзегезне шул авыру урынына куеп карагыз, – дим. Табиблар ул авыруның өенә барып, йә хастаханәгә алып килә яисә тиешле ярдәм күрсәтеп кайта. Уен эш түгел. Хәлләре начарайгач, мәшәкатьборчулары гына күбрәк булачак бит аның. Болар барысы да Тәүфыйк Фәтхерахман улы сабаклары.

Хастаханәдә тәҗрибәле, югары белемле белгечләр эшли. Биредә элек төшләренә дә кермәгән камил, яңа медицина җиһазлары... Хастаханәнең хәзерге генераль директоры Рамил Уел улы Әхмәтов бөтен тырышлыгын куеп эшли. Ул килгәннән соң, клиника үз йөзен югалтмады. Коллективта тотрыклылык саклана.

– Аның белән эшләве бик уңайлы – тыныч, ипле кеше ул, – ди әңгәмәдәшем. – Сәламәтлек саклау бүлегенең элеккеге җитәкчесе буларак та, зур тәҗрибә туплап килгән. Электән бергә шушы системада эшләгәнгәме, озаклап бер-беребезгә яраклашасы булмады.

Хастаханә ишеген ачып керүчеләрнең һәрберсе ак халатлы игелек ияләре яныннан тормышка яңадан кайткандай булып, зур рәхмәт әйтеп чыгалар. Табибларга рәхмәт сүзләре белән тулган кенәгәдә йөрәктән чыккан нинди генә сүзләр юк!

...Ул тизлек ярата. Атка да атланып чаба, машинада да элдертә, квадрациклга утырып, тауларга да менә, кышын снегоходта йөри. Диңгезгә барса, судан чыкмый. Фитнес белән шөгыльләнә. Нәрсә әйтәсең моңа?.. «Спортсменка, отличница, красавица!» Һәм, әлбәттә инде, үз эшенә тугры калган «Татарстанның атказанган табибы», Бөтенроссия бәйгесендә җиңүчеләрнең берсе булган «Кайнар йөрәкле доктор». Таләпчән, кырыс... һәм кайнар йөрәкле!

Медицинада озак еллар эшләү дәверендә күп кенә Мактау кәгазьләре, Дипломнар белән бүләкләнгән Вәсилә Зөфәр кызының күркәм юбилее. Чын күңелдән котлыйбыз! Сәламәтлек, уңышлар юлдаш булсын аңа!

ХАТЫН-КЫЗ ТОКМАЧ БАСАРГА ТИЕШМЕ?



Ирләр күзлегеннән

Равил САБЫР

Шушы сөаль борчый әле мине соңгы көннәрдә. Башка кереп утырды да, һич чыкмый. Каян килеп керде бу сәер сорау, дисәгез, әйтәм. «Сөембикә»нең баш мөхәррире Гөлнара Сабирова шалтыратты: «Равил, «Хатын-кыз рульдә йөрергә тиешме?» дигән темага мәкалә язып бир әле». Мин уйга калдым: «Ә бала табарга тиешме? Ә токмач басарга?» Чөнки хатын-кызларның машина йөртүләре, җитәкче урыннарда эшләүләре инде күптән гадәти нәрсәгә әйләнде.

Шул ук вакытта интернетта бер фото күреп шаккаткан идем. Анда унлап ир-ат йөгереп баручы бер ханымга ябышканнар, аны ничек тә булса туктату – ниятләре. Фото 1967 елда Бостонда төшерелгән икән. Катрин Швейцер исемле ханымның да марафонда катнашасы килгән, тик хатын-кызларның ул чакта андый хокуклары булмаган әле. Ярты гасыр элек кенә Бостонда, демократия бишеге АКШта булган хәл бу!

Аңа кадәр бер ел элек Ив Сен-Лоран, хатын-кызлар өчен смокинг уйлап чыгарып, дөньяны дер селкеткән. Аның бу яңалыгын шундук Катрин Денев, Лайза Миннелли һәм башка бик күп күренекле ханымнар эләктереп алганнар, тик моннан ярты гасыр элек чалбарлы костюм кигән ханымнарны беренче мәлләрдә рестораннарга кертмәгәннәр, андый «бозык» студент кызларны университетлардан куган очраклар булган.

Нәрсә ул чалбар?! АКШта хатын-кызларга сайлау хокукы тулысынча 1920 елда гына бирелгән, Бөекбританиядә – 1928 елда, Франциядә – 1945 елда, Германиядә – 1948 елда, ә Испаниядә – 1976 елда. Чагыштыру өчен: Россиядә – 1918 елда. Аның каравы, хәзер тулы ирек: хатын-кызлар берберсенә хет кияүгә чыга, хет өйләнә ала.

Мистика яратучы бер кеше белән сөйләшеп торган идек шулай. Җир шары белән англосакслар, ягъни яшерен бөтендөнья хөкүмәте идарә итә дип инанган ул. Аның фикеренчә, Россия — англосакслар колониясе, һәм алар хәзерге вакытта бу илдә гаилә институтын юк итү өчен барысын да эшли.

«Безнең законнар шундыйга әйләнде хәзер, Равил, – ди бу, – дәүләт, турысын әйткәндә, хатын-кызның сутенерына әверелде. Мәскәүдә, мәсәлән, ике хатын-кызның берсе – бүген эшмәкәр, аларның бизнеслары шундый – кияүгә чыгу. Берәр шәбрәк ирне әйләндереп алалар да, бер, күп булса, ике бала табалар да, аннары аерылалар. Ирләре алимент түли, балаларын күргәннәре дә юк».

Ярар, монысы минем танышымның мәсьәләгә, кем әйтмешли, глобаль карашы булды. Тик шулай да, хатын-кыз токмач басарга тиешме соң? Тиеш, дип саный Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов. АКШтагы Берлингейм дигән шәһәрнең (Калифорния штаты) «Татар йортында» булган очрашуда бирелгән оешма вәкиле Адилә Сафа Президентка:

– Монда җыелышлар була, кешеләр аз килә. Ләкин әйтсәң, җыелыш беткәч, пәрәмәч була дип, – уау! – монда кеше тула! Бездә «Бәхетле» юк, үзебезгә пешерергә кирәк бөтен татар ашларын да, – дигән иде.

– «Бәхетле» – ул ялкау булган хатыннар өчен генә, – дип җавап бирде Рөстәм Миңнеханов. – Әгәр дә хатының ашарга пешерә белсә, «Бәхетле»гә барып бер әйбер дә алмыйсың.

Һичшиксез, Миңнехановлар гаиләсендә Рөстәм әфәнде хуҗа, юкса ул болай дип җавап бирмәс иде. Чыннан да, «Хатын-кыз токмач басарга тиешме?» дигән сорау ахыр чиктә «Өйдә кем хуҗа?» дигән сорауга барып тоташа. Чөнки хатын хуҗа булса, ир токмач баса.

ВЦИОМ үткәргән сораштыру нәтиҗәләре буенча, Россиядә 82 процент халык гаиләдә ир белән хатынның хокуклары тигез булырга тиеш һәм алар теге яки бу карарны үзара килешеп кабул итәргә тиеш дип саный икән. Тиешкә тиештер дә ул, тик минә тормышта алай була алмый шул. Бу нисбәттән бер кызыклы әңгәмә искә килеп төште. Берсендә шулай яшь журналист ханымны эшкә алабыз, баш мөхәррир төрле-төрле сораулар бирә моңа. «Сезнең өйдә кем хуҗа?» – дип тә сорады бу. «Бездә равноправие», – дигән җавап яңгырады. «Хатын-кыз равноправие дип сөйләсә, димәк, өйдә ул үзе хуҗа инде», – дип куйды җитәкчебез.

Гомумән, хатын-кыз белән әңгәмә кору – гади эш түгел ул. Әйтик, ир-ат нинди дә булса җитди карар кылар алдыннан хатыны белән киңәшләшә башласа, тегесе: «Син әллә ир-ат түгелме соң?! Нигә бөтен нәрсәне миннән сорыйсың? Үзең хәл итә алмыйсыңмыни?» – дияргә мөмкин. Ә киңәшләшмичә генә үзенчә эшләп куйса: «Син нигә миңа бер сүз дә әйтмәдең? Мин кеше түгелмени? Шунда киңәшләшергә ярамыйммы?» – диячәк.

Анысы гаиләдә табак-савыт шалтырамый тормый инде. Бик тапталган мәкаль булса да, бу юлы да язып куйдым әле, чөнки очрагына бик туры килеп тора. Туйларда еш кабатлыйлар инде бу мәкальне. Тагын әле ир – баш, хатын – муен, дигәнне кабатларга яраталар. Янәсе муен кайсы якка бора, баш шул якка борыла. Тик дөресен әйткәндә, баш мие муен мускулларына әмер бирә, киресенчә түгел. Шуңа күрә мантыйгы аксаган бу мәкальне, минемчә, бары тик хатын-кыз гына уйлап чыгара алган. Ә бәлки берәр ир әйткәндер, хатын-кызларны тынычландырыр өчен...

Тынычлану димәктән, беләсезме нинди гаиләдә тынычлык, үзара хөрмәт, бәрәкәт һәм бәхет хөкем сөрә? Әгәр дә өйдә мәхәббәт хуҗа булса...



Тулысынча сайтыбызда укыгыз.

PRESSA

КОЯШ, ХЫЯЛ, ӨМЕТ БҮЛӘК ИТӘСЕ КИЛӘ!

Эльмира
ЗАКИРОВА

ДӨНЬЯ – БАШКАЛАР ЯЗМЫШЫНА БИТАРАФ БУЛМАГАННАР БЕЛӘН МАТУР УЛ.

Башкалар кайгысын алар җиңеләйтә белә, ярдәмгә ашыга, кылган изге гамәлләреннән шәфкатьлелек, җылылык бөркелә. Яшь буынга ярдәм итү һәм социаль башлангычлар хәйрия фонды «БлагоДарение» турында нәкъ менә шулай әйтеп буладыр.



Республиканың көньяк-көнчыгышында – Баулы, Бөгелмә, Ютазы районнарында, шулай ук Актаныш, Минзәлә якларында бу фонд, аның матур эшләре турында инде сокланып та, гаҗәпләнеп тә, яратып та сөйлиләр. Татарстан Республикасының 33 нче көньяк-көнчыгыш сайлау округыннан Дәүләт Советына сайланган үз депутатлары Ирек Фәрит улы Салихов әнә шундый фонд оештыруны уйлап таба. Ярдәм сорап, аңа күпләр килә, күпләр мөрәҗәгать итә. Чөнки беләләр: башкалар кайгысына, бүтәннәр хәсрәтенә ул беркайчан битараф калмый, һәрчак ярдәм итәргә әзер. Балаларның уй-хыялларына да, җан авазына, күңел җәрәхәтләренә дә шулкадәр сизгер, игътибарлы кеше ул. 2015 елда «БлагоДарение» хәйрия фондын оештырып җибәреп, аның иганәчесе булуы да әнә шул олы йөрәкле, миһербанлы була белүеннән.

7 июль – фондның туган көне, быел аның оешуына өч ел була. Шушы аз гына вакыт эчендә дә гаҗәп күп эшләр башкарыла! Социаль яктан әһәмияткә ия бик күп чаралар, җылы очрашулар, талантлы балаларны үстерүгә, өлкәннәрне һәм ветераннарны хөрмәтләүгә юнәлтелгән масштаблы проектлар... Фондның төп максаты: халыкның яклаучысыз социаль катламын кайгыртып тору, сәламәтлеге чикләнгән, караучысыз калган балаларга, өлкән яшьтәгеләргә һәртөрле ярдәм күрсәтү, мәгариф, мәдәният, сәнгать өлкәсендә шәхеснең рухи үсешен тәэмин итү.

Оештыру сәләтенә ия тәвәккәл, тырыш, тәҗрибәле, игелекле затлар «БлагоДарение» хәйрия фондын җитәкли. Фондның президенты – Фәрит Муллагали улы Салихов. Ул укытучы да, спортчы да (Актаныш районы Шахмат федерациясе һәм Чаңгы федерациясе рәисе), җитәкче дә («Татавтодор–Актаныш» ҖЧҖ директоры), әти, дәү әти дә әле (Ирек һәм Илнар Салиховларның әтисе, оныкларының яраткан бабасы). «БлагоДарение» хәйрия фонды директоры – хыялларны чынга әйләндерә белүче, балаларны матур сүзләр белән үсендереп торучы, мең мәшәкатьләр белән янучы, төрледән-төрле кызыклы идеяләр белән илһамландыручы якты кеше – Рузилә Якуп кызы ШӘЙМӘРДАНОВА.

«Эшлим дигән кешегә эш табыла икән: алар арткан-нан-арта, күбәйгәннән-күбәя бара», – Рузилә Якуп кызы шулай ди дә көлеп җибәрә. Аннары «БлагоДарение» фондының эшләре белән таныштыра башлый. Яратып та, илһамланып та сөйли. Ярдәм өмет итеп, аңа ышанып караган кызларны-малайларны исемләп искә төшерә, аларның хыяллары, үскәч кем булырга теләүләре турында безгә дә җиткерергә ашыга. Әллә нинди проектлар, акцияләр, волонтерлар, слетлар, меценатлар...

Боларның барысын да ничек хәтердә калдырып бетерергә дә, ничек вакытында үтәп чыгарга? Шаккатып аны тыңлыйм. Җитәкче хатын-кызлар, гадәттә, «Ежедневник» дигән көндәлеккә алдан эшләнәсе эшләрне, билгеләнгән очрашуларны, тиз арада хәл итәсе мәсьәләләрне теркәп баралар һәм төгәл үтиләр дә. Рузилә Якуп кызының да өстәлендә шундый көндәлек ята. Һәм аның һәр бите төрле даталар, күрәсе кешеләр, кызыклы идеяләр белән чуарланып беткән. «13 май, 12.00. «Татнефть-Арена»да «Вымпел» хоккей турниры», «10 март. «Татарстанның Чуаш гүзәле-2018» бәйгесе. Эльвина белән Анастасия катнашырга тиеш!», «5 яшьлек Аязга 370 меңлек аппарат кирәк!»... Һәм һәр эш янында «+» тамгасы куеп барылган.

– Ә сез беләсезме, чын күңелдән ышанып теләсәң, хыяллар һичшиксез тормышка аша ул!

Рузилә әнә шулай канатлы берәр фикер әйтеп куя, аннан шуны сүтә башлый. Әйе, аларның «Хыяллар чынга аша!» проекты кемгә дә кызык булырлык икән шул! Үскәч депутат булам дип язган 13 яшьлек Рамазан өчен депутат Ирек Салихов белән махсус очрашу оештырганнар. Спортчы булырга теләгән Максим... рәхәтләнеп көрәшче Сергей Петров белән аралашкан. ГИБДД хезмәткәре, дизайнер, сатучы, табиб, тренер, кондитер, хезмәт укытучысы... Балаларга нинди һөнәр кызыклы, барысын да үзләре сынап караган. Хакимият башлыгы булам дигән Арсений исә Баулы районы хакимияте башлыгы Рамил Гатиятуллин кабинетында утырган. Руслан фотограф булырга хыяллана икән, ул Баулы телевидениесендә «практика үткән», фотоларыннан күргәзмә дә оештырганнар.

...Күңел белән очып кына Баулыга да барып кайтабыз, сәламәтлеге чикләнгән балаларның «Ангелы «Благо» театр студиясе белән гастрольләрдә дә йөрибез. «Шатлык» тернәкләндерү үзәгенә, «СемьЯ» социаль приютына кереп чыгабыз. Роналд Макдоналд йортындагы балалар, күр, тәмам әкият геройларына әйләнгән: волонтерлар аквагрим ярдәмендә битләренә кызыклы персонажларны төшергән. Баулы, Урыссу, Бәйрәкә волонтерлары ясаган открыткалар ничек матур! «Татнефть-Арена» сараенда «Ядран-Ойл» компаниясе белән берлектә узган хоккей турнирында җан атып утыргандай булабыз. Җыелган акча «Шатлык» тернәкләндерү үзәге өчен уен мәйданы төзүгә тотылачак, ди. Тукта, легендар шахматчы Анатолий Карпов Актанышка килде, диме? «БлагоДарение» фонды Президенты Фәрит Салихов ничек итсә иткән, Карповны Актанышка китерткән! Районның иң оста шахматчы балалары берьюлы уйнау сеансында Дөнья чемпионы белән көч сынашкан.

Кар өстендә казан кайната, диләр андыйлар турында.

Ирек Салихов «Шатлык»та тәрбияләнүчеләр өчен чын әкият ясаган: Гүзәл Уразова һәм Илдар Хәкимов алар белән очрашуга килгән. Хәер, кемнәр генә очрашмаган ул балалар белән! Автоузышчы, раллийкросста Европа чемпионы булган Тимур Тимерҗанов, Г. Камал театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев, режиссер Илшат Рәхимбай... «Ангелы «Благо» театрының яшь артистлары күптән түгел үзләре Казанга, Камал театрына кунакка килделәр. Яраткан артистлары белән коллегалар кебек аралашулар, аларның грим бүлмәләрендә утырулар... Зур сәхнәдән «Путь к счастью» спектаклен башкала тамашачысына тәкъдим итүләр...

Яныңда сине аңлый белгән кеше булу үзе бәхет. Ирем Фәнискә рәхмәтле мин. Хәйрия өлкәсендә эшләгән кешегә гаиләсе тарафыннан аңлау булмаса, бик кыен булыр иде. Чөнки командировкаларга иртән иртүк чыгып китәсең. Атналар буе кайтмый йөрисең. Баулыга ике көннең берсендә барырга туры килә. Биш сәгать барасы, биш сәгать кайтасы...
Әти-әнием исән-сау, ирем – янәшәдә, кызларымның үз тормышы, оныкларым Мансур, Дамир, Таир, Алтына, Диана тәгәрәшеп үсә... «Аһ! Сөбханалла!» диярлек кенә!









Депутат булырга хыялланган Рамазанга депутат велосипед бүләк итә.

Тагын... без әле 18 яше тулган Руслан Евстифеевта кунакка да кереп чыккандай булабыз. Баулы район җитәкчелеге биргән өр-яңа фатирда өй туе диярсең. Рузилә ханымның бер сызгыруы җитә: «Ямьле» салоны тәрәзәгә шторалар элә, «БлагоДарение» фонды – суыткыч, Фәрит Муллагали улы – кер юу машинасы, Ирек Фәрит улы – телевизор бүләк итә, бирәүләр – савыт-саба, икенчеләре – урын-җир кирәк-ярагы күтәреп килә... Чып-чын әкият, билләһи!

Яшь артистлар күкнең җиденче катында иде!..

...Юк, әле бетмәде. Хыялыбыз офыкларында Рузилә ханымның балачак авылы Табанлыкүл дә, яшьлеге узган Түбән Кама да чагылып кала тагын. Әнисе Венера апа белән әтисе Якуп абый өчен ул – инде биш оныгы булган Рузилә – һаман бала. Кайтам, дип хәбәр генә сал – урам чатына ук чыгып басалар.

– Кызым, «Тәрәзәдә ут булганда, кайтып йөрергә кирәк, балам», – дип җырлый Бәширә...

Әнисенең тел төбен аңламыймы соң инде Рузилә! Җай чыккан саен, үзе рульгә утырып кайтып килә ул.

Ә бу эшенә кереп китүе, әлбәттә инде, әти-әни тәрбиясеннән килә. «Мин хәйриячелеккә күптән әзер идем инде. Балачактан ук. Безнең гаиләдә бар ул, – ди Рузилә. – Әти белән әни икесе дә әдәпле, кече күңелле, ярдәмчел кешеләр. Балаларын да олыларны хөрмәтләргә өйрәтеп үстерәләр. Табанлыкүлдә бер күрше әбекәй яши иде. Үземне белә-белгәннән бирле шул әбекәйгә булышырга йөгерәбез. Күрше әбекәй дип кенә йөрибез. Исеме шулайдыр дип уйлый идек. Әле мунчага чакырабыз, әле чәйгә дәшәбез. «Бар әле, кызым, әбиеңнең суы бетмәгәнме?», «Бәбекәем, әбиеңә мичтән чыккан көлчәләрне кайнар чагында кертеп чык әле...» – дип, әни гел шул әбиләргә кертеп җибәрә. Энем Фаил белән чын-чынлап «Тимур һәм аның командасы» идек. Соңыннан гына аның бары күрше әбекәй генә булганын белдек. Күңелдә барыбер үзебезнең әбекәй булып калды ул», – дип сагына.

Тагын шунысын да әйтергә кирәктер: Рузилә тирә-юньгә бер атаклы мич чыгару остасы Әбелкасыйм оныгы да бит әле! Бабасына гозер белән әллә кайлардан киләләр, аңардан мич чыгартыр өчен чират торалар. Мич ул – йорт, гаилә җаны, җылылык, ипи дигән сүз. Бабасы әнә шулай авыл халкына җылылык, шатлык өләшкән. Кешеләрне сөендерү геннар белән Рузиләгә дә күчкән, димәк. Соңгы елларда болай да хәйриячелек ягына борыла башлаган инде ул. Банк структурасында эшләгәндә ишле балалы гаиләләргә, мохтаҗ, авыру балаларга кием-салым, язу әсбаплары, уенчыклар, китаплар бирүләрне гадәткә әйләндергән иде. Берчак кызлары Миләүшә белән Резеда Түбән Камада «Чайка» лагерендә ял итә. Балалар йортында тәрбияләнүчеләр дә шул сменада икән. «Яннарына баргач, «Әйдә, үзебезгә алыйк әле», дип, бәләкәй малайларны җитәкләп каршыбызга килә кызларым, чактан гына алмый калдык», – дип елмая Рузилә ханым.

Менә хәзер үзенә шундый балалар белән эшләргә язган икән.

Рузилә Якуп кызы сөйләгән һәр вакыйга үзе бер хикәя сыман.

– Баулыга баргач, «Шатлык» тернәкләндерү үзәгенә беренче тапкыр килеп кенә кердем – кулга сценарий тоттырдылар. Спектакль куярга җыеналар икән. Инвалид балалар, аларның әти-әниләре утыра. Шундук үз кеше итеп тота башладым үземне. Балаларның кайсын башыннан сыйпыйм, кайсын кочаклыйм. Хәлләрен сорашам, көләм, шаяртам. Текстны тиешле интонация белән кычкырып укый башладык. Бөтен тамаша күз алдымнан үтә. Шунда ук рольләр бүләбез. «Монысын кем ала?», «Кемгә бирик?», «Әйдә, син уйна бу рольне!», «Килеп чыгачак!» – дип үсендерәм әле. Әкрен-әкрен миңа елышалар. «Мин алам, мин!» – диешә башладылар. Күрәм: бер малай нидер әйтәсе

килгән кебек кыбырсый, авыз эченнән нәрсәдер пупалый. Әнисе, ярар, тик кенә утыр дип, тыймакчы. «Нәрсә әйтмәкче ул?» – дип кызыксынам. «Аның да уйныйсы килә», – диләр. Тик ул ДЦПлы бала икән, сөйләшә алмый. Әйдә, бер роль табабыз аларга да, дип, булмаган рольне уйлап чыгардык. Әнисе инде, ярар, басып кына торсын ди. Ул анысына да бик риза. Таптык бит аларга да роль: Добрыня һәм Добрянка.

– М-м-м, – ди малай.

– Да, какие красивые у нее глазки! – дип тәрҗемә итә әнисе.

Тагын «М-м-м» кабатлана.

– Да, какие у нее белые ручки!

Диалог дәвам итә. Сөйләшә алмый торган бала актер булды шулай. Режиссер эзли башладык. Баулы халык театры режиссерын әйдәкләргә керештем. Миргалиян Миргазиян улы Фәхриевны. Килергә теләмәде башта. Сәламәтлегем юк, ди. Бик нык ялына, җайлый-майлый торгач, күндердек тәки. Бергә эшли башладык. Ул педагог кеше, инглиз теле укытучысы, театрның режиссеры да. Композитор Лилия Таһировага да рәхмәтле без. Казаннан ук килеп, спектаклебезне әзерләште. Көн саен репетицияләр. Аннары сәхнә артында дәвам итә бу кабатлаулар.

Сөйләшми торган егетебез сәхнәдә: «Какие у нее красивые глазки!» – дип үзе әйтә алды! Бу могҗизага тиң иде! Менә бит сәхнәнең көче! Аралашуның, коллективизмның көче, сихәте! Кешенең үзен үзе җиңә алуы! Спектакльдән соң әнисе елады. «Улым белән алданрак шөгыльләнгән булсагыз, ул сөйләшә алган булыр иде», – ди. Спектакль күр-сәтәсебезгә беркем ышанмады. Инвалид балалар, коляскалы балалар нишләр икән инде, дип шикләнделәр. Ә тамаша вакытында бөтен зал елады...

Менә шундый ул Рузилә Якуп кызы. Булмастайны булдыра, юктан бар ясый. Әле кабынып, күзләре белән янып, әле катгый карарга килеп, сүзен өздереп әйтеп, әле шаян елмаеп, кызыклар сөйләп, каршымдагы Рузилә ханым төрледән-төрлегә әйләнә. Аны тыңлаган саен, яңадан-яңа сыйфатлары белән ачыла бара.

ЯЗМАГА КЕРМӘГӘН ЮЛЛАР

■ **Эшләмәгән эшем калмады**. Мин табиб булырга хыялланган идем. Мединститутка керергә балларым җитмәде. Түбән Кама медучилищесында укыдым. Шәфкать туташы булып эшләдем. Активлык, оештыру эшләренә әвәслек нәселдән киләдер. Әни спектакльләрдә уйнап йөри, әти моңлы тавышы белән җырлый иде. Заманында авылдашы Хәнәви Шәйдуллин белән бер сәхнәләрдә җырлап йөргән кеше ул. Мине медицина хезмәткәрләренең профсоюз оешмасын җитәкләргә чакырдылар. Ит эшкәртү заводында директор урынбасары, банк структураларында җитәкче, Кама аръягы төбәгендә җитәкче... Экономик һәм юридик белемнәр алдым, күп мәртәбәләр төрле психология курсларында укыдым.

■ **Яшермим: башта бер дә җиңел булмады.** Кирәкле сүзләрне табасы, хисләреңне тезгенлисе... Монда бит ул баланың бөтенесен кочакларга, бөтенесен сөяргә йә бөтенесен дәваларга, бөтенесен гаиләгә алырга кирәк. Җитәкче, менеджер-оештыручы, менеджер-администратор сыйфатлары нык сеңдерелгәч, теләсә кайда эшләп була. Ә һәр фонд нинди дә булса бер юнәлештә генә эшли. Башкаларны кабатламый. **Охшаш фондлар юк. Һәркайсының үз юлы.** Нульдән башларга туры килде.

■ **Ирек Салихов оештырган фонд депутат Ирек Салихов сайлаучыларын борчыган, кызыксындырган сораулар белән шөгыльләнә.**

■ Кичләрем район газеталарының сайтларын караудан башлана. Баулы, Бөгелмә районнарында, Ютазының Урыссуында атнага бер яңалык та булмаса, команда белән уйлана башлыйбыз. Нишләп балалар тик утыра? Алар дүрт стена арасында калырга тиеш түгел. Башка балалар кебек үк, кумирлары белән аралашасылары, аларга сокланасылары, алар белән бер тында, бер дулкында буласылары киләдер. Читтән кемдер килү алар өчен бүләк, бәйрәм булачак. Шуны аңлата белергә кирәк! **Балалар көткәнен аңлата белергә!**

■ **Теләсә кемнең күңеленә ачкыч табып, теләсә кем белән сөйләшеп була** – эшеңне яратырга гына кирәк. Кая гына барсак та, елмаеп керәбез, йөрәгебезне ачып сөйләшәбез дә, үзебез дә янабыз, башкаларны да кабызабыз. Үзеңне, тәмле сүзләреңне, эмоцияләреңне җәлләмәскә генә кирәк!

■ **«Тимер кулга замш перчатка кигән леди»**. Бер тренингта җитәкчеләрнең психик-эмоциональ халәтенә тест уздырганнар иде. Мине шулай бәяләделәр. Тыштан каты булып, куырып эшләтсәм дә, бәрхет кебек йомшак та була алам. Кайбер балалар өчен мин – җылы, кемнәргәдер – ачык, беришләренә таләпчән булып күренәмдер. «Килдек, күрдек, елмайдык һәм эшләп тә куйдык», – безнең команданың девизы бу.

■ **Алыштыргысыз командам белән бик күп эшләр башкарылды.** Һәркемнең үз урыны. Мин һәрчак аларга таянам.

■ **Рульдә утырып йөрергә яратам.** Казан–Түбән Кама маршруты аеруча якын. Җай чыгу белән әти-әни янына ашыгам. Ике кызыбызны да 18 яшь тулуга рульдә йөрергә өйрәттек. Бүгенге көндә әни кешеләргә дә рульгә утырмый булмый.

■ «БлагоДарение» хәйрия фондының иганәчесе Ирек Фәрит улы Салихов яшь булуына карамастан, олы йөрәкле. Бик булган эшмәкәр. Андыйлар, гадәттә, үргә менү, карьера ясау, мал табу дип чаба. Ә ул итагатьле, тәрбияле, зыялы. Затлы нәселдән: укытучы һәм табиблар гаиләсендә үскән. Башкаларга ярдәм итәр өчен яратылган. Гади, башкаларга хөрмәт белән карый. **Менә кемнән үрнәк алып үсәргә кирәк яшьләргә!**

■ Әнисе Нурия ханымның булганлыгы, зәвыгы турында аерым сөйләрлек. Йә, кайсы җитәкченең әнисе улы эшләгән коллективка бәйрәм саен үзе махсус балан бәлеше, чәкчәк пешереп җибәрә инде?! **Бу – тәрбиялелек, улыңның хезмәттәшләрен хөрмәт итү белгесе.** Шушы самимилек, гадилек балаларына да күчә.

■ **Иң ошаганы – эшләргә дә эшләргә, эшләргә дә эшләргә кирәк!** Баланы башыннан сыйпасаң да, баскычтан күтәрелергә булышсаң да, ата-анасы белән баласы турында сөйләшсәң дә – дөрес юл, дөрес эш була.

■ Балаларның хыяллары тормышка ашсын дип эшлибез. Аз булса да аларга **Кояш, Хыял, Өмет бүләк итәсе килә.** «Путь к мечте» спектаклендә дә шул чагылды бит.

■ Ура! Ура! Бүген искиткеч көн! **Кечкенә Шамилгә операция вакытында ясалачак!** Тиешле акчаны җыеп бетерә алдык!

■ **Миңа балалардан әйбәт энергетика килә!** Аларның килеп сарылуы, кочаклап алуы... Арада бер башка миннән зурраклар да бар. Өерләре белән кочаклап алалар. «Обнимашка» фазасын узасың шулай. Аркасыннан сыйпап сөйләшәсең. Балалар елмаюыннан, аналарының күз карашыннан үзеңнең кирәгеңне аңлыйсың. Шулкадәр рәхмәтле алар!

Лилия ГӘРӘЕВА

ШӘФКАТЬ МАРАФОНЫ

АЗНАКАЙДА ЕЛ САЕН ШӘФКАТЬЛЕЛЕК МАРАФОНЫ УЗА.

Соңгысында 4 миллионнан артык акча җыелган. Бу акча тиененә кадәр инвалидларга, ятимнәргә, күп балалы мохтаҗ гаиләләргә тотылачак.

Була шундый җирләр, ник мин монда яшәмим икән, дисең. Матур табигатенә кызыгып кына түгел, кешеләре белән аралашып, халык өчен тудырылган уңайлыкларын күргәннән соң ярала ул фикер.

Азнакай яклары белән танышкач та шундый уй туган иде. Башка районнарда да шулайдырмы, юктырмы, ә менә Азнакайда һәркемне зур юбилее белән район башлыгы үзе килеп котлый. Беренче тапкыр кулыңа паспорт алу да күңелле тантанага әверелә аларда. Җиләк бәйрәмнәре дә Чатыр тау якларында гына түгел микән әле? Азнакайлыларның кочтеп алган иң күңелле көне бу – автобусларга тәялеп, яше-карты җиләкле болыннарга тарала. Берәү дә җәй нигъмәтеннән авыз итми калмый бу көнне. Үзләре бара алмаганнарга чиләге белән җыеп алып кайтып бирәләр. Кичен исә Азнакай урамнары җиләк исенә күмелә. Урамы-урамы, йорты-йорты белән берләшеп, урамнарга зур-зур табыннар корыла.

Иң беренчеләрдән булып үзләрендәге ятимнәр йортын бетерүчеләр дә азнакайлылар. Бер Чалпы авылында гына да ятимнәрне сыендырган сигез гаилә яши.



Рушания һәм Әзһәм Галиевлар гаиләсе, Азнакай районының Чалпы авылы.

Барып күргәнче үк, мин аларны нәкъ шушылай күзаллаган идем – миһербанлылык бөркелеп торган көләч йөз, сабыр акыллылык... Тугыз ятимгә бирерлек җан җылысын каян алган алар?

– Без башта Алинәне генә алып кайткан идек. Балалар йортында абыйсы белән энесе калган икән. Кунакка гына алып кайткан җирдән, малайлар: «Без сездә калабыз, китәсебез килми», – дигәч, Алмаз белән Айнур да

Азнакай. Гаилә паркындагы «Гаилә» һәйкәле.

безнекеләр булып куйды. Алмаз – коррекция мәктәбендә укый торган бала. Мәктәптә гел елап кала. «Тагын шундый берәр бала юк микән? Бер-берсенә иптәш булырлар иде», – дип, Максимны алып кайттык. Аннары менә Айгөл һәм Айнур Каюмовлар... Әбиләре белән генә авылда үскәннәр, әбиләре үлгән. «Бер дә ияләшә алмыйлар, авылны сагыналар», – дигәч, кызгандык. Аннары Гөлнараны, Данилны, Люданы алдык. Данил быел мәктәпкә барасы», – ди Рушания апа, шулкадәр дә Әзһәм абыйның үзенә охшаган төпчек улларының башыннан сыйпап.

– Безгә 11 сыман да түгел алар. Өйдә берсе генә булмаса да, юксындыра. Үзләре дә татулар. Бер-берсен бик яраталар, бөтен эшне бергәләп эшлиләр, берсенең кайтканын берсе көтеп кенә тора, – ата-ананың һәр сүзеннән балалары белән горурлану сизелә.

Алмаз, әтисе белән әнисе, ике абыйсы кебек, Галиев фамилиясендә. «Кызгандык. Сау да түгел, кая барыр, дидек тә, үз балабыз итеп яздырдык», – ди Рушания апа. Без күрешкән көнне балаларны Казанга циркка озату хәстәре белән йөриләр иде. Күп балалы гаиләләргә районның бүләге икән. «Бер генә бәйрәмнән дә калдырмыйлар. Бездә авыру балалар өчен махсус Сабантуйлар, Чыршы бәйрәмнәре дә уза», – ди алар.



Рәмилә һәм Фәрәгать Зәкиевлар гаиләсе, Азнакай районының Ирекле авылы.

Үзләренең өч уллары янына дүрт ятимне сыендырган олы йөрәкле бу гаиләдә – балаларныңның кайсыларын үзләре тапкан, кайсылары тәрбиягә алынган – аңларлык та түгел. Тыңлап торсаң: безнең Айгөл, безнең Маша...

– Ирек белән Радиктан соң ук бер кыз баланы тәрбиягә аласыбыз килгән иде инде. Ничектер, ул вакытта уйда гына калды. Аннары менә Камилебез туды. Бик авырлык белән генә дөньяга килде ул. «Теге вакытта ниятебезне тормышка ашырмаганга, бер сынау булдымы», – дип, Камил исән-сау үсеп китсә, берәр ятимне сөендерү уен күңелгә салып куйдык та, 2008 елда Минзәлә балалар йортыннан 8 яшьлек Айгөлне алдык. Аннары Каринаны алып кайттык. Казандагы гадәти бер гимназиядән, дәрестә утырган җирдән алып чыгып бирделәр аны. 3 нче сыйныфта укый иде. Кемнәр, ничек укыткан, ятим балага ничек тә ярар, дигәннәрме, безгә кайтканда бер хәреф тә танымый иде. Тырыша торгач, алдырып китте үзе.

2014 елда Виктория белән Машаны алдык. Маша авылдагы урта мәктәпне тәмамлады, өч кызыбыз коррекция мәктәбендә укыды, – ди әниләре.

Викадан кала, кызларның өчесе мәктәпне тәмамлаган инде. Айгөл – штукатур-маляр, Маша – ашчы һөнәрен үзләштергән. Ә Кариналары әле студент. Көн дә иртән машина белән илтеп куя, барып ала аны Рәмилә апа. Виканы узган ел район Кырымга путевка белән бүләкләгән.

Зәкиевлар да Айгөлне үз фамилияләренә яздырган. «Тик торганнан гел елый торган булды. Нигә елаганын аңламыйбыз. Әтиләре: «18 яше тулгач, бездән китәсе булыр дип елый, ахрысы, бу бала. Әйдә, елатмыйк, яздырыйк үзебезгә», – дигәч, Айгөлне үз кызыбыз итеп яздырдык», – ди әни кеше. Айгөл белән икесе дә социаль хезмәткәр булып эшли алар. Эшли дип кенә әйтү дә аз, ул аларның яшәү рәвешенә әйләнгән инде.



Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Дамир ГЫЙЛӘҖЕВ

«Бездә биш ел инде «Азнакай» шәфкатьлелек фонды эшли. Иганә акчаларына булдырылган фонд ул. Инвалидларга, ятимнәргә, ярдәмгә мохтаҗларга ярдәм итү өчен оештырдык без аны.

Районда 3593 инвалид яши. Алар арасында 276 бала да бар. Өч ел элек кенә инвалидлар саны дүрт мең ярым иде. Акрынлап, бу санны киметүгә ирештек. Хәзер халык та үз сәламәтлегенә игътибарлырак, спортка тартылучылар да күп. Шәһәребездә инвалидлар өчен 13 төрдәге спорт тренажеры белән җиһазландырылган «Шәфкатьлелек» паркы ачтык. «Чатыр тау» комплексында инвалидлар өчен махсус спорт залы бар. Андый заллар авылларда да ачыла.

Әле бөтен республикада ятимнәр йорты эшләгән вакытта да бездә инде андый оешмага ихтыяҗ калмаган иде. Районыбыздагы 186 тома ятим бала кабат әти-әниле булды, аларның берсен дә читкә җибәрмәдек. Халык киң күңелле безнең – авыру, акылга зәгыйфь балаларны да сыендырдылар. Унар бала алучы гаиләләр бар.

65 бала коляска белән йөри. Аларның күбесе яшьтәшләре белән көн дә мәктәпкә укырга бара. Бу балаларга шартлар тудыру – безнең бурыч. Авырумы ул, урында гына ята торган гарипме – берәү дә үзен кирәксез кеше итеп тоярга тиеш түгел. Һәрбер инвалид балага җитәкчеләрдән, депутатлардан берәр куратор билгеләдек. Мөмкинлеге чикле һәркемне район башлыгы Марсель Шәйдуллин инвалидлар көнендә, бәйрәмнәрдә шәхсән үзе барып тәбрикли. Ай саен фонд утырышы була, гаризаларны район башлыгы үзе карый. Гозерләрне кире какканны хәтерләмим.

Балаларның ялларын оештыру, инвалидлар өчен Сабан туйлары, Яңа ел кичәләре уздыру, мөмкинлеге чикле кешеләргә заманча коляскалар, каты авыручыларга дәвалану, тернәклөнү мөмкинлеге тудыру – фондның эшчәнлеге якынча шуннан гыйбарәт. 12 кешене атна саен Бөгелмәгә гемодиализга йөртәбез.... 100 баланы Казанга алып барып, җентекле тикшерү уздырдык.

Халык үзе дә актив. 114 иҗтимагый оешма эшли бездә. Хәтта балалар да хәйрия белән шөгыльләнә.

Әнә шулай бергә тотынсак кына җәмгыятьне үзгәртеп була. Бергәләп уйласак, иң зур проблеманың да чишелеше табыла ул.»



Фото: Ксения Богданова

АЛАР ӨЧЕН ТОРМЫШНЫҢ ИҢ ЗУР КЫЙММӘТЕ – ГАИЛӘ ҺӘМ БАЛАЛАР.

ГАИЛӘ ӨЧЕН ЯРАТЫЛГАН



Мәдинә АВЗАЛОВА

Рушания ханым: «Фәрһад мулланың өе кая дип сорасагыз, күрсәтерләр...» – дип әйткән иде. Спас районының үзәге, хәер, районның гынамы соң, бөтен Татарстанның «кайнар йөрәге» булган ата-бабаларыбызның изге Болгар җиренә аяк басуга, дөрес килдекме дигәндәй, бермәл аптырап-югалып та калгандай булдык. Ничек үзгәргән бу яклар. Гасыр төзелешенә тиң Ак Мәчет каршына килеп басып, аның матурлыгына, бөеклегенә, сихри бер көченә шактый вакыт хәйран калып тордык. Кайда торганыбызны оныттык. Әллә Мисырда инде?!

Һәм, чыннан да, «Фәрһад мулла» яшәгән йортны без бик тиз эзләп таптык. Корылмалары урманга терәлеп диярлек утырган өйнең капка төбендә утын ярып мәш килгән ирне күреп алдык та, менә бит ул үзе, дип машинада төшә-төшешли үк кул биреп күрешмәкче идек, ул шундук безгә үзенең кем икәнлеген сиздерде. «Хатын күрсә...» – дип шаяртып куйды. Хата җибәргәнебезне шундук аңлап, сузылган кулыбызны тиз генә төшердек. Ир кеше белән кул биреп күрешергә ярамый. Дин рөхсәт итми. Бусагадан кергәнче үк алган беренче дәресне күңелгә киртләп куя-куя, исемнәре рухи мирасыбызның йөз иң яхшы гаилә китабына кертелгән Рушания һәм Фәрһад МИНСӘГЫЙРОВлар яшәгән дөньяга килеп эләктек. Гомерләрен мөселман динен үстерүгә, балалар тәрбияләүгә, ныклы гаилә булдыруга багышлаган ир белән хатынның хәят дәресләре иде бу. Мин алар сөйләгәннән күп нәрсәне үземә өр-яңадан ачтым.

Әниләре: «Мин – әни, ир хатыны»

«Ничек кавыштыкмы?» – дип елмая Рушания ханым. Ул – чын мөселман хатыны, лаеклы имам-хатыйп хатыны. Бик тыйнак, әмма, сөйләвенә караганда, аны әле бер зур сәясәтче, әле тәҗрибәле педагог дип уйлый башлыйсың. Ул – әни, «Ана Даны» медаленә лаек биш бала анасы. Тормышын шул балаларга багышлаган, инде бүген канат чыгартып, кайсын кая очырган иң бәхетле әниләрнең берсе. Хади Такташның: «Нәрсә җитә ана булуга?» дигән юллары шундый ханымнарга кагыла да инде.

Рушания Салихҗан кызы – җәелеп аккан Ык елгалары, куе наратлык урманнары, киң күңелле халкы белән танылган Мөслим якларыннан. Аның да әле Башкортстан чигендәге шактый зур гына хуҗалыклы Баек авылыннан. «Бездә дә бармаем, кайтмаем, – дип сөйләшәләр, – ди ул көлеп җибәреп. – Башкортчарак инде...» Һәм ул, балачагына, яшьлегенә кайтып, ике республиканы тоташтырып торган күпер уртасында кала.

– Унынчы сыйныфны мин туган авылымда тәмамладым, – ди ул, хатирәләрен яңарта башлап. – Урта мәктәпне тәмамлаганда әни миңа әйтте: «Теләсәң кая укырга кер, тик авылга кайта торган гына эш булмасын». Мин Казанга китеп, Химия-технология институтына укырга кердем. Ә үзем гел авылны уйлыйм, сагынам, түзеп булмаслык сагынам. Кайтыр идем, сыер саварга да риза, дим. Өченче курска кадәр әйбәт кенә укып йөрдем. Бервакыт мине дус кызым Спас районының Татар Такталысы авылына Яңа ел үткәрергә чакыра. Ризалаштым. Һәм бу кайту язмышымны хәл итте дә куйды. Әнисе янына дус кызымның абыйсы да кунакка кайткан булып чыкты. Без Казанга киткәч, артыбыздан ук: «Сүнгән йөрәккә ут капты», – дип, хат килеп төште. Өч мәртәбә күрештек без аның белән, өч мәртәбә! Өченчесендә никахлашып та куйдык. Мин аңа бер күрүдә үлеп гашыйк булган кеше. Аннары уку минем өчен әллә ни түгел. Минем өчен кияүгә, бигрәк тә Фәрһад шикелле белемле, грамоталы (аның миңа җибәргән хатында бер генә хата да булмый торган иде) кешегә кияүгә чыгу мөһим.

Әйе, Рушания ханым әйтмешли, укырсың, укырсың, әллә кемнәр булырсың да, язмышыңа җүнле кеше туры килмәсә, гомер буе типкәләп йөртсә... Кемгә кирәк ул?! Анысы да бар. Кайнанасы Рузалия – килененә: «Өченче курсны гына булса да укып бетер, «неоконченное высшее булыр», – дип киңәш бирә. Бер-бер артлы балалар таба башлагач, укуда кайгы калмый. Аннан теләк тә булмагандыр инде.

– Кияүгә чыкканда, миңа әле 19 гына яшь иде. Фәрһад эшкә китә. Мин артыннан, бала-чага шикелле, елап калам. Ничек инде мин Казанга барып, атналар буе имтиханнар биреп йөрим.

Үткәннәре аны әле елмаерга, әле керфек очларын чылатып алырга мәҗбүр итә. Әлбәттә, ул өйдә ире кайтканын көтеп кенә утырмый. Тәрҗемәче булып редакциягә эшкә урнаша. Ул арада Минсәгыйровларның бик тә көтеп алган беренче бәбиләре – бәләкәй кызчык дөньяга килә.


> *«Хәлемнән килсә, бөтен хатын-кызны Мөхәммәдия мәдрәсәсендә укытып чыгарыр идем...»*

– Без ул чагында тулай торакта яшибез. 1985 елның 1 гыйнвары иде бу. Ә инде 1987 елның июнендә Айдарым туды. Бер-бер артлы таптым мин аларны. Улыма яшь тә өч ай булганда, өченче балам – Алиямне алып кайттым. Өченче балага узгач, укуны ташладым. Бер сессияне авырлы килеш бирдем дә (ул чагында авыл хуҗалыгы институтына күчкән идем), юк, болай булмый дип, бөтенләй ташладым. Алия туар алдыннан шушы өйне төзи башладык. Район хакимиятеннән өй урыны сайларга куштылар. Ә без менә иң тыныч, матур урынны үз иттек. Дәүләтнең күп балалы әниләргә күрсәткән бердәнбер ярдәме ул чагында шул булды.

Ул вакытларда Казан төзелеш институтын тәмамлап, инде өч бала атасы булырга өлгергән Фәрһад Минсәгыйров төзелештә прораб булып эшли. Яртылаш төзелгән йортны үзе салып бетерә. Яңа өйгә күченгәч, шатлык өстенә шатлык өстәп, тагын бер нәни малай кайта. Аңа Мөхәммәт исеме кушалар. Шулай итеп, Рушания 30 яшендә – дүрт бала анасы! Һәм... гаилә өчен тагын бер мөһимнән-мөһим яңалык димме, вакыйгамы – әкренләп дингә керә башлыйлар. Ул көннәрдә Болгар фонды оештырыла. Фәрһад Минсәгыйров Туристлар







■ Олы кызлары Ләйсән ире һәм балалары белән.

■ Уллары Мөхәммәт белән Айдар.

■ Айдар хатыны Эльмира белән.

комплексына директор итеп билгеләнә. Байтак эшли ул анда. Акчасы гына юк. Рушания заповедникның оешкан гына чагында татар бүлегенә экскурсовод булып урнаша. Дини кулъязмалар, китаплар белән дә күп шөгыльләнергә туры килә аңа. «Мөхәммәтне имезә-имезә гарәп графикасын өйрәнә торган идем. Бала карау бик авыр, аягың-кулың богаулы. Вакыт тиде исә – китапка...» – Рушания ханым шулай ди. Фәрһаднең мәдрәсәдә бер атна эчендә гарәп телен өйрәнеп кайткан чагы. «Нишләп ул өйрәнгәнне мин өйрәнмәскә тиеш?!»

– Бала имезгәндә гел ясин укыйм, – дип искә ала ул, – кычкырып укыйм. Мөхәммәткә яшь тә җиде ай булганда, эшкә чыктым. Кайтуыма, бала яныма әфтияк тотып килә, битен ачып күрсәтә. Укы, янәсе.

Төпчекләре Фатыйма унберенчене тәмамлый. Ул да абый-апалары кебек Төзелеш институтына керергә җыена. Әйе, әйе, Алиядән гайре (ул башта мәдрәсә, аннары Мөхәммәдия мәдрәсәсе тәмамлаган) балаларның барысы да төзүчеләр, кайсы – архитектор, кайсы – проектлаучы. Әтиләренә охшап сайлаганнармы һөнәрне, тик бу – шулай.

«Мин бу дөньяга тугры хатын, әйбәт ана булырга туганмындыр...»

Әтиләре: «Хатын-кызның бурычы – ирен карау, бала табу, дини тәрбия бирү»


Рушания ханым ире турында яратып та, назлап та: «Әти – ул безнең бәйрәм!» – ди. Чөнки хатын да, балалар да иртә таңнан эшкә чыгып китеп, кичкырын гына кайткан әтиләрен, бәлкем, үскәндә ул кадәр еш күрмәгәннәрдер дә. Ләкин өйдә әти кеше барлыгы һәрвакыт сизелеп торган һәм тора. «Ул эштән кайтканда кызган бәхәсләр инде күптән суынган була. Аның күбесен әтиләре белми дә кала», – дип елмая ул чакларны искә алганда әниләре.

Фәрһад – дистәләгән еллар Болгар мәчетенең имамхатыйбы, район мөхтәсибе. Кайларда гына белем эстәмәгән ул: Төркия, Мисыр дисеңме, Иорданияме... Ул хәзер һәрьяктан «иярләнгән» югары белемле мулла. Аның белән теләсә нинди темага сөйләшергә, бәхәсләшергә була. Аның һәрнәрсәгә карата үз фикере бар. Шуңа да аның белән гәп куертуы – үзе бер бәхет! Без дә кинәт тәтегән бу очраклылыкка куана-куана аны тыңлыйбыз. Кызыксынып тыңлыйбыз: ниләр әйтер икән?!

– Безнең районда татарлар халыкның 8 процентын гына тәшкил итә, – дип сөйләп китә ул. – Элек мәчеткә йөрүчеләр бик аз булган. Бүген исә 20–25 кеше йөри. Әле мәчетне яңартып, төзекләндереп ятабыз. Мәдрәсәдә дә укытам. Балаларымның барысы да миндә укыды. Шөкер, дини белемнәре бар. Мондагы үзгәрешләрне күргәнсездер инде. Элеккеге Президентыбыз Минтимер Шәймиевкә мең рәхмәт. Болгарның күрке, горурлыгы булып күтәрелгән Ак мәчетебез үзе генә дә ни тора! Янәшәдә – мәдрәсәсе, Никахлашу залы, хәләл ризыклы ашханәсе... Карап туйгысыз, күңел сөенә, татарның киләчәге өчен мең шатмын. Нинди генә илләрдән килмиләр безгә хәзер. Киләләр, бу гаҗәеп матурлыкны күрәләр дә, таң калалар. «Татарстанның бер почмагында шундый җәннәтне очратырмын дип уйламаган идем», – дип исләре китә. Килгән бер кунак – безнең өйдә кунакта булып китә. Дөрес, без әллә ниткән хан сарайларында яшәмибез. Яшәү рәвешебез, үзегез күрәсез, бик тыйнак. Ләкин килгән берсе, хатыным пешергән ризыкларның тел йотарлык тәмле булуына сокланып, чиксез рәхмәтен белдереп китә.

– Өченче күрешкәндә никахлашып та куйгансыз, яраткансыз, димәк.

– Бер-береңне хөрмәтләп яшәсәң, – дип дәвам итә генә башлый, Рушания ханым аны шундук бүлдерә: «Үлеп яратып кияүгә чыктым, ә ул хөрмәт ди». Фәрһад исә әйткән сүзләренең мәгънәсен аңлатырга керешә: «Хәлемнән килсә, бөтен хатын-кызны Мөхәммәдия аша үткәрер идем», – ди ул. – Иң элек хатын-кыз ул – әни! Рәсүл вакытында хатын-кызның дәрәҗәсе, әлеге дә баягы хөрмәте зур булган. Җәннәт – әниләр аяк астында, дип тикмәгә генә әйтмәгәннәр. Бүген хатын тапкан акчага көн күреп ятучылар күбәеп китте. Ә минә дин буенча, хатын-кыз эшләп тапкан акчаны ир кеше бары әҗәткә алып торырга тиеш. Без Рушания белән бөтен балаларны да укыттык. Акча кирәк булганда: «Биш мең акча биреп тор әле?» – дип сораганым бар минем аннан. Моның бернәрсәсе юк. Кире кайтаруың гына мәҗбүри. Гарәбстан илләрендә шулай. Хатын-кызга



Кызлары Алия ире Ришат белән.



Төпчекләре Фатыйма.



Минсәгыйровлар гаиләсенең киләчәге – оныклар.

төрле җәннәт ишекләре ачыла. Әгәр дә мин ахирәттә – җәннәттә Рушания белән очрашам икән, бу инде минем фани дөньядагы дөрес гамәлем хакында сөйли. Хатын дөрес әйтә, балалар белән күбрәк ул шөгыльләнә: аларга риваятьләр, догалар укый, кухняда пешеренә, өй чиста, бала-чага чиста-пөхтә... Әни кеше өйдә булгач, рәхәт. Безгә укытучылар: «Мәктәпнең ярты баласы сезнекеләр шикелле булса, бернинди проблема булмас иде», – диләр. Ә нигә шулай дисезме?!

Икебез дә дин кешеләре

Сөйләшкәннәрдән чыгып, инде хәзер нәтиҗәне үзем дә ясый алам. Бөтен хикмәт тәрбиядә, икесенең дә диндә булуында. Фәрһад хәзрәт әйткәнчә, өйдә кычкырыш-талаш юк. Биредә бер-береңә карата җылы бер ярату белән тирән хөрмәт, кайгырту яши. Гаиләгә кайгы-хәсрәт китерә торган гамәлләр, гадәтләр турында әйтмим дә инде. Аракының, тәмәке тартуны ни икәнен белмиләр дә, һәм, Аллам сакласын, белмәсеннәр дә. «Аракы эчеп үлгән татар бәндәсе теге дөньяга мөселман булып бармый», – ди бит әнә Фәрһад хәзрәт.

Әниләре, әле берсе, әле икенчесе турында кызыклы истәлекләр сөйләп, көлдереп ала. Рәхәтләнеп, истәлекләргә бирелеп утырабыз.

– Айдарым бәләкәйдән техниканы яратты, – дип дәвам итә әңгәмәне Рушания ханым. – Ул кайтса, бөтен урам малайлары җыела. Кайсының велосипеды ватылган, кайсының нәрсә... Кулы бөтен эшкә ята. Әтисенең аны мулла итәсе килде. Карыша торган гадәте юк. Төзүчеләр институтына керәсе килсә дә, Ислам университетына барып керде. Бер ел укыганнан соң, Мисырга – Каһирәгә китеп, политология һәм халыкара мөнәсәбәтләр факультетында укуын дәвам иттерү җае чыкты. Китте. Ел саен каникулга кайта да, китәсе килми. Әтисе: «Юк, улым, укып бетерәсең», – дип, чыбыркылап тора. Бер ел йөрде шулай, ике ел, өченче курстан соң, «калам», – диде. Нигә болай эшләвенең серен соңыннан гына белдек: метеорда Казанда яшәүче Эльмира исемле кыз белән танышкан да, аерылышмас хәлгә җиткәч, кайтырга, өйләнешергә сүз куешканнар. Менә бит мәхәббәт нишләтә?! Баштан кичкән инде. Бер сүз әйтә алмадык. Үзебез дә шул күперне кичкән кешеләр ич! Монда кайткач, өр-яңадан БДИ биреп, институтка укырга керде. Хәзер бер уллары бар инде.

Уллары Мөхәммәт турында әниләре. «Кечкенә дигән сүзне әйттертмәде. Гел мөстәкыйль булды. Хастаханәгә дә 6-7 яшьтән берүзе йөри башлады. «Артымнан йөрмәгез, мин бәләкәй түгел», – дип кенә җибәрә иде», – ди. 6 яшьтән спорт белән шөгыльләнсен дә, «кагыйдәсез ярышлар» дип аталган көрәшләрдә беренче урыннарны яуласын да... Җитмәсә, уникаль корылмалар төзүче булачак ул хәзер!

Олы кызлары Ләйсән хәзер гаиләсе белән Сочида яши. «Анысы – үзе бер тарих, – ди әңгәмәдәшем. – Ул да, минем кебек, укыганда өч бала тапты. «Әти, балалар ул – приоритет», – дип кенә җибәрә иде. Хәзер дүрт баласы бар. Икенче баласын табар алдыннан, кызымны: «Даун синдромы белән туачак», – дип куркытканнар. Кызым: «Үтермим баламны, ул минеке», – дип, тәки тапты, Хәдичәбез туды. Теле татарча ачылды. Аллага мең шөкер, тап-таза, исән-сау бала. 5 яшьтән фигуралы шуу белән шөгыльләнә. Диплом алгач, үзенә фирма ачып җибәргән иде. Канада технологиясе буенча күп кенә йортлар да салдырды. Сочига барып, андагы яшәү шартларын, балаларга спорт белән шөгыльләнү өчен мөмкинлекләрне күреп кайтты да, тиз генә җыенып чыгып та киттеләр шунда. Хәзер менә ике ел була инде».

> «Савыт-саба юылмаган, бала пычрак, ә хатын – диванда. Нишлибез? Ошамый икән, үзебез юабыз».

Ике мәдрәсәдә белем алып чыккан кызлары Алия дә инде өч бала анасы.

– Трай тибеп йөрмәделәр, – дип сүзгә кушыласы итә Фәрһад хәзрәт. – Җәй көннәрендә Алия белән Айдар Иске Болгарда төрле вак-төяк саттылар. Ә хәзер үзләренең күчереп йөртә торган арбалары бар, шунда хәләл ризык саталар. Без аларны кечкенәдән йөгертәйөгертә эшләттек. «Тыңламасагыз, бәхетсез буласыз», – дип куркыткан чаклар да булгалады. Баланың гел аркасыннан сөеп утырып кына булмый. Катылык та күрсәтергә кирәк. Шулай диюгә, Рушания ханым көлеп җибәрә. «Каты инде син, әтисе, – ди ул, – бер мәртәбә өч баланы юындырып, урамга чыгарып җибәрдем. Үзем кер юарга тотындым. Берзаман чыксам, өчәүләшеп күмер өстендә уйнап утыралар. Үзләре кап-кара. Кычкырып елап җибәрдем. Ә әтиләре шунда, янәшәдә генә нидер эшләп йөри. «Нәрсә елыйсың, уйныйлар бит алар», – ди. Тагын берсендә, Айдар белән Алияне өйдә калдырып, эшкә киттем. Аларның берсенә – булса шул ике, икенчесенә өч яшьләр тирәсе булгандыр. Чыгып киткәндә, газны яптым, су кранын... Үземчә кирәкле бөтен куркынычсызлык чараларын күрдем шикелле. Эштән кайтып барам, Фәрһад янә ишегалдында нидер эшләп йөри һәм миңа әйтә: «Балаларга тимә, анда әзрәк тәртипсезлек бар», – ди. Өйгә керсәм, чүт артыма авып китмәдем. Шкафтагы бөтен ярмаларны уенчык машинага салганнар да, бер бүлмәдән икенчесенә ташып, көшел итеп, идән уртасына өеп куйганнар. Төрле чаклары булды. Ләкин без балаларга беркайчан да тавыш күтәреп сүз әйтмәдек».

Төпчекләре Фатыйма быел урта мәктәпне тәмамлый. Ул институтка барырга җыена. Әнисенә кайчак: «Миңа әле 18 генә тула. Ә мин инде ун ел бала карыйм», – дип әйткәләп тә ала. Әйе, бер-береңә ярдәм итәсе, булышасы... Әти-әнисе аларны шулай өйрәткән.

Адәм баласы үзенең тырышлыгы белән яши. Иманы нык булса, тәрбиясе төптән чыккан, дөрес, ә иң мөһиме: дин кушканча булса, әллә каян гына бөтен авырлыкны җиңәрлек көче дә, мөмкинлеге дә табыла. Фәрһад хәзрәт әйткәнчә, юлы да ачыла...

PRESSA

Ул дөрес әйтә: тамашачылары аны шаян да, моңлы да Миңнурый аша яратты. «Әбүзәр!» – дип дәшә Миңнурый, шаян елмаеп. «Миңнурый!» – дип җавап кайтара гашыйк Әбүзәр. Ә бит Татарстанның халык артисткасы Зөлфирә Зариф (Зөлфирә Сафа кызы Зарипова) уйнаган рольләрнең һәркайсы татар хатыны дигән олы бер образның әле бер ягын, әле икенче ягын ача. 65 яшьлек матур бәйрәме алдыннан без аның белән артистлык язмышы турында сөйләшеп алдык.



ЗӨЛФИРӘ ЗАРИФ: «БЕЗ ЙӨРӘК БЕЛӘН ЯШИБЕЗ БИТ...»

Зөлфирә апа, Сез татар дөньясында Казан арты дип йөртелә торган шагыйранә якта туып-үскән кыз. Әтнә районының Яңа Бәрәскә авылыннан. Сезнең язмышка аның йогынтысы нинди булды?

– Казанга якын булуыбыз, һичшиксез, сизелә иде. Сөйләмебезнең дә әдәби телгә якын торуы татарлыкның казанында иркен кайнарга мөмкинлек биргәндер дип уйлыйм. Шәһәргә якын яшәвебез аркасында телевизорлар да безгә алданрак килмәдеме икән әле, чөнки мин театрга телевизор аша гашыйк булган кеше. Яшь вакытта идеалга омтыласың бит, ә театр һәрнәрсәне идеаллаштырып, биеккәрәк – сәхнәгә күтәреп күрсәтә. Әнә шулай театрның алдавыч, ялтыравык дөньясына утка омтылган күбәләк кебек килеп эләгәсең инде. Гәрчә дөресе дә шул, читтән караганда гына театр матур, эченә керсәң, анда бөтенесе дә бар.

Театрның «эчен-тышын» күргәннән соң, күңел кайту кебек хисләр булмадымы?

– Юк, беренче тапкыр телевизордан «Ай тотылган төндә» спектаклен карау белән театрга гашыйк булган идем, бу ярату гомерлеккә калды. Яшь чагымда җырларлык тавышым да бар, авылда бөтенесе, җырчы булырсың, диләр иде. 15 яшемдә филармониягә дә барып карадым. Миңа: «Үсмер чакта тавыш үзгәрүчән була, унны укып бетер, аннан соң килерсең», – диделәр. Әмма мин театрга күбрәк гашыйк идем, җырлы тавышым театрда уйнарга комачауламас, киресенчә, ярдәм итәр дип уйладым. Театрга килдем. Соңыннан Айрат Арсланов белән Илгиз Мәҗитов филармониягә чакырсалар да, театрдан китәсем килмәде. Марсель Хәкимович мине академия театрында алып калды – монысы өчен аңа чиксез рәхмәтлемен, чөнки күпләргә андый











бәхет тәтемәде. Коллектив бик ошый, артистларны бик ярата идем. Театрда булуым белән бик бәхетле идем, шуңа күрә аннан бер дә китәсем килмәде.

Театр училищесын тәмамлау белән Казанда калгансыз. Мәскәү ымсындырмадымы?

– Без Камал театрында дүрт кыз калдык: Алсу Гайнуллина, Фирая Әкбәрова, Рузия Мотыйгуллина һәм мин. Ә Мәскәүгә барыр өчен рус телен яхшы белергә кирәк. Без бит инде татарча гына сөйләшеп үскән кешеләр. Билгеле, Мәскәүдә миңа эш күбрәк тә булган булыр иде. Татар театры, ни генә әйтсәң дә, артистның диапазонын чикли. Нигездә, татар кызларын уйныйсың инде анда. Ә рус театрында диапазон киңрәк, анда төрле-төрле образлар уйнарга мөмкинлекләр бар. Шул ук вакытта мин бит инде – чын татар, татар хатын-кызын уйнамый, кемне уйныйм?

Нурсолтан, Расиха, Миңнурый, Мөслимә, Миңзифа… Бу исемлекне тагын дәвам итәргә була әле… Барысы да чын татар хатын-кызы образларын чагылдырган рольләр. Аларның уртак сыйфатларын ничегрәк итеп аерып бәяләр идегез?

– Татар хатын-кызы йөрәк белән яши ул. Авылда үскәннәр бигрәк тә. Чөнки авылда һәрнәрсәне акыл белән үлчәп торырга адәм баласының вакыты юк. Мин әни белән үскән кыз. Минеке генә түгел, күп әниләр шундый иде: алар эмоциональрәк, тиз генә кызып та китәләр, шул арада гафу да итәләр, сабыр да, ярсу да була алалар. Кайберсе үлгәнче түзә, кайберсе юкка-барга чәпчи… Образларны эшләгәндә, әнә шул тормышта очраган татар хатыннарын күздә тотасың да инде. Мин бит үзем дә чын татар хатыны: телем дә, яшәү, фикерләү рәвешем дә татарныкы. Совет чоры балалары булarak, мөселман икәнебезне белсәк тә, дин белән үсмәдек. Урыслашкан якларыбыз да бардыр. Менә чәчемне сарыга буяп йөрим бит әле *(көлә)*.

Телевидение күрсәткәндә, үзегезне видеоязмалардан караганда, эшегездән канәгать каласызмы?

– Юк-юк, мин үземне бөтенләй карый алмыйм. Әмма 10–20 елдан соң караганда, анда яшьрәк буласың бит – әллә шуңа, азрак кына үзеңә ошый башлыйсың.

Иҗат кешесенең уңышы 10 процент – таланттан, калганы тырышлыктан тора, диләр.

– Һәрбер артист – шәхес. Үзеңне узып сикерә алмаган кебек, артист та үз тәртәсеннән ерак китә алмый. Ә менә образларны эшләгәндә, талантына карап, артист бер-берсенә бөтенләй охшамаган образлар тудыра ала. Менә Шәүкәт абый Биктимеров даһи актер иде. Ул миңа – үрнәк. Ул шул ук кыяфәт, шул ук тавыш белән

үзен танып булмый торган әчке образ иҗат итә иде. «Муса Җәлил»дәге – Палач, «Әлдермештән Әлмәндәр»-дәге – Әлмәндәр, «Әни килде»дәге – Ислам – өчесе өч дөнья бит! Берсе – вәхши, икенчесе – циник, өченчесе – аксакал. Һәркайсы камил образлар. Билгеле, мондый рольләрне талант яки тырышлык белән генә иҗат итеп булмый – икесе дә кирәк. Шундый дәрәҗәдә эшли алганда, син үзеңне чын артист итеп хис итә алыр идең. Мин шул биеклеккә омтылам. Ничек килеп чыгадыр – анысы тамашачы хөкемендә.

Кайбер артистлар олыгайгач та каушау-дулкынлануларны җиңә алмый, диләр. Сәхнә артында сез нинди?

– Баштарак мин дә тәҗрибә җитмәүдән, җаваплылыктан куркып кала идем. Үз-үзеңә ошамыйсың, уйнап җиткермисең кебек... Хәзер инде үземне иркенрәк тоям, тәҗрибә үзенекен итә. Аны беркая да куеп булмый (*көлә*).

Һәрбер артистның аны артист буларак ача алган режиссеры була.

– Әлбәттә. Мине режиссерлар яратмады дип әйтә алмыйм. Миңа Марсель Сәлимҗанов та, Празат Исәнбәт тә рольләр бирә иде. Ә инде Дамир Сираҗиев белән без бергә укыгангамы, яшьтәш тә булгангамы, ул миндәге потенциалны күбрәк сизеп, күбрәк күрде, ахры. Чөнки ул миңа, әле яшь булсам да, Миңнурый ролен ышанып тапшырды. Равил абый Шәрәфиев Әбүзәр иде, бергә уйнадык. Мине шушы роль аша таный башладылар, чөнки ул безнең халык ярата торган җырлы-биюле, көлкеле спектакль иде. Аңа кадәр мин Нурсолтаннарны уйнаган, уңай рецензияләр алган актриса идем. Аннан соң Дамир миңа Чыңгыз Айтматов әсәре буенча куелган «Ахырзаман»да Ак бүре ролен бирде, аны да тамашачы яратты. Ул безнең белән «Клеопатра»ны да эшләмәкче булган дип ишеттем, ләкин ул театрдан китеп барган иде инде.

Клеопатра роле үкенеч булып калмадымы?

– Мин бит авыл кызы, мин нинди Клеопатра инде?! *(Көлә.)* Кайчан да булса Клеопатраны уйнармын дип уйлаганым да булмады. Шулай да баш тартмас идем. Нинди булса да, минем Клеопатра булыр иде ул.

Сез бүген Нәҗибә апа Ихсанова уйнаган рольләрне дә уйныйсыз. «Зәңгәр шәл»дә, мәсәлән.

– Әйе, хәзер инде без дә өлкән буынны уйный башладык. Вакыт бара. Аллага шөкер, әле щепкинчылар да үз көчендә. Без аларның эшенә сокланып, уйнауларына кызыгып үстек. Театрга да аларның тарту көче китерде. Барысы минем өчен – кумир. Алардан башка театрның яме китәр кебек. Сүз дә юк, яшьләребез дә бик талантлы, театрыбызда һәркайсы шәхес.

Гаилә тормышыгыз турында да бер-ике сүз әйтегез инде.

– Мин алты балалы гаиләдә-туып үстем. Безне үги әни тәрбияләде, мин аңа бик рәхмәтле. Абый мин беренче сыйныфта укыганда армиягә китте, шуннан бирле гаиләдә ир заты күргәнем булмады. Шуңа күрә дә ирләр белән ничек «идарә итәргә» кирәген белмим. Сигез ел опера җырчысы Сәет Рәинбәков белән яшәдем, ләкин без аерылыштык. Ике ул үстердем. Бер улым мәрхүм булды. Бүгенге көндә ялгыз яшим. Ләкин мин ялгызлыгымнан зарланмыйм, аның да үз рәхәте бар. Ничек кенә булса да, кеше барыбер түзә ул.

Сез Казанның үзәгендә яшисез. Зур шәһәр арытмыймы?

– Казанны бик яратам. Әтнә театры ачылгач, Зөлфирә апа, безнең театрга кайтмыйсызмы, дип шалтыраттылар. Юк, мин хәзер авылда тора алмыйм, миңа шәһәр шау-шуы җитмәячәк, дип җавап бирдем.

Без әле артистларны илаһи, серле затлар итеп күреп өйрәнгән буыннан.

– Артист күз алдындагы кеше инде ул, аның турында гайбәте дә, буш сүзе дә күп. Алар турында гади кешегә караганда күбрәк сөйлиләр.

Гомумән, артистның эчендә азмы-күпме даншөһрәткә омтылу утыра. Ул баштарак сәхнәгә чыгарга кыюлык бирә. Үзен күрсәтү теләге булмаса, кеше сәнгатькә килмәс иде, чөнки аның күренәсе, ялтырыйсы килә. Еллар үтә-үтә бу омтылышның мәгънәсе югала, кирәге калмый, ул хис үтә, эреп югала. Миңа, мәсәлән, ул кирәкми. Мактану, дан-шөһрәткә табыну кебек сыйфатлар, киресенчә, тискәре мөнәсәбәт уята. Талантлы артист йолдызланмый, гадәттә, урта куллар кыланырга яратучан була.

Шулай да сәхнә сәнгате артисттан туктаусыз эзләнүне, үзен гел искә төшереп торуны таләп итә.

Үземне күрсәтәсем килсә, ныграк тырышкан булыр идем. Мине күрсеннәр, дип, бәлки, рольләр сорап йөрергә дә кирәк булгандыр. Ләкин андый гадәтем булмады. Роль бирсәләр, эшләдем, бирмәсәләр – юк. Шулай да бер үкенечем калды... Мәскәүдән килгән режиссер мине икенче составка Катарина итеп алмакчы булган (Шекспирның «Укрощение строптивой» пьесасы буенча), ләкин Марсель ага риза булмаган.

Театр шундый бер организм инде ул, бөтен нәрсә дә чагыштыруда күренә. Артист бик күп нәрсәләргә, кешеләргә бәйле. Режиссер роль бирәме, юкмы дип көтеп торасың. Бирсә, шатланасың. Күрми калсалар, түзәсең. Башка бер урында эш бирмәсәләр, кеше шатланып кына йөрер иде. Ләкин театрда эшлисе килә. Зарланган юк анысы, үзем сайлаган язмыш бит.

Сезнең кино сәнгатендә дә тәҗрибәгез бар бит әле. «Неотложка»да уйнаганыгыз хәтердә.

– Ул вакытта хезмәт хакларын вакытында бирмиләр иде, акча эшләп алу өчен төшкән кино ул. Татар киноларында да төшкәләдем. Баш тарткан чаклар да булды. Хәзер инде бөтен рольгә ябышып яту юк, җаныңа туры килгәнен генә сайлыйсың, үз рәхәтең өчен уйныйсың.

Бүген нинди теләкләр белән янып яшисез?

– Улыма, аның гаиләсенә, гомумән, бөтен кешегә исәнлек-саулык телим. Шулай ук театрыбызга уңышлар телим. Тамашачыларны спектакльләребезгә чакырып калам. Аларның театрга йөрүе – зур бүләк.

Әңгәмәдәш – Ландыш ӘБҮДӘРОВА.

КАЙНАНАМ ИРЕМНЕ МИҢА КАРШЫ КОТЫРТА

«Кияүгә чыкканыма ел да өч ай. Ирем белән бик яратышып өйләнештек. Тик хәзер көн тудымы: «Әллә аерылып китим микән?» дип уйланам. Болай уйлавымның сәбәпчесе – кайнанам. Ул иремне миңа каршы котырта. Очрашып йөргәндә, булачак иремнең әти-әнисе белән таныштым, мине бик яхшы кабул иттеләр. Өйләнешеп яши башлагач та әнкәй (иремнең әнисенә беренче көннән үк шулай дип дәшә башладым) белән мөнәсәбәтләребез әйбәт иде. Күпмедер вакыттан соң иремне алыштырып куйдылармыни. Юк-барга да бәйләнә, пешергән ризыгымны ошатмый, тоткан акчамны тиенләп саный башлады. Бактың исә, аны шулай эшләргә әнисе котыртып кайтара икән! Нинди генә темага сөйләшә башласак та, ирем әнисен телгә алмый калмый: «әни болай дип әйтте», «әни ул диванны алмаска кушты», «әни әле сезгә бала алып кайтырга иртәрәк диде». Бер тапкыр кунакка килгәч, үз тормышыбызны үзебез хәл итсәк иде, дип, җайлап кына әнкәйгә әйттем. Ул аны иремә җиткергән. Билгеле инде, тавыш чыкты. Хәзер әнисе аркасында көн саен диярлек кычкырышабыз. Кайнанам белән ничек көрәшергә белмим...»

И.

Казан шәһәре.

Ландыш ФӘРРАХОВА, 48 яшь:
– Кияүгә чыгып, кайнана белән бер түбә астында яши башлавыма 25 ел. Шушы 25 ел эчендә кайнанамның мине игәүләми калган бер көне булдымы икән? Яшьрәк чакта «бер эш эшли белмисең» дип ачулана иде. Яңа гаиләгә килгәч, андагы тәртипләрне белеп тә бетермисең бит әле. Өйрәтүче дә булмады, барысына да үзем өйрәндем. Хәзер исә кайнанам йә «ашыңның тозы юк» дип, йә «урын-җирне дөрес юмагансың» дип, йә башка берәр сәбәп табып бәйләнә. Үзенең күзләре дә начар күрә башлады инде, минем кулга калып бара, үзе һаман минем кимчелегемне эзли. Ә мин дәшмәдем, хәзер дә дәшмим. Бәлки, яшьрәк чакта бер утырып сөйләшсәсе, аңлашасы булгандыр, дим. Хәзер сөйләшәсе дә килми инде. Ирем дә дәшмәде. Тавыш чыга башласа, тизрәк өйдән чыгып китү ягын карый иде. Ул кистереп үз сүзен әйтсә, бәлки, барысы да башкача булган булыр иде.

Шушы көннәрдә үзебезнең улыбыз өйләнергә йөри. Киленемне җәберләмәм, аны үзем яшәгән көнгә калдырмам, дип, үз-үземә кат-кат вәгъдәләр бирдем инде.

Риназ КАМАЛЕТДИНОВ, 25 яшь:
– Мин үзем әле өйләнмәгән. Иң куркканым – әни белән хатын арасында калу. Ике кадерле кешең үзара дус булмаса, тыныша алмаса, бик начардыр ул. Югыйсә проблема ясарга да кирәкмидер кебек бит инде. Әни әни инде ул, ә хатын – хатын. Тик без, ир-атларга, хатын-кыз мантыйгын аңлау кыенрак шул.

Әгәр инде шундый хәл килеп чыккан икән, ир-ат икесе белән дә утырып сөйләшергә тиеш дип уйлыйм. Нәрсә ошамый аларга бер-берсендә – шуны ачыкларга. Әнигә: «Әни, бу – минем яраткан кешем, хатыным һәм мин тормышымны аның белән корырга булдым. Бәхетле булуымны теләсәң, мине аңларга тырыш, бәхетемә комачаулама – ярдәмче бул», – диярдем. Ә хатынга: «Әйе, мин хәзер синең белән, мин сине яратам, тик әнинең урыны – аерым. Ул миңа тормыш бүләк иткән кеше. Шуңа күрә мин аны калдырып китә дә, аңа авыр сүз әйтүеңне күтәрә дә алмыйм», – дип аңлатырга була.

Ә инде сөйләшү дә ярдәм итмәсә, икегә ярылырга туры киләчәк. Әниең белән хатыныңны очраштырмаска тырышырга, шул ук вакытта икесенә дә җитәрлек игътибар бирергә.

Өч фикер



Ләлә БӘҺРАМШИНА, психолог

– Хат авторы «Кайнанам белән ничек көрәшергә белмим» дигән. Беркем белән дә көрәшергә кирәкми. Яхшылап сөйләшергә, аңлашырга, килешергә кирәк. Кешеләр бер-берсен, бу очракта кайнана – киленне, килен кайнананы гаепли, бер-берсе белән көрәшергә кирәк дип саныйлар икән, димәк, алар сөйләшә, аңлаша белмиләр. Кешенең табигате шундый: без аңлашуга мохтаҗ. Сүзләр ярдәмендә аңлашумы ул, күз карашы ярдәмендәме, әллә җилкәгә кагылып алу рәвешендәме – мөһим түгел, контакт кына булсын. Психология телендә «Мин-хәбәр» һәм «Син-хәбәр» дигән нәрсәләр бар. «Мин-хәбәр» кешегә үтемлерәк тәэсир итә, йомшаграк та яңгырый. Шуңа үзеңнең теләкләреңне, ихтыяҗларыңны, борчуларыңны «Мин-хәбәр» («мин шулай теләр идем», «миңа мөһим» һәм башкалар) аша җиткерергә өйрәнергә кирәк. Болай сөйләшү кешене хөрмәт итүеңне дә күрсәтә. Ә инде «Син-хәбәр» («син шулай эшләргә тиеш», «сиңа шулай эшләргә кирәк» һәм башкалар) эмоциональ кабул ителә.

Без күпчелек очракта үзебезне теләгәнебезне әйтмибез, кешеләр безне сүзсез дә аңларга тиеш дип уйлыйбыз. Тик тел белән әйтмәгәнне үтәүләрен көтү – дөрес түгел. Син әйтмәгәч, синең нәрсә теләвеңне, нәрсә хис итүеңне, нәрсә уйлап йөрүеңне башкалар ничек белсен?! Шуңа күрә кара-каршы утырып сөйләшү, аңлашу мөһим, дибез. Кеше белән сөйләшкәндә, аңа кимендә өч плюс (уңай дәлил) бирергә кирәк. Әйтик, килен – кайнанага: «Әни, мин сезнең фикерне хөрмәт итәм, сезнең тормыш тәҗрибәсе зуррак, улыгызны яратуыгызны аңлыйм», – дия, шуннан соң «Мин-хәбәр»не («мин менә болай теләр идем», «мин болай эшләгәндә шуны күздә тоткан идем») җиткерә ала. Шул рәвешле үзенә карата хөрмәт сизгән кайнана да киленен тыңларга, ишетергә, аның белән килешергә мәҗбүр булачак, үзендә дә киленгә карата хөрмәт уяначак.

Фәннур Сафин… Шигырьләре сагыш-моң булып керә дә мәңгегә күңелдә кала. Алар хисле, җылы, якты. Ал чәчәкле, ак буранлы, ай-йолдызлы… Алар – җыр сорый! Ниһаять, җырлый да!.. Җыр булып киткән шигырьләрен генә искә төшерегез: «Ил кызларына», «Безгә дөнья дәшә», «Җырымда юатырмын», «Моңланма», «Ялгыз көймә», «Хушлашырга ашыкма»… Яшьли арабыздан китеп, мәңгегә лирик шагыйрь булып калган Фәннур Сафинны бүген үзенең җыр юллары белән юксынабыз:
Гомер буе ярсу йөрәк / сине сагынып сулкылдар…

Фәннур
САФИН

ҖЫР БАГЫШЛЫЙМ СИҢА…

Нишләттең?!

Кинәт миңа арыш басулары,
киң болыннар шундый кадерле!..
Иделемә карыйм,
күзләремне
алалмыйча таңга кадәрле.

Йөрәгемне нидер чәнчеп ала,
алтын көннәремне сагынам…
Керфектәге ут шар аша багам
алсуланган офык ягына.

…Тыныч кына гомер кичкән чакта
шатлык-кайгыларны ишәйттең;
күкрәгемдә йөрәк барын тоям!..
Мәхәббәт, син мине нишләттең?!

Әнкәй!..

(Бер көндәлектән)
Үз илем бар, рәхмәт, әнкәй!
Үз телем бар, рәхмәт, әнкәй!

Дөньяларда ямьнәр табып,
дулкынланып, ярсып-янып
яшәү шундый рәхәт, әнкәй, –
барсы өчен рәхмәт, әнкәй!

Ризык биргән,
гомереннән
өзеп биргән син үк, әнкәй…
Ләкин бөтен рәхмәтләрне
ничек әйтим? –
Син юк, әнкәй…

* * *

Моңа кадәр, сылу, кайда булдың,
әллә мине көтеп айда тордың?..

Йолдызлардан гына төштең мәллә?
Шундый самими син, шундый садә.

Бер агачның ике тамыры без,
бер үк кайгы белән кайгырырбыз.

Бир кулыңны, бергә китик әле,
бер бәхетне ике итик әле!

* * *

Яттан шигырь сөйлисең син,
Сөйлә, сөйлә, акыллым!
Матурлыкны сөям, дисең,
Мин дә сөям, матурым!..

Дөнья аңлашылмый, диеп,
Учакка текәләсең.
Аңламыйсың?
Югыйсә бит
Йөрәккә үтәләсең!

Дөрләп яна учагыбыз,
Син шуңа сөенәсең.
– Җә, тот, куып җит! –
дип кинәт
Аланнан йөгерәсең.

Ак каенны кочып алып,
Йолдызга үреләсең.
Син бит менә шулай минем
Дөньяма әвереләсең!..

Сүндералмам учакларның
Җанга күчкән ялкынын,
Һәрбер сүзең, хәрәкәтең
Шигырь синең, акыллым!

* * *

Инде күпме сиңа яз булып та,
Таң булып та сөйләп карадым.
Дулкын булып билләреңнән кочтым,
Җилләр булып чәчең тарадым.

Йолдыз алып бир дип
әйтә калсаң,
Алмас идеммени үрелеп?
Бу хәлләрне гомер буйларына
Кыйсса итеп сөйләп йөрерлек.

Бер син генә аны белмәгәч тә,
– Кайтсана?! –
дип күпме җан аттым…
…Әверелдем хәзер тик өч сүзгә:
«Яраттым!»
«Яраттым!..»
«Яраттым…»

Туй

Коеп яңгыр ява, ява,
бу соң нинди төн икән?
Ник урамга чыгып елый,
ник елый ул, кем икән?

Күз яшенә манчылгандыр
инде туй күлмәге дә...
Бармагында балдагыдыр,
юатыйк ничек кенә?

Кеше елый...
юк, юатма!
Бер сүз әйтмә син аңа!
Пар тапса да,
яр югалткан
кешеләр бар дөньяда...

Туган җиркәй, исәнме!
Тугайлы да, тургайлы да,
чишмәле як, исәнме!
Гөл-чәчәкләр исен төяп
җылы җилләр исәме?

Мәңге яшел наратлар һәм
аксакаллар, исәнме!
Җаным яшәргәндәй була
сезгә кайтып килсәм бер...

Картлар кебек сабыр як бу,
күп хәвефләр кичкәнме?
Әй, борынгы таңнар иле –
Туган җиркәй, исәнме!

Кичегү
Кичегәбез кайчак бер мизгелгә,
ә кайвакыт гомер буена.
Кичегәбез әткәй үлеменә
йә бердәнбер ярның туена.

Кичегәбез...
Йолдыз нуры кебек,
соңга калып килә шигырьләр.
Сокланып шул нурга үрелгәндә,
ут эчендә була гомерләр...

Кемнәр килер, нинди куллар белән
бәйли алыр күңел ярасын?
Ә хәзергә Җирем йоклый кочып
хакыйкатьне – күкрәк баласын...

Яратам
Юлга карап
күз нурларың коясыңмы?
Безне эзләп ай моңлана, тоясыңмы?
Яшьлек эзе буйлап,
Йөгерә-йөгерә уйнап,
Тугайларда ал чәчәкләр җыясыңмы?

Сине сагынып дулкын ярны
кыйный бугай,
Уйчан таллар сине генә
уйлый бугай.

Син гел минем истә.
Беркем тапмас төшкә
Нигә качтың, кая качтың соң
син шулай?

Яратам мин сине генә, сизәсеңме?
Кем уйлаган
синең чынлап сөймәсеңне?
Сиңа килсәм тагын,
Кулым бирсәм, җаным,
«Мин башканы яратам шул»
димәссеңме?

Ярату
Минем өчен генә тудыңмы син,
Минем өчен генә үстеңме?
Минем өчен мәллә, минем өчен
Башка галәмнәрдән күчтеңме?

Һәр кайгымны минем бүлешәсең,
Һәр сүземне әзер тыңларга.
Шуңа күрә, бары шуңа күрә
Елмаюың охшаш таңнарга.

Таңнар алар һаман матур булмый,
Син булганда гына таң матур.
Шуңа күрә, бәлки, шуңа күрә
Таңнарым да сине яратыр.

Җыр багышлыйм сиңа
Җыр багышлыйм сиңа,
җыр багышлыйм,
тик сине сөям дип алдавың өчен;
төн шикелле кара күзләрең белән
йөрәгемә хәнҗәр кадавың өчен.

Җыр багышлыйм сиңа, күзләремне
күтмәгәндә килеп каплавың өчен;
йә бөтенләй мине күрмәгән кебек
җиде ятлар белән атлавың өчен.

Җыр багышлыйм сиңа,
җыр багышлыйм,
син дә моңлан,
җавапсыз мәхәббәтем;
һәрбер авыруга шифам син минем,
үзең мәңге
йомылмас җәрәхәтем.

Җыр багышлыйм сиңа,
җыр багышлыйм,
таңда былбыл булып
сайравың өчен;
минем кебек һәркем шулай
шатлыкка,
буй җитмәс бәхеткә юрасын
төшен!

Моңланма
Тулган айга карап,
чәчләреңне тарат,
моңсу җырлар ләкин җырлама.
Сиңа карыйм да мин,
күзем ала алмыйм –
мин моңланмыйм,
җаным моңлана...

Бердәнберем идең,
«Син – бәхетем», – дидем,
үз бәхетеңә инде соңлама.
Ак моңнарым булып
янадыр ай тулып, –
мин моңланмыйм, йөрәк моңлана...

Юкка гына түгел,
сагышлана күңел,
ул ашкына ерак елларга.
Күз яшьләрен яшер,
ара ерак хәзер,
тик моңланма, күңел, моңланма...

Бу бит туган яктыр,
тирә-ягың матур,
чыкмасаң да озын юлларга.
Тугайларга дәшеп,
җырлап килә яшьлек,
шуңа күрә син дә моңланма!

Хушлашырга ашыкма
Хушлаштың да китеп бардың.
Аерылу авыр бит!..
Күзләреңнең моңын
йөрәгемә салыйм,
тукта, дустым, сабыр ит!

Гомер буе ярсу йөрәк
сине сагынып сулкылдар...
Иделләрдә дулкын, –
чү, ашыкма, дустым! –
Күңелдә ул дулкыннар!..

Сайрар кошлар синсез нишләр,
ничек агар бу сулар?
Урман ничек шаулар,
ишелмәсме таулар? –
Икебез дә моңсулар!..

PRESSA



Нурания
ТӨХБӘТУЛЛИНА

АХИРӘТЛӘР

(Хикәя)

Балкып торган кояшлы көннәре, сихри айлы кичләре белән яшел язлар, ямьле җәйләр шаулап-гөрләп үткән дә киткән, сизелмәгән дә. Алмашка озын-озакка сузылачак көзләр килгән. Көзләр диген... Көзнең аның картайган сөякләрне җылыга тиендерә торган әбиләр чуагы дип аталган кояшлы атнасы да, көне буе салкын яңгыр пыскаклаган эчпошыргыч көннәре дә була. Ә аннан инде ак кәфенле кышларга да ерак калмый. Ә хәзергә... хәзергә рәхәт әле. Кояш җәй көннәрендәгечә кыздырмый, иплэп кенә, чамасын белеп кенә илаһи нурлары белән җир өстен сыйпап иркәли.

Профнастил койма буенда сарыга буялган агач эскәмиядә ике карчык та шушы рәхәт җылыга изрәп утыра. Берни сөйләшмичә оеп утырган җиреннән карчыкларның каратут йөзлесе үз-үзенә сөйләнгәндәй генә әйтеп куйды:

– И-и, ахирәткәем, көннәре бигрәкләр дә матур тора, җиле-мазары да юк, җәйләр әйләнеп кайткандай.

Бераз тын тордылар. Икенче карчык, җавапсыз калуны килештермәгәндәй генә, тик нигәдер авыр сулап:

– Үткәннәргә кайту юк инде ул... Әйе... ә көне сөбханалла, – диде.

Тагын тынып калдылар. Хәер, аларның сөйләшер сүзләре дә юк кебек. Әйтеләсе әйтелгән, яңалыклар алышынган, серләр бүлешенгән дигәндәй. Шул көн дә үзгәреп тора торган һава торышы турында гына сүз алышсаң инде. Ә, юк, сөйләшер өчен бер дә бетеп тормый торган тема бар икән бит әле. Балалар! Менә кемнәр турында сөйләшеп сүз бетми. Уллар, кызлар, киленнәр, кияүләр, оныклар. Мәңгелек тема. Карчыклар да бәгырь кисәкләре – балалары турындагы сүзгә күчтеләр. Каратут йөзлесе – ул Сабира исемле иде:

– Әле бүген иртәнчәк Галинурым шалтыратты. Кырымда ял итә алар. Монда хәзер бик шәп вакыт, «бәрхет сезон» дип атала ди. Бездә дә, мин әйтәм, көннәр кояшлы тора, диңгезе генә юк... Исән-сау йөреп кайтсыннар инде балакайларым, – дип куйды.

– Соң әле син, Галинурым – утырган тавык кебек, Казаныннан беркая кузгала алмыйча китап яза, дип сөйләгән идең түгелме соң? – дип, Шаһидә беркөнге сөйләшүне искә төшерде.

– Әйе, әйе, Кырымда да шул «Мемуар» дигән китапны яза инде. Монда кайтып китәргә дә вакыт таба алмый балакаем. Синекеләр генә ул, эшләре беткәндәй, атна саен өерелешеп кайтып җитәләр.

– Эшләре бетмәгән инде бетүен, – дип куйды Шаһидә карчык, бераз үртәлеп. – Соң, синең дә кызың, безнекеләр кебек, район үзәгендә генә яши бит. Бу араларда бер дә кайтканы күренми, – дип өстисе итте.

– Әйтмә сана... – Сабира авыр көрсенеп алды. – Беләсең бит инде аның айга бер генә тапкыр – мин пенсия алган көнне генә кайтып киткәнен.

Бер-берләренә төртмәле сүзләр әйтешкәннәренә үкенгәндәй, икесе дә тынып калды. Шулай сүзсез генә озак утырдылар. Кояш та сүрәнләнә төште. Шаһидә карчык: «Ахшамга соңга калмыйк тагын», – дип, җәһәт кенә торып басты. Ахирәте дә, биле авыртуга, аяклары оюга зарланып, ахылдап урыныннан кузгалды.

Ястү белән витр намазын укып, тынычлап кына йоклап китәргә җыенган Шаһидә карчыкның бүген никтер керфегенә йокы эленмәде. Ахирәтенең, Галинурым Кырымда китап яза, дип мактануымы, синекеләр өерелешеп кайтып җитә, дип көнләшебрәк әйтеп куюымы, белмәссең, нәрсә борчыды аны.

Әй бу дөнья, бу гомерләр, бу язмышлар!.. Ә бит отставкадагы полковник Галинур (Галинур булмаса, башка исемле ул) аныкы булырга мөмкин иде. Мөмкин иде... Явыз язмыш шул бәхеттән мәхрүм итте. Алай да бәхет дигәненең бер чите, әгәр аны бәхет дияргә яраса, тиде аңа: ул авыр эш, исерек ир күрмәде, юклыктан интекмәде; алар карты белән менә дигән чибәр, тәүфыйклы кыз үстерделәр, менә хәзер яраткан әни, дәү әни булып, карты белән тигезлектә, кадер-хөрмәттә яшәп яткан көне. Ә ахирәте юлдан язган кызы өчен ут йотып яши. Чәчләре вакытсыз чаларган, гәүдәсе көянтә сыман бөгелгән, кайчандыр гөлчәчәктәй булган йөзе аяк астына салып тапталган чүпрәккә охшап калган Сабирага шул гына җитмәгән иде диярсең. Дөрес, еллар Шаһидәне дә аямады: ялтырап торган коңгырт куе чәчләренә бәс сибелде, ап-ак биек маңгае сырланды, куе зәңгәр күзләре тоныкланды, чия иреннәренең җете кызылы уңды, төп-төз гәүдәсе бераз чүкте, горур башы иелә төште.

Их! Бар иде аның чәчкә чаклары! Юкка гынамыни авылның бер дигән егете – гармунчы, көрәшче, шофер – Бөркет Тимергалие аңа үлеп гашыйк булды. Шаһинәм дип кенә иркәләп эндәшә иде ул аңа. Тимергали! Шаһидәнең күңелендә мәңге яшь, чибәр булып саклanучы сөйгән яр! Нәкъ җырдагыча.

Шаһидәләр буынының күбесен сугыш аерды. Тик аның сөеклесен сугыш алдыннан рәхимсез язмыш тартып алды. Карчыкның хәтерендә үткәннәр кино тасмасындагы сыман берәм-берәм җанлана башлады. Менә алар ике дус – Сабира белән Шаһидә, чырык-чырык килеп, гөрләшеп, курчак уйнап утыралар. Күп тә үтми, пардан киенгән ике кыз бала, чүпрәк букчаларын асып, җитәкләшеп, мәктәп юлыннан атлый. Бер парта артында утыралар, концертларда парлашып бииләр; үсә төшкәч, урман-кырда җиләк җыйганда, тырма күтәреп, колхозның печән эшенә йөргәндә, яшьлекләренә аяк басып, клубка чыкканда дисеңме – алар аерылгысыз: ике тирәк бер төптә, ике төймә бер җептә, дигән кебек.

Тик тормыш дигәнендә борылышлар күп икән. Җиденче сыйныфны тәмамлауга, Сабира Казандагы туганнарына бәби карарга китеп барды. Шаһидәнең, китмә инде, дип ялынуына ул җавабын да әзерләп куйган:

– И-и ахирәткәем, укыганым җитеп торыр. Миңа хәзер ничек тә паспортлы булу җаен кайгыртырга кирәк. Бер-ике елдан эшкә урнашып, өс-башымны карармын дим. Матур итеп, кешене ах иттерерлек итеп киенәсем килә. Туйдым бу фәкыйрь тормыштан! Бер әнигә өч бала бит без. Әле дә укытты инде!

...Еллар йөгерә тора. Менә инде Шаһидә медицина училищесының соңгы курсында укып йөри. Авылы, әти-энисе, Тимергалие сагындыра. Әле ярый бәйрәмнәр бар. Бу юлы да, Октябрь бәйрәменә кайтып, рәхәтләнеп ял итәргә, көзге караңгы кичләрне сөйгәне белән үткәрергә җыенган иде кыз. Тик ул уйлаганча ук булып бетмәде: Тимергали колхоз йомышы белән Казанга киткән булып чыкты.

Шаһидә китәсе көнне Казаннан Сабира кайтып төште. Ишектән җил кебек ашкынып килеп тә керде, дустын кочып алып: «Ахирәткәем минем, бигрәкләр сагындым үзеңне!» – дип, зыр-зыр әйләндерергә дә кереште. Аннан, бераз читкәрәк китеп, Шаһидәне беренче күргәндәй карап торды да: «Һаман шул биш былтыр тектергән күлмәгеңнән йөрисең икән», – диде. Дус кызының пальто, шәлләрен дә күздән кичерде. – Ник әзрәк өс-башыңны юнәтмисең? Болай булса, Тимергалиеңнән колак кагуың да бар, – дип шаярткандай итте.

– Йөрәккә түгел, күлмәккә генә карап яратса, китсә дә, елап калырлык егет булмый инде ул, – дип җаваплады Шаһидә.

Кызлар гөрләшкән арада, Шаһидәнең әнисе Хәсбиҗамалттәй чәйгә дәште. Шаһидәнең укуы, Сабираның мех комбинатындагы эшләре турында сөйләшә-сөйләшә чәй эчтеләр. Сабираның әле йомышы да бар икән.

– Хәсбиҗамалттәй, – диде ул, – тирә-юньдә синнән дә оста палас сугучы юк инде ул. Миңа да 25-30 аршын палас сугып бирә алмассың микән? Ярган чүпрәкләрем шактый җыелды инде. Унлы кәтүк җепләре дә алып куйган идем.

– Кара әле, кем, Сабира кызым, хәзер көннәр бик караңгы тора, язга чыккач, боерган булса.

– Юк-юк, Хәсбиҗамал түти, миңа ашыгыч, шушы ай ахырына кадәр кирәк, зинһар, ярдәм ит инде, буш итмәм.

– Нинди бик ашыгыч хәл соң әле ул? Кияүгә сорарга килделәрме әллә?

– Әлегә килүен килмәделәр дә. Ни бит, кыз кешенең кырыгыннан диләр, өшәнчек әзерләү турында. Ә миңа, үзең беләсең, тиздән егерме тула.

Сөйләшү – Сабираның инәлеп ялынуы, Хәсбиҗамал түтинең, ниһаять, ризалашуы белән тәмамланды.

Яңа ел алдыннан имтиханнарга әзерләнергә бирелгән дүрт көнлек ялда Шаһидә коштай очып авылларына кайтты. Юлы да уң килеп торды: укудан чыгу-

га, Алабугадан Бондюгка кадәр курсташы – керәшен кызы Валя белән җәяүләп кайтып, шуларда кунды. Икенче көнне Бондюгта күрше авылның май заводы машинасы очрап, шуңа утырды да күрше авылдан, ун чакрым араны тәпиләп, караңгы төшкәнче кайтып та җитте.

Әнисенең, мунча кергән килеш чыкмасаң да ярар иде, дигәненә колак та салмый клубка йөгерде. Клуб яшьләр белән шыгрым тулы, тик Тимергали генә күренми. Күңеле кителгән кыз кәефсез генә берничә уенга катнашты да өенә юнәлде. Аяк астында кар шыгырдый. Күктә томан сыман бөҗра белән әйләндереп алынган ваемсыз ай йөзә, аңа синең борчылуың ни дә, шатлыгың ни. Бу нинди хәл соң әле? Соңгы атналарда Тимергалидән хат-хәбәр булмавы да кызның эчен пошыра, җанын өзгәли иде. Ул ни уйларга да белмәде.

Капка төпләренә җитәрәк, аны кемдер куып җитте. Борылып караса... Тимергали! Кич бердән яктырып, ай, йолдызлар балкып яна башлады, дөнья көмеш нурларга күмелде.

– Исәнме, Шаһидә, – диде егет әкрен генә, тик сөюдән балкыган кызны кочагына алырга ашыкмады. Алар гомер булмаганча сүзсез-нисез тордылар. Бераздан Тимергали авыр итеп сулап куйды да ничектер пышылдап диярлек:

– Мин өйләнергә булдым, – диде.

Башлары әйләнеп киткән кыз бәхет тулы күзләре белән аңа бакты. Менә нигә үзен уңайсыз, хәтта сәер тота икән сөйгәне! Ул тәкъдим ясарга җөрьәт итми йөргән ич. Риза, бик риза ул. Алты айдан аның укуы да бетә. Никах укытырлар, матур итеп туй ясарлар. Үзен күкнең җиденче катында итеп тойган гашыйк кыз «Мин риза!» дияргә өлгермәде, Тимергалие әллә ничек бик авыр итеп:

– Башка кызга, – дип әйтеп салды да ашыгып китеп тә барды.

Өстенә бозлы су ташкыны ишелеп төшкәндәй, өнемме бу, төшемме дип катып калган Шаһидә бик озак аңына килә алмый торды. Аннан, тезләре калтырап, хәлсезләнеп, капка баганасына сөялде. Бер уйсызнисез торды да торды. Кышкы суык җелегенә үтеп, калтырата башлагач кына, аңына килеп, үксеп елап җибәрде. Бу коточкыч хәбәр аның башына сукты, йөрәгенә без кадады, тынын кисте. Дөрес ишеттеме соң? Шаяртмадымы ул? Кыз, капка баганасын кочкан килеш, үксеп-үксеп елады. Тирә-юньдә котып салкыны, бушлык, ак карлар каралган иде.

Әнисенең: «Сабырлар итсәнә, кызым, ал бәхетең югалмасын. Кемгә барып, ни күрәсеңне белгән юк», – дип юатулары гына ярдәм итми иде шул яры ташлаган кыз балага. Ә инде Тимергалинең Сабира белән никахлашуы Шаһидә өчен җир тетрәүгә тиң булды. Ул тәмам аяктан егылды, акылын җуйган кешедәй тирә-юньне аңламас хәлгә килде. Әнисе, түбән очка төшеп, Камәрия абыстайны алып килде. Абыстай нindидер үлән чәйләре кайнатып эчерде, аннан догалар укып, кызны өшкерде дә: «Бу дөньяда беркемне дә, бернәрсәне дә артык яратырга ярамый, чама хисен саклау зарур. Егетеңне булдыра алганча кичерергә тырыш. Адәм хатадан хали түгел. Ул – бәхетсез җан. Вәгъдә бозган – яшь кояр, ди безнең халык. Ә син укы, тырыш, тәүфыйгыңны югалтмасаң, бәхетең сине үзе эзләп табар», – дип юатып китеп барды.

Имтиханнарына соңга калып килгән Шаһидә, кызарынып, әнием авыр хәлдә иде, дип алдашырга мәҗбүр булды. Дусты Валяга исә, күз яшьләрен түгә-түгә, дөресен сөйләп бирде.

– Яраткан кеше бу рәвешле хыянәткә бара алмас иде, әллә Сабира дигәнең балагa узды микән? – дип куйды Валя.

– Һич белмим, андый сүз ишетелмәде, – диде үзе дә икеләнә калган Шаһидә.

Тирә-юньгә чәчәкле болыннарның хуш исләре таралган ямьле июнь урталарында Шаһидә, диплом алып, авылына кайтты. Ул эшкә каядыр читкә – башка җиргә урнашырга тели иде, тик аны үз авылларына билгеләделәр. Авыл зур, балалар күп туа, авырулар да әз түгел, фельдшерга эш җитәрлек, диделәр.

Шаһидә, вазыйфасына керешеп, бер атна да эшли алмады, «Сугыш!» дигән дәһшәтле хәбәр дөньяның астын өскә китерде. Тимергали дә машинасы белән фронтка китте. Хәсрәткә баткан авыл өстенә үлемнең, ачлык-ялангачлыкның, ятимлекнең шомлы күләгәсе җәелде. Дарулар җитмәүдән, авыруларның күплегеннән, үлем каршында чарасызлыктан Шаһидәнең куллары салынып төшкән чаклар да аз булмады, тик ул хәленнән килгәнчә тырышып, хәтта хәленнән килмәстәйләрне дә хәл итәргә омтылып эшләде дә эшләде.

Хәтеренә җуелмаслык булып кереп калган хәл ноябрь ахырында булды. Ачы җилле ямьсез кич иде ул. Соң гына Шаһидәне чакыра килделәр. Сабира инде тәүлеккә якын бәбили алмый интегә икән. Тимергалиләрнең йорты авылның бөтенләй башка очында булганга, кызның Сабираны күптән күргәне юк иде. Өйдә аны бетәшкән карт белән карчык, аларның төпчек кызлары, кендек әби каршылады. Чаршау белән бүлеп куелган түр сәкедә Сабира ыңгыраша иде. Аның елап, шешенеп беткән, агарынып калган чырае күптәннән чиләнгәнен әйтеп тора. Кичә, фельдшерны чакырыйк, диюләренә, ул мине хастаханәгә озатыр дип, риза булмаган. Бөтен хатыннар да өйдә бәбили, мин дә өйдә генә табармын әле, дигән.

Хатынның хәле харап иде: бала аркылы ята. Кендек әбисе баланы тиешле рәвешкә китереп борырга маташкан булса кирәк, хәзер дә шулай эшләмәкче булды, тик Шаһидә аны: «Кирәкми, баланың үлүе бар», – дип туктатты. Ашыгыч рәвештә район үзәгенә – тимер юл хастаханәсенә барырга кирәк иде.

Бригадир янгын сүндерү бүлегенең атын биреп торудан катгый рәвештә баш тартты. Колхозның башка хәлсез атларын җигеп юлга чыгарлык түгел иде.

– Әнә ЗИС-5 машинасы белән барыгыз, – диде ул. «Ул беткән иске калтырчаны кем йөртә соң? Шоферы фронтта бит», – диюгә, бригадир:



Рәсем: Наталья Васильева

– Кем булсын, энесе Самат, машина йөртә белүче башка кешем юк, – дип китеп тә барды.

Сабираны кабинага урнаштырып, Шаһидә толып киеп, әрҗәгә утырып, юлга кузгалдылар. Машинаның эше шәп шул инде. Шул арада 12 чакрымны узып, Баймак авылына да килеп җиттеләр. Авылны чыгуга, тимер юл станциясе утлары да берән-сәрән җемелдәп күренгәли башлады. Барып җитәргә алты гына чакрым калды. Тик әллә күз тиде инде, озак та бармадылар, машина сүнде. Үсмер Самат, сикереп төшеп, капотны ачып, шунда казына башлады. Бераздан:

– Булмый апа, Баймакка кайтып, ат эзләп килергә туры килер, – диде ул.

Пошаманга төшкән Шаһидә авылга таба йөгерде. Ат таба алмады ул. Алай да үрәчәле җиңел чана юнәтеп килде. Толыпка төреп, Сабираны шунда утырттылар. Самат Шаһидә белән барудан баш тартты. «Олы юлдан кем генә узмас. Машинаны калдыра алмыйм, иртәнгә кадәр, бәлкем, төзәтермен», – диде.

Шаһидә, бераз уйланып торгач, олы юлдан түгел, басу аша турыга салынган җәяүлеләр сукмагыннан барырга булды. Олы юлдан барсаң, район үзәгенә җиткәч тә әле ике чакрымлап тәпиләргә кирәк: алты-җиде чакрымлап чыга, ә туры сукмактан өч кенә чакрым.

Бисмилласын әйтеп, чанага җигелгән Шаһидә алга атлады. Сукмак тар, вакыт-вакыт чананың бер ягы сукмак буендагы көрткә бата. Кичтән үк кузгалган җәяүле буран себереп торганга, сукмак өстендә кар көртләре өелгән урыннар да шактый очрый. Үзе дә карга бата-чума атлаган кыз чананы көч-хәл белән көрттән тартып чыгара. Шуңадырмы, атлаган саен, чана авырайган төсле, каршыга искән ачы җил дә көчәйгәннән-көчәя. Бераздан, буранлап, кар ишәргә кереште. Инде сукмакның ике ягындагы әрем сабаклары да күзгә чалынмас булды. Чана карга бата, тартып алыр хәл юк. Җитмәсә, Сабираның ыңгырашуы көчәйде. Шаһидә, туктап, толыпны рәтләде, «Түз инде, түз, күп калмады», – дип, хатынны юатып азапланды. Тагын кузгалдылар. Җәзаланып, кар көртләреннән чананы тартып чыгара алмыйча, интегеп бара торгач, Шаһидә үзеннән бер-ике метр читтәрәк каралып күренгән таякнымы, әрем сабагынмы шәйләп алды. Сукмактан төшеп киткәннәр ләбаса. Шабыр тиргә батып, чананы сукмакка чыгаруга, кыз лып итеп карга утырды. Ул тәмам хәлсезләнгән иде. Ыжгырып искән җилгә аркасын куеп борылды да күзләрен йомды. Хәзер, хәзер... Әз генә тын алыр да кузгалып китәрләр. Бераздан ул үзен җылынгандай тойды, башы бер якка салынып төште, әллә нинди авыр йокы баса башлады. Күпме вакыт узгандыр, кемдер касыгына төрткәндәй уянып китте. Сикереп торып, чанага ташланды. Сабира тавышсыз-өнсез иде. Коты алынган Шаһидә елый-елый: «Сабира, Сабира, дим, уян әле, Сабира!» – дип, аны селкетә, яңакларына җиңелчә суккалый башлады. Ниһаять, хатын, күзләрен чак кына ача төшеп, хәлсез тавыш белән «су!» диде. Судыр, чәйдер алып тормады-

PRESSA

лар, ашыктылар шул. Хәер, машина ватылыр дип кем уйлаган. Шаһидә, карны учында эретеп, хатынның иреннәренә тидерде, тегесе йоткандай итте дә, тагын күзләрен йомды. Кузгалып киттеләр. Ничек тә сукмакны югалтмаска иде бит. Сабира тагын ыңгыраша башлады. Шаһидә, туктап, чана өстенә иелде. «Түз инде, түз, хәзер барып җитәбез», – дип пышылдады ул, никтер үзенең дә тавышы бетүгә гаҗәпләнеп.

Әйе, әйе, алар инде станциягә якынлашалар, еракта-рак вокзал бинасы да шәйләнә. Хәзер, хәзер, озак калмады. Алда торган кар көртенә үрмәләп маташканда, чана нишләптер чалулап та китте, Сабира толыбы-ние белән карга тәгәрәде. Бу нинди хәлләр соң, Ходаем?! Шаһидә, хатынны читкәрәк этеп, астыннан толыпны алып чанага җәйде дә Сабираны култыклап аягына бастырырга азапланды. Бу гамәле барып чыкмагач, чананы Сабира янына этеп алып килде дә хатынны чанага сөйрәп менгерергә керешт. Җан-фәрманга чиләнә торгач, булды тагын. Сабираны яңадан толыпка төреп, үзе чана бавына җигелде. Бу юлы чананы көрт өстеннән сак кына тартып алды. Моңа шактый вакыт китте. Ул арада буран көчәйде. Җир белән күк тоташкандай булды. Берни күренми. Әллә нинди явыз җанвар сыман ыжгырган җил сулышны кисә, аяктан ега. Кара буран эчендә каршы искән җилгә каршы юлсыз-нисез кар диңгезеннән чананы сөйрәп бару Шаһидәне эштән чыгарды. Баткан чананы тартып алу түгел, үзе дә билдән карга чумып, кузгала алмый интекте. Юкка гына, әйләнгечтән юл туры, димәгәннәрдер шул. Олы юлдан киткән булса соң. Ашыкты шул. Ашыгу – шайтан шөгыле, дип, белми әйтмәгәннәр икән. Җәзаланып үрмәли торгач, ниһаять, ат юлына чыктылар. «Аллага шөкер, исән-имин килеп җитәбез бит», – дип сөенде ул. Туктап хәл алган җиреннән кузгалып китүе булды, колагына Сабираның «Үлә-ә-ә-м!» дип кычкырганы ишетелде. Бавын ыргытып, Шаһидә аның янына ташланды, хатын зәңгәрләнгән иреннәре белән чак-чак пышылдап: «Суым китте», – диде дә яңадан каты итеп ыңгыраша башлады. Кыз, тиз генә чанага җигелеп, алга омтылды.

Шаһидә, чана белән толыпны бала табу йортының кастеляншасына калдырып, кабул итү бүлмәсенә кергәндә, каталкага салган Сабираны операция бүлмәсенә алып чыгып баралар иде инде. Кыз кушеткага ауды. Тамагы, башы чатнап авыртудан уянып киткән Шаһидәнең колагына: «Ир бала, өч килолы...» – дигән сүзләр ишетелде. Сүз Сабира баласы турындамы соң? Шулай икән. Ярып алганнар, әнисе йоклый икән әле. Шаһидәне, сөенечтән битәр, ниндидер көнләшү чеметеп узды. Тимергалинең улы бар! Тик ул Сабираныкы, Шаһидәнеке түгел. Әллә Сабира басуда үлсә, яхшырак буласы идеме? Тьфү- тьфү, Алла сакласын, күңелгә нинди яман уй килә, шайтан коткысыдыр.

Шаһидәнең торып басар хәле юк иде. Янына килгән шәфкать туташына көчкә генә: «Тамагым авырта», – дип пышылдады. Аны санитар машинасында район хастаханәсенә илтеп куйдылар. Шунда бер атна дәваланып яткач кына, кыз авылына кайта алды, әле кайткач та бик озак хәлсезләнеп йөрде.

Сабира улы белән авылга кайтуга, Хәсбиҗамалттәй аларга бәби ашы күтәреп китте. Шаһидәнең: «И-и әни, нишләп йөрисең инде! Шул Сабираның исемен ишетәсем килми», – диюенә, ана: «Язмыштыр, балам. Күршедә генә үскән кыз бит. Аннан, бәби тапкан хатынга бирер көчтәнәчең булмаса, коймасын булса да сыйпап кит, дигән борынгылар. Сабый хакы бар бит», – диде. Акыл белән фикер йөрткәндә шулаен шулайдыр, йөрәк бит, һич кенә дә гафу итәргә теләми.

Яңа ел алдыннан Шаһидә өчпочмаклы хат алды. Хат Тимергалидән иде. «Мең-мең рәхмәт сиңа улымны дөньяга китерергә булышканың, аны исән калдырганың өчен» дигән, Яңа ел белән котлаган. Хат ахырына «Бердәнберем, кадерлем, Шаһинәм минем, кичер мине, кичерә алсаң», – дип өстәп куйган.

Яңа елга кердләр. Авыр, газаплы, хәсрәтле ел булды ул 1942 ел. Шаһидәнең абыйсы Шакирны да сугышка алдылар. Гаилә хәзер аның өчен ут йотып, фронттан хат көтеп яши башлады. Шаһидәнең эше күп, эт урынына чаба, борылып карарга да вакыты юк. Җитмәсә, әллә каян гына трахома дигән күз авыруы таралды. Әнисе аны кайчаннан бирле Табыш Муллышына – фин сугышыннан яраланып, аксап кайтып, хәзер ферма мөдире булып эшләүче Муллаянга димли. Шаһидә Табышны (малай мәктәптә укыганда, килешләрне бутап, баш килеш, иялек килеш, юнәлеш килеш, төшем килеш, табыш килеш дигән, имеш) Тимергали белән янәшә куеп, чагыштырып, күз алдына китерә дә ахылдап куя. Сугышка кадәр кеше арасына да кермәгән шул аксак-туксак Муллышның хатыны буламы соң ул! Юк һәм юк!

Тик... баганага сәлам бирерсең диләрме әле? Март аенда Шаһидә дус кызы Валяның һәлак булуы турында хәбәр алды. Безнең төркем кызларының яртысы фронтта инде, дип язган бу авыр хәбәрне җиткергән курсташ кызы, мине балам булганга гына калдырдылар, дип язган. Валяның үлеме Шаһидәне тетрәндерде. Аны да бүген-иртәгә фронтка җибәрүләре мөмкин. Әнисе белеп елый.

...Табыш Муллышы белән яшәде ул. Тегесе ферма, амбар мөдире, бригадир булды. Тормышлары авыл өчен шактый бай булып, хатынын һичнәрсәгә йөдәтмәде. Алай гына да түгел, хатынының сугыштан бик нык имгәнеп, бер аяксыз кайткан Шакир абыйсы гаиләсенә дә хәл кадәренчә булышты. Сугыш беткәч тә, кытлык еллар шактыйга сузылды бит әле. Шаһидә матур киенде, хезмәтен тырышып башкарды, әмма хуҗалыгындагы бетмәс-төкәнмәс эшләр белән ватылмады. Тормышыннан канәгать түгел дисә, Ходай орыр. Тик йөрәгенең әллә кайдагы тирән бер почмагында хәбәрсез югалган Тимергали яшәде. Яшертен генә аның фоторәсеменә карап, бердәнбер хатын укып яшь түккән чаклары әз булмады. Шулай, тормышның һәр ягы да килеп бетми шул, кем әйтмешли, кругом шестнадцать булмый.

Әнә Сабираны кара. Сөеклесеннән ир бала үстерде. Тик сугыш елларының барлык газабын татыды. Ачлык

дигәннәре дә бик тиз ишек шакыды. Сабираның берүзенә биш җанны туйдырырга кирәк иде. Кырык өчнең җәендә язмыш күсәге хатынның башына тагын да катырак итеп сукты: кесәсеннән 3-4 уч уылган арыш чыккан Сабираны сигез елга хөкем итеп куйдылар. Биш ел утырып, алтынчыга киткәндә генә күкрәк баласы белән кайтып килде ул. Сабира кайтканда, биата-бианасы гүр иясе булганнар, каенсеңлесе вербовка белән Сталинград якларына китеп барган, улы күрше авылдагы сеңелләрендә иде. Тәрәзәләрен каплаган такталарны каерып ачып, өйгә кергән ике балалы тол Сабираның тормышы алдагы елларда да авыр булды әле. Улы – яшь бөркете Галинур, калкынып, тормыш арбасына җигелгәч кенә бераз кеше рәтенә керде алар. Улы эшкә дә, укуга да шәп булып чыкты. Унны бетергәч, военкомат аны хәрби училищега җибәрде. Галинур, офицер булып, Мәскәүдә берничә ел хезмәт иткәч, хәрби академиягә укырга керде. Хатыны биюче – балет артисткасы, диделәр. Галинур үзе генә дә, гаиләсе белән дә ел саен авылга ялга кайтып йөрде. Әнисе белән сеңлесенә сыйфатлы чит ил киемнәре (ул озак вакытлар Чехословакиядә, аннан Германиядә хезмәт итте), күчтәнәчләр төяп кайта, күрше-күлннене дә бүләк-санаксыз калдырмый. Берни әйтер хәл юк, шәп иде Сабираның яшь бөркете. Тик менә кызы гына… Әллә иркәрәк булып үсте, әллә яралган орлыгы шундыйрак булган, белмәссең. Укырга да булдырмады, эшкә дә кулы ятмады. Аны башка нәрсәләр кызыксындырды бугай. Яшьли эчәргә, тартырга һәвәсләнде, кияүгә чыгып та кешечә яшәп китә алмады. Тормышы кыек юлдан, дөресрәге, бөтенләй дә юлсыз җирдән китте.

Сабираның кызы өчен җаны көя, ул үртәлә, минем гөнаһларым өчен җәза кызыма төште дип газаплана иде. Әйе, гөнаһлы ул, әйтеп бетергесез гөнаһлы. Яшьлек исәрлегеме, кан тамырларында йөри торган шайтан эшеме – эт белсен, нәрсә этәрде аны бу адымга.

Казаннан Сабан туена ашкынып кайтып килүче Сабира район үзәгеннән авылга ахирәтенең егете Тимергали машинасына утырды. Шәһәрчә киенгән кызның кәефе гадәттән тыш күтәренке иде. Юк-бар нәрсәдән дә кызык табып, көлешеп, сөйләшеп кайткан җирдән Сабира нишләптер егеткә игътибар беләнрәк күз төшерде. Карасана, нинди чибәр икән ул! Зифа буй-сын, дулкын чәчләр, озынча сөйкемле йөз, куе кара кашлар, озын керфекләр белән каймаланган янып торган кара күзләр, тезелеп кенә киткән ап-ак тешләр, өстәвенә, елмайганда бит очлары чокыраеп китә. Әле ул сине кочып назласа, ягымлы сүзләр дә әйтсә, эреп китәрсең, валлаһи. Нишләп шофер булып йөри икән, артист кына буласы калган. Ничек кенә элек күрмәгән соң аны Сабира? Хәер, ул бит авылга сирәк кайтты. Сабира ваемсыз йөргән арада, ахирәте нинди егет солтанын эләктереп өлгергән. Ник, Сабира ахирәтеннән киммени? Нигә аңа да арсландай егетнең сөйгәне булмаска?

Фонарик җиңле, декольтелы крепдешин күлмәген, биек үкчәле дерматин туфлиен киеп, бизәнеп, төзәнеп, «Серебристый ландыш» ислемаен колак артларына тигезгәләп, кичке уенга чыккан Сабира ахирәте яныннан бер адым да читкә китмәде. Шаһидәләрнең капка төбенә дә өчәүләп кайтып туктадылар. Тик күпме генә тырышса да, Сабира Тимергалинең игътибарын яулый алмады. Егет, хыялланган Мәҗнүндәй, Шаһидәдән башка беркемне дә күрми иде.

Гашыйк кыз Казанда да җанына тынычлык тапмады, авылга очып кайтырдай булды. Июль урталарына кадәр түзде-түзде дә, әнигә печән әзерләшергә кирәк дип, үз хисабына бер атна ял алып, иске бер тиендәй ялтырап, авылга кайтып та төште. Тик һаман шул инде. Өчәүләп йөрсәләр дә, Тимергали, кояшка баккан көнбагыштай, һаман Шаһидәгә борыла, аны гына күрә, аны гына сөя.

Сабира бар тынычлыгын җуйды, яна да көя. Тимергалине ничек итеп үзенеке итү турында нинди генә планнар корса да, барысы да яраксызга чыгара.

Һәм менә кинәт, уйламаганда, көтмәгәндә… Печән теземнәрен әйләндереп киптерәләр иде, шунда күрше рәттәге тезем дә баручы ике хатынның үзара чыш-пыш сөйләшүе кызның колагына кермәсенме:

– Әйтмә дә инде, өч баласын ятим итәм дип тормаган.

– Алай да… тегесе ничек итеп кенә үзенә бора алды икән?

– Ничек дип, Очкырга барган, диләр.

Очкыр… Бу сүз авыл теленә күптән кергән. Анда сихер ясатырга йөриләр, диләр. Сихер! Бик куркыныч сүз. Гөнаһысы әкәмәт зур ди аның.

Гыйшык утының көйдерүе сихер куркынычыннан көчлерәк булып чыкты. Барды Очкырга Сабира.

Сыер савучылар, шимбә көннәрендә Ишне аркылы йөзеп чыгып, Удмуртиянең бер район үзәге булган Яскыга шикәрдер, чәйдер алырга чыгалар иде.

Төшке савымнан соң, Ишнең теге як ярына йөзеп чыгып, тау өстендәге Яскыга күтәрелделәр. Менеп җиткәч, Сабира, иптәш кызыма куна барам дип, юлдашларыннан аерылды. Аңа басу юлы буйлап тагын алты чакрым атларга кирәк иде әле.

Сабира багучыга барып кергәндә, тегесе фанера кисәкләренә кура җиләкләре таратып утыра иде. Һич тә сихерче димәссең: кечкенә гәүдәле, ябык кына, иллеләр тирәсендәге чирмеш хатыны. Кыз, ишектән кереп, исәнләшүенә, ул танышына эндәшкәндәй генә саф татарча:

– Килеп тә җиттеңмени? Хәл кылдың инде алайса, – диде. Гаҗәпләнүеннән Сабира артына ава язды. Ул арада хатын сүзен дәвам итте.

– Сайларга мөмкинлегең бар әле. Үз юлыңнан атла. Нигә сиңа кеше юлы, кеше бәхете? Киңәш итмим.

Сүзсез-өнсез калган кызны сихерче почмакта торган сулы кисмәк янына чакырып, су өстенә карарга кушты. Сабира, шүрләбрәк суга бакты – ә анда… анда Тимергалинең йөзе чайкала иде. Кыз куркуыннан артка чигенде.

– Юк, син китмә, кара, – дип әйтте хатын боерган тавыш белән.

Сабира тагын кисмәккә иелде. Кинәт су өсте сәер рәвештә дулкынланып китте, сурәт юкка чыкты.

– Күрдеңме, – диде сихерче, – ул югала.

Шактый гына тынсыз-өнсез торганнан соң, Сабира телгә килеп:

– Булсын, – диде калтыранган иреннәре белән. – Мин риза. Ичмасам, аныкы булып калырмын, бәлкем, бәхетемнән балам да булыр.

– Булыр, – диде сихерче, аның сүзен җөпләп, – кая китсен ул, булыр. Тик башка берәүнең бәхетен тартып алып, сиңа бирү миңа нигә кирәк? Хәер, аңа булса да, күпкә түгел инде ул. Юк кирәкми, – дип баш тартты ул.

Сабира үксеп еларга кереште. Үзе елый, үзе такмаклый:

– Ул – минем бәхетем. Аны яратырга минем хакым бар. Мин аннан башка яшәмим. Лутчы үләм мин! Менә кайтканда ук Ишкә төшәм дә бетәм... Ник кенә тудым икән бу дөньяларга! Үләм бит!.. Бәхетсез башкаем!

Сихерче аны ачуланып туктатты:

– Өзгәләнмә. Яратуыңны беләм.

Күпмедер вакыт тын торгач, ул дәвам итте:

– Бар кайт инде. Син дигәнчә булыр, тик ике айлап көтәргә туры килер әле, йолдызлар торышы рөхсәт иткәнче.

Сабира алып килгән акчаларын ашыга-ашыга кулъяулыгыннан урындыкка төшереп, рәхмәт әйтергә дип сихерчегә күтәрелеп карася, имәнеп китте: тегенең бер күзе кара, берсе сары, җитмәсә, сарысы әллә нинди куркыныч булып ялтырап алды. Коты чыккан кыз, рәхмәт тә әйтә алмыйча, ишеккә ташланды.

Ишне берүзе йөзеп чыгарга шомланып, кичке сөт машинасына утырып, Яскыдан Ижауга юнәлде. Авылына икенче көнне генә кайтып җитте.

Әнә шулай тартып алды ул Тимергалине Шаһидәдән. Тик бәхете генә кыска булды. Кырык икенең җәендә Тимергалидән хат-хәбәр килү тукталды. Инде менә Галинуры, үзе дә олыгаеп килгәндә генә, әтисенең язмышын ачыклады. Германиянең Бавария дигән җиренә алып барды ул әнисен.

Әсирләр җирләнгән урын Хаммельбург дигән шәһәрдән егермеләп чакрым ераклыкта икән. Мемориаль комплекс хезмәткәре аларны, кечкенәрәк автобуска утыртып, бездәге әрәмәлекләргә охшаган урман юлыннан каберлеккә алып китте. Барып җитсәләр, бернинди каберлек юк, бары баганаларга беркетелгән тимер чыбыклар белән әйләндереп алынган биш-алты гектарлы тигез кыр. Концлагерьларда авыр эшләрдән, җәзагазаплардан, ачлыктан, авырулардан һәлак булып, гәүдәләре крематорийда яндырылганнарның көле сибелгән басу икән бу. Таптылар алар газизләренең исем-фамилисе язылган багананы. Җәсәде белән алман басуын ашлаган икән татарның бөркете! Баганаларда йөзәрләгән исемнәр, дистәләгән милләт вәкилләре. Бу кадәр дә явызлыктан гөнаһыга баткан Җир, күчәреннән ычкынып, ничек космос тәмугына төшеп китмәде икән?!

Басудан бер уч туфрак алып кайтырга чыктылар. Машина алдыннан, әле тәрәзәгә якынлашып, әле ераклашып, әйләнгәләп, бер кошчык оча. Ана белән ул, бу хәлгә сәерсенеп карап барганда, хезмәткәр мондый аңлатма бирде. Әгәр килгән кунаклар баганалардан газиз кешеләренең исемен таба алсалар, машина алдыннан һәрвакыт, куангандай, кош оча. Әйтерсең лә гәүдәләре көлгә әйләндерелгәннәрнең җаннары. Шулайдыр, җаннар кошларга күчә диләр бит.

Ярты гасыр пыскыган өмет уты әнә шулай сүнде. Инде Шаһидә белән бүлешер кешесе юк иде Сабираның.

Дөресен әйтергә кирәк, гомер буйларына көнчелек корты кимерде Сабираны. Үсмер чакта ул ахирәтенең шахтер абыйсы алып кайткан киемнәренә кызыкты, соңрак дустының медучилищеда укуы, ә үзенең кара эшче булып йөрүе эчен пошырды, аннан инде мәхәббәттә юллары кисеште. Тол хатын булып, тормышның «уфалла»сын җигелеп тартканда, бу көнләшүе шартлар дәрәҗәгә җиткән чаклары булды. Ничекләр итеп түзмәк кирәк: ул – Сабира, өстенә ямалып беткән сырмасын, аягына шахта галошын киеп, башына уңып-тузып беткән иске шәлен бәйләп, арып-талып, фермадан иртәнге савымнан кайтканда, юлында каракүл якалы бостон пальтосы, аягындагы ак фетр итекләре, ак челтәр шәле белән урамнарны балкытып, медпунктка баручы Шаһидәне очрат әле, ачуыңнан ярылыплар китәрсең, валлаһи.

Галинур әнисенә акчалата да, посылкалар белән дә ярдәм итеп, ялга кайтканда йорт-кураны төзекләндереп тора башлагач кына Сабираның кара көнчелеге басыла төште. Ә инде Галинур Шаһидәләр күршесеннән элеккеге колхоз рәисенең бер дигән шәп йортын сатып алып, әнисен шунда күчергәч, Сабира тынычланды диярлек. Аның да хәзер менә дигән йорт-җире, яхшы өс-башы бар, ел саен санаторийга бара. Ниһаять, ул да җитеш тормышка иреште. Тик менә авыл дигәнең генә Сабиралар, Шаһидәләр белән бергә картая. Өстәвенә, яшьтәшләре дә сирәгәя бара – инде күпләре мәңгелек йортларына күчтеләр.

Кешегә ялгызы гына яшәү авыр, ул аралашуга мохтаҗ. Сабира Шаһидәләр күршесенә күчеп килгәч, аралар тора-бара ялганып китте, элеккечә ихласлык белән үк булмаса да, ахирәтләр аралаша башладылар. Ә инде Шаһидәнең 70 яшьлек юбилеена Галинур чуклы кашемир шәл дә бүләк иткәч, мөнәсәбәтләр шактый җылынды. Ахирәтләр әле берсендә, әле икенчесендә чәй өстәле артында яки капка төбендә озак кына гәпләшеп утыра торган булып киттеләр. Урамда бик салкын йә бик җилле-яңгырлы көн була калса яки авырыбрак торсалар, телефоннан булса да шалтыратышып, хәлләрен белешәләр. Борчуларыңны эчеңә җыйма, чиргә әйләнер, баганага булса да сөйлә, диләр бит. Серләреңне кемгә сөйләр идең дә, кем сине аңлар иде. Сер дигәннән, ахирәтләрнең бер-береннән яшерен серләре юк та инде. Сөйләшә, аралаша торгач, бары да әйтелгән, серләр дә чишелгән сыман. Ә-ә, юк... Чишелмәгән бер сер калган икән бит әле. Сихерчегә бару. Йә, ярар, анысын да күңелдә төер итеп йөртеп булмас. Алла бирсә, иртәгә исән-имин торып чыксалар, Сабира бу турыда ахирәтенә сөйләми калмас. Шаһидә өчен бу бик әһәмиятле сер икәнен белә бит ул.

ЗӘКЯТСЕЗНЕҢ МАЛЫ ХӘРАМ



Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН, «Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы

Хатын-кызның бизәнү әйберләреннән зәкят түләргә кирәкме?

– Алтын-көмешнең бизәнү әйберемеүгелме икәне мөһим түгел: өендә андый байлык ята икән – болардан зәкят түләнә. Әмма алтынның авырлыгы 85 грамм яки аңардан күбрәк булса гына. Ә көмештән зәкят түләү өчен аның авырлыгы 595 грамм яки шуннан артыграк булырга тиеш. Тик кешенең, әйтик, 50 грамм алтыны, 200 грамм көмеше, болар өстенә тагын акчасы да бар икән, шуларның һәммәсен бергә кушып санарга кирәк. Нәтиҗәдә, 210 мең сум яки аннан да артыграк акча җыелса, ул вакытта зәкят түләнә. Бизәнү әйберләренең бәясе авырлыгына карап исәпләнә. Әйтик, бер йөзекнең бәясе 100 мең булырга мөмкин. Ләкин алтын буларак, ул арзанрак та тора ала. (Ломбардтагы шикелле бу: кибеттән сатып алганда, әйтик, колак алкасы «эшләнмә» дип атала, ә ломбардка тапшырганда аны инде «ватык», «калдык» кына диләр.) Ә йөзектәге, алкалардагы асылташлардан зәкят аларның бәясенә карап түләнә.

Сүз уңаеннан: 210 мең акчаң җыелса һәм ул бер ел тотылмыйча яткан булса, аннан зәкят түләргә тиешсең. Фитр сәдакасы рамазан аенда, гает намазына кадәр бирелә. Быел аның күләме – 100 сумнан алып 600 сумга кадәр. Төрле сәбәп белән ураза тота алмаучылар фидия сәдакасы түли. Ул – һәр көнне бер кешене ашату дигән сүз. Быел аның күләме – 200 сум.

Фитр сәдакасын кеше уллыкка-кызлыкка алган балаларына бирә аламы?

– Бирә ала. Ләкин моны сез ничек күз алдына китерәсез? Әйтик, тәрбиягә алган баласына 5 яшь ди. Кеше сәдаканы бер кулы белән биреп, шунда ук икенчесе белән алып, әлеге акчаны үзе кулланырга тиеш була бит. Бу бала инде акчаны үзе тота алыр яшькә җиткән булса яки әлеге акча, бала үсеп буйга җиткәнче, банктагы кебек кагылгысыз булып каядыр ятып торса, бирергә дә мөмкин, әлбәттә. Әмма барыбер ниндидер шикле авантюра кебек килеп чыга. Беренчедән, уллыкка-кызлыкка алгансың икән, син аны болай да тәэмин итәргә: ашатырга, эчертергә, киендерергә, тәрбияләргә тиешсең. Ә аның кулына сәдака тоттыру – акчаны читкә җибәрергә теләмәү кебек. Дини яктан караганда, хәтта мошенниклык кебек бу. (Ләкин шундый очрак булырга мөмкин: ир хатынны кияүгә баласы белән ала. Ияреп килгән бала каршында ирнең бернинди җаваплылыгы юк, шуңа күрә ул: «Бу акчаны балаңа тот», – дип, сәдаканы хатынына тапшыра ала.)

Фитр, фидия сәдакасы, зәкят – барысы да бер үк кешеләргә – мескеннәргә бирелә. Ягъни тору урыны бөтенләй булмаучыларга (фатир арендалап торучылар моңа керми), фәкыйрьләргә. Кемнең 210 мең һәм аннан да күбрәк акчасы юк, кем зәкят түләми – шул фәкыйрь дип санала. Шулар арасыннан сәдаканы кемгә бирү хәерлерәк соң? Әлбәттә, ятимнәр, карт-карчыклар, гарипләргә. (Эшләгән кеше дә фәкыйрь булырга мөмкин анысы. Ләкин ул бүген-иртәгә үзенә ризык таба ала әле.) Бирергә була дини юлда гыйлем алган шәкертләргә. Дин әһелләренә – муллага, мөәзингә һәм башкаларга. (Елның бер вакытында кергән зәкят акчасыннан тыш, аларның берсенең дә даими керемнәре юк.) Сәфәрдә, юлда калган кешегә бирергә рөхсәт ителә. (Әйтик, кемдер безнең шәһәргә кунакка килә һәм, авыр хәлгә тарып, акчасыз кала. Үз илендә, торган җирендә ул байлардан саналырга да мөмкин, ләкин аңа ярдәм хәзер, монда чакта кирәк.) Элек колны азат итәргә бирергә булган. Хәзер алар урынына кредитлы кешеләр бар. Ләкин аларга ярдәм иткәндә шундый шарт кую кирәк: ул башка кредит алмаска тиеш. Шәригать күзлегеннән караганда, безнең җәмгыятьтә байлар хәерче булып күренергә, ә ярлылар бай булып чыгарга да мөмкин. Әйтик, берәүнең кулында 1 миллион акчасы бар ди. Безнең өчен бай кеше бит инде ул. Әмма аның бурычлары тагын да күбрәк – 5 миллион. Шуңа күрә ул фәкыйрь санала, зәкят тә түләргә тиеш түгел. Яки менә ике күрше яши. Берсе зур коттеджда тора, кыйммәтле машиналарда йөри, чит илләрдә ял итә. Әмма аның 20 миллион кредиты бар. Икенчесе фатирны «снимать» итеп кенә яши, үзенә йорт сатып алырга тиенләп акча җыя – инде 500 мең җыйган. Шуларның беренчесе, бурычы күп булгач, фәкыйрь санала – зәкят түләми, икенчесенең өйдә ята торган акчасы 210 меңнән артыграк, ул зәкят бирергә тиеш. Менә шундый парадокс. Әмма монда бер хикмәт бар. Бүгенге көндә Ходай каршында бай саналучы кеше ахирәттә берәүгә дә бурычлы булмаячак, ә фәкыйрь дип танылганнар бурычларын анда баргач түләячәкләр.

Инде зәкятне кемнәргә бирергә ярамаганын да әйтик: үзеңнең эти-әниеңә, дәү эти-дәү әниеңә, балаларыңа. Аларны тәэмин итү синең өчен болай да мәҗбүрият. Күңелең нечкәргәндә генә эшләргә тиеш түгел син аны.

Улыңның хатынына, кызыңның иренә фитр сәдакасын бирү дөресме?

– Әйе, бирергә мөмкин. Ләкин шул ук вакытта алар акчаны ничек тоталар икән? Ислам дине буенча, ир белән хатынның акчасы аерым булырга тиеш. Улыңның хатыны акчасын аерым тотса, «Үзеңә берәр нәрсә ал», – дип, сәдаканы аңа бирергә була әле. Акчалары аерым түгел икән, димәк, ул бу акчаны да барыбер иренә тапшырачак. Бу очракта инде шик туа – сәдаканы үзеңнең улыңа биргән кебек булып чыгасың бит. Ә кияүгә менә бирергә ярый. Ул сиңа туган түгел – чит кеше. Хәтта син биргән акчаны синең кызың тотса да, ул барыбер үз акчасын тоткан кебек санала. Димәк, ул синең кулдан сәдака алса, аңа ярдәм итәргә мөмкин.

PRESSA

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



Апрельдә 95 яшен тутырган әниебез Нурания Рәхимованы авылыбыз Көек-Ерыксада, яратып, Ак әби дип йөртәләр. Әле бүген дә зиһене уяу, хәтере яхшы, берүк күзләр тимәсен.

Сугыш чоры газапларына өстәп, ятимлек ачыларын да бик иртә татый ул. 1936 елда әниләре вафат була. Ул вакытта гаиләдәге олы бала булган әниебезгә – 12, иң кечкенә энеләре Хафизга 1,5 яшь. Әтиләре Садыйк тиздән өйгә үги әни алып кайта, сугышка кадәр аларның бер уллары туарга өлгерә.

Бабайны сугышка 1941 елны ук алалар. Үги әни, әти-әниемне тәрбияләргә кирәк, дип, улын алып авылына кайтып китә. Бөтен тормыш йөге шушы өч ятимгә өелеп кала.

Инде 1937 елдан ук үзләренең «Марс» колхозында бригадир ярдәмчесе булып эшләгән әнине сугыш башлангач бригадир итеп куялар. Эшкә ярардай атлар фронтта, авылда нибары ике ир кеше, калганы барысы да хатын-кызлар, картлар һәм балалар. Бөтен эш – шулар җилкәсендә. Әле тамаклары тук, өсләре бөтен булса икән... Көнлек норманы үти алсаң, бер стакан он бирәләр. Кул көче белән генә әллә ни майтара алмыйсың, ашлык гектарына нибары 7-8 центнер гына чыга. Анысын да җәяүләп Мамадышка ташыйсы. Боларга өстәп, задание дә үтисе бар: 200 литр сөт, 100 йомырка, май, йон... Үзеңә генә түгел, асраган терлегеңә дә җитәрлек азык юк. Җитәр-җитмәс печән белән генә торган арык сыер күпме генә сөт бирсен соң? «Аптырагач, Малмыжга кадәр барып, кибән төпләрен казып ала идек. Андагы урыслар безне куа. Качкан вакытта аяктан чабаталарга кадәр төшеп кала. Берсендә шулай бик салкын көнне чабатам төшеп калгач, башымдагы шәлемне алып, аягыма урадым», – дип сөйли ул.

Җәен бар ашаганнары үлән булса, кышын – бәрәңге. Әмма ул бәрәңгене дә күпмегә генә җиткереп була инде: үзеңә дә, терлегеңә дә шул бер бәрәңге бит. Язын бар да басуда черек бәрәңге җыя. «Ул чакта бәрәңге хәзерге кебек череми иде, ап-ак булып, ярмаланып тора иде», – ди әни.

Сугыш бетеп, әти кайтса, болай авыр булмас иде, дип яшәгәндә, ул өметләре дә өзелә: әтиләренең үлү хәбәрен алалар. Бу хәбәр белән килешәселәре килми, «Юк, әти үлмәгән, ул исән!» – дип такмаклап елый-елый, өч ятим бу кәгазьне ишегалдына алып чыгып яндыра.

...Язмыш әниемне ата-ана назыннан, балачак рәхәтлекләреннән мәхрүм итсә дә, гаилә бәхетен бирә. Сугыштан бер кулы яраланып кайткан Сабир атлы егет – безнең әтиебез белән тормыш корып җибәрәләр. Тугыз балага гомер бирәләр. Кызганыч, барысы да гомерле булмый. Без, аларның өч кызы, исән-сау үсеп җитеп, өчебез дә медицина өлкәсен сайладык. Әти белән әни безне гел укырга өндәп торды. Әтиебез күптән инде вафат. Әни исә безгә генә түгел, бөтен районга үрнәк. Авылыбыз Көек-Ерыксаның бик хөрмәтле кешесе ул. 2016 елда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов аңа «Фидакарь хезмәте өчен» медален тапшырды. «Хезмәт ветераны», «Татарстанның атказанган колхозчысы» кебек мактаулы исемнәре бар. Әниебез биш вакыт намазын калдырмый, ел да уразасын тота, урманнан җиләк-гөмбә җыеп, бөтен туганнарга күчтәнәч итеп өләшә. Күңеле гел изгелектә, безгә, туганнарга, авылдашларга хәер-догада ул.

Гөлсинә БАКИРОВА.
Казан шәһәре.

Яңа ел каникуллары вакытында Уфага барырга туры килгән иде. Казанга кайта торган автобуста янымда утырып кайтучы ханым белән сөйләшеп киттек. Аның язмышы мине бик дулкынландырды.

Биш бала табып үстергән ул. Бер улы моннан ике ел элек Казанда «Адмирал» сәүдә үзәгендәге янгында вафат булган. Хәрабәләр арасыннан янган гәүдәсен генә табып алганнар. «Бик акыллы, тәртипле бала иде, – ди әңгәмәдәшем. – Дүрт кыз арасында үскәнгә, хатын-кызларга карата бик игътибарлы, ярдәмчел булды. Үзем дә: «Улым, Кыямәт көнендә синнән кыз туганнарың өчен дә сорарлар. Син аларга терәк булырга тиеш», – дип үстердем. Алдагы көнгә өметем, тормышымның төп таянычы иде ул. Нишлисең, шулай язгандыр, язмышлардан узмышлар юк».

Хәсрәт ялгызы гына йөрми. Уларының вафатыннан соң, 38 ел бергә гомер иткән ире башка хатынга чыгып киткән. «Нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар икәнен белүче бер Аллаһы Тәгалә генә. Шөкер, шул вакытта башларымны имәслек көчләр бирде. Сынауларны күтәрергә үзе ярдәм итте. Бәндә хурласа да, Аллаһы Тәгалә ташламый. Балаларым «әни» дип, оныкларым «дәү әни» дип өзелеп торалар. Хезмәттәшләрем хөрмәт итә», – ди ул.

Ә Уфага баруының сәбәбе – Ихлас мәчетендә «Балкыш» тапшыруы өчен балаларын югалткан аналар хакында сюжет төшергәннәр икән. Бала хәсрәте – иң ачы хәсрәт, беркемгә дә аны кичерергә язмасын.

Исемем редакция өчен генә.
Яшел Үзән шәһәре.

Җәйнең матурлыгын күрербез, балык каптырырбыз дип, дустым Азат белән кичтән Мәртен авылына кайттык та, яр буенда гына кунып, таңнан кармакларыбызны суга салдык.

Көтмәгәндә таңның серле өрфиясен тибрәндереп, моңлы җыр ишетелде. Азат белән бер-беребезгә караштык. Таң алдыннан су буенда кем җырлап йөрер? Моң иясен күпме генә күрергә тырышсак та, күреп булмады. Шактый еллар узса да, бу иртәне, бу тавышны оныта алмадым. Аны әллә нинди тавышлар арасыннан да танып алырмын кебек иде.

Һәм ничә еллардан соң кабат очраттым бу моң иясен. Үзебезнең үзешчәннәр концертына килгән идем. Кинәт... күңелемдә йөрткән тавыш яңгырады. «Кыр казлары артыннан», «Олы юлның тузаны» җырларын җырлаган бу ханым Мәртен авылында туып-үскән Рәкыйбә Гатауллина булып чыкты.

Рәкыйбә апа – сугыш чоры баласы. Сугыш башланганда аңа 5 кенә яшь була әле. 1941 елда әтисе Колшәрипне сугышка озаткан көнне бик ачык хәтерли ул. Алар өч бала, әниләре дүртенчегә авырлы. Әтиләренең Суслонгердан берничә хаты килә әле, ә фронттан «хәбәрсез югалды» дигән кәгазь генә килеп төшә. Хәер, үзе сөйләгәннәрне тыңлыйк әле.

«Үлгән хәбәре килсә дә, без бик озак көттек әтине. Әни бик күп күз яшьләре түкте. Ләкин түгәсе яшьләр алда булган әле безнең. 1949 елда район үзәгенә менгән җирдән әнием Факияне кулга алдылар. Ул вакытта шулай бит, берәрсенең үч аласы булса, жалоба гына язалар иде. Әнине сигез елга утыртып куйдылар. Ни өчен икәнен үзе дә, без дә белмәдек. Өйдә өчебез утырып калдык. Ярый әле әни урынына апа булды. Мичкә ягу өчен, фермадан сыер астына салган саламны урлап алып төшә идек. Өйгә төтен, тирес исе тулса да, җылынгач, күңел күтәрелеп китә. Алай да ашарга юклык бик читен. Ярый әле күршеләребез әйбәт булды. Әнине кулга алуга ук, тегү машинабызны үзләренә алып чыгып, яшереп куя белделәр. Машина турында беркемгә дә әйтмәгез, дип, безне дә кисәттеләр. Берничә тәлинкә белән иске бишмәттән гайре алып чыгардай әйберебез дә юк иде. Ел ярым утыргач, сеңлем кечкенә булганга, әнине амнистия белән азат иттеләр. И-и ул вакытта шатланганнарыбыз!

Авыл яшьләре ул чакта да бәйрәм саен концерт куярлар иде. Мин матур җырлагач, урыным гел сәхнәдә булды. Әти дә матур җырлаган безнең. Аны икенче Рәшит Ваһапов дип йөрткәннәр.

Җиде класс белем алдым. Район үзәгеннән Нигъмәтулла исемле бер чибәр генә егет килеп укытып йөрде. Шул елларда Мамадыш районының Кыерлы авылыннан бер хат килеп төште. Әти белән сугышта бергә йөргән, аны үз куллары белән җир куенына иңдергән бер абый (исемен хәтерләмим) язган иде. Әни шуннан соң гына әтине көтүдән туктады.

Кыз бала булсам да, кул пычкысы белән урман да кистем, Нырты күперенә субай да кактым, Туктарда кирпеч заводында да эшләдем, Мәскәү астында торф та чыгардым. Ул вакытта авыл кешесенә паспорт бирмиләр иде. Миңа исә җырлавым ярады, Казанга концерт белән барасы булгач, паспорт язып бирделәр. Район үзәгенә ипи кибетенә эшкә урнаштым. Ипине исемлек буенча, кеше башына 500 грамм гына сатарга ярый. Үзем ипи сатам, ә үземә талон бирмиләр, чөнки авылда исәптә торам бит. Иң үзәкне өзгәне: ипи сатканда авыл кешеләренең читтән тилмереп карап торулары. «Эх, кайчан аларга да ипи сата алырмын да, аларның бу үзәк өзгеч карашларыннан котылырмын», – дип тели идем.

Мине шул елны ук урлап алып киттеләр. Кем дисезме? Үзебезне укытып йөргән теге Нигъмәтулла! Бәләкәй генә дүртпочмаклы өйгә унынчы кеше булып килдем. Кысынкы булса да, уныбыз да сыйдык. Менә мин шунда тойдым инде «әти» дип әйтүнең, ирле йортта яшәүнең рәхәтлекләрен. Туры сүзле, тырыш, гадел, сугышта бер аягын калдырып кайткан кайнатама «әти» дип 11 ел әйтә алдым. Ләкин бәхетле тормыш озакка бармады, утынга дип киткән җирдән машиналары капланып, ирем ике аягын да бот төбеннән сындырды. Аяклары озак төзәлә алмыйча, бик интекте. Инде болары да артта калды, дисәк, базга бәрәңге алырга төшкән җирдән, ис тиеп егылды. Җитмәсә, өйдә берүзем, берничек тә чыгара алмыйм. Ярый кешеләр булышты, азга гына тоткарлансак та, коткарып калып булмый иде. Шушы хәлдән соң ике күзе дә сукырайды. Алай да операцияләр ясап, якты дөньяга кайтара алдылар.

Күп еллар тегү артелендә тегүче булып эшләп, пенсиягә чыктым. «Татарстанның атказанган көнкүреш хезмәте хезмәткәре», «Хезмәт ветераны» исемнәренә лаек булдым. Ә безнең әниләргә боларның берсен дә күрергә насыйп булмады»...

Менә шундый чын хикәя сөйләде Рәкыйбә апа. Аның үзәк өзгеч моңының сәбәбен аңладым мин.

Муса АБДУЛЛИН.
Саба районы, Байлар Сабасы.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA



Фото: www.pixabay

БЕЗ ИСӘН ЧАКТА...



Ризидә ГАСЫЙМОВА

ӘНИЕМ ТУРЫНДА БУ ЯЗМАНЫ МИН ИНДЕ ЯРТЫ ЕЛ ЭЛЕК ЯЗА БАШЛАГАН ИДЕМ.

Иң элек, шартлы рәвештә, исемен дә язып куйган булганмын: «Әниләр турында җыр». Ә нигә – җыр? Минем җыр түгел, шигырь дә язып караганым юк бит! Үзем шулай уйлыйм, әмма күңел тулы ярату һәм юксыну, нишләптер, бары тик «җыр» дип кенә аталырга тиеш кебек тоела. Яза башлыйм да... елыйм. Яза башлыйм да... туктыйм.

Узган көз безнең өчен бик авыр булды – уйламаганда-көтмәгәндә газиз әниебезне соңгы юлга озатырга туры килде. Көтмәгәндә, дигәннән... Сәламәтлеге, дөрес, әйбәт түгел иде инде әнинең. Әмма ләкин без аның шушы гел сырхау хәленә күнеккән кебек идек инде. Һәм ул безгә әле менә шушылай бер төслерәк булып: бер ятып, бер торып, бер бетеп, бер хәлләнеп, әле әкрен генә яшәр дә яшәр кебек тоела иде.

Җомга көнне кич начарланып киткән әни. Температурасы кырыкка җиткән. Дару эчерсәләр дә, төшмәгән. Әни шулай төне буе үзен үзе белештермичә авырып чыккан.

Без икенче көнне иртүк Чаллыдан кайтканда әнине ашыгыч ярдәм машинасы белән район больницасына алып килгәннәр иде. Ничек шулай туры килгәндер, шимбә көн булуга карамастан, үзенең участок табибы карады аны. Өйдә чакта инде телдән язган кебек булган икән, Ходай рәхмәте, ничектер сөйләшеп китте бит әниебез. Табиб хәлен сораганда, «әйбәт» дип җавап бирде, барыбызны да аермачык таныды. Әмма шул ук вакытта... ул ничектер башка төрле дә иде инде. Каталкада хәрәкәтсез яткан килеш рентгенга төшерергә алып барганда да, табиблар озаклап диагноз куярга азапланганда да, йокылы-уяулы халәттә, канәгатьсезлек белдермичә ята бирде. Ул «монда» да, әмма шул ук вакытта... гел монда да түгел сыман иде.

Нишләптер аны больницага салуны кирәк санамадылар. Сөйләшүе үзгәрде, аңы югалып бара, диюебезне дә «ишетмәделәр». «Әби озак яшәмәс, торса да бер-ике көн торыр, алып кайтыгыз, өеңдә өзелсен», – дип ачыктан-ачык әйтсәләр, мин бүгенге акылым белән бик рәхмәтле булыр идем дип уйлыйм. Тик алай да димәделәр. Тулы «осмотр» булсын өченме, ике сәгатьләп күз табибын көттереп алганнан һәм әнинең күзләрен озаклап тикшереп, әйбәт дип тапканнан соң, ике айдан соң тагын килерсез, күренерсез, дип, ул гел эчә торган дүрт-биш дару өстенә, тагын дөнья кадәр дару язып кайтарып җибәрделәр. Төенчек кадәр генә калган әниебезне энем машинага күтәреп алып чыкты.

Әнине без бу юлы якындагырак авылга – апаларга алып кайтырга булдык. Табиблар алай зур гаебен тапмагач, рәтләнеп китәр дигән өмет белән (ЭКГ кәгазен карагач, табиб: «Йөрәге минекеннән дә яхшырак», – диде бит!) барыбыз да әни янына җыелдык. Ак яулыклы әниебез ап-ак урын өстендә юп-юка булып ята иде. Без моны саубуллашу мизгелләредер дип уйламыйбыз да бит әле. Ә әнинең ул чактагы күз карашы! Аның сүзсез генә өздереп, соңгы кат күргәндәй йотылып әле беребезгә, әле икенчебезгә каравы... Ул караштагы яратуның зурлыгы... Бу яратуның илаһилыгы! Мин моны берничек тә сурәтләп бирә алмамдыр! Әни безгә – балаларга һәрвакыт йомшак булды, тик бу караш гадәттәгедән үзгә, ул башка, бөтенләй башка иде! Хәер, әни үзе дә башка иде шул инде. Ул, әйтерсең, күңеле белән инде биеккәрәк – башка яссылыкка күчкән иде. Дөрес, сорагангa җавап бирә. Тик элеккечә авыл белән дә кызыксынмый, «Лимон (ул әтине шаяртып шулай атап йөртә иде) нишләп ята микән анда?» – дип тә кыбырсымый, безнең хәл-әхвәлне сорашып, югыбары өчен сөенергә дә атлыгып тормый.

Шулай да, бер җылы мизгел булган икән әле ул көнне. Бер ярты сәгать чамасы без тып-тынычта әни белән икәү сүзсез генә ятып тордык. Җитәкләшеп. Соңгы елларда авылга кайткач, гел әни янында йоклыйм, без аның белән еш кына шушылай җитәкләшеп ята идек тә, ул сүзсез генә минем кулны кысып куя иде. Бу юлы да шулай булды.

– Әни, мин сине яратам, – дидем мин.

– Мин дә сезне яратам, кызым...

Бу аның без яшәгән дөнья белән алыш-бирешен өзеп бетергәнче әйтеп калдырган соңгы сүзләре булгандыр, мөгаен.

Без табиблардан кирәгеннән артык күпне өмет итәбез икән!

Аннан... Аш шулпасын каба алмады, тамагыннан ризык үтмәсә дә, коса башлады, табиблар өеп биреп кайтарган даруларны эчертү турында сүз дә булырга мөмкин түгел иде. Һәм без, һичьюгы укол кадатып карарга дип, авылның фельдшерын чакырырга булдык. Фельдшер ханым исә әнине игътибар белән карады да, шундук:

– Ашыгыч ярдәм чакырырга кирәк. Комага китеп бара әби, – дип нәтиҗә ясады.

Ни хикмәт булгандыр ул көнне – инде икенче мәртәбә килүебез булса да, фельдшерның «кома» дигән сүзләрен кабатлап карасак та, кизү торган табиб әнинең хәлен нишләптер реанимациягә салырлык дип тапмады. Аны каталка белән гомуми палатага кертеп салдылар. Дүртенче кеше итеп. Кич иде ул. Башкалар йоклыймы, йокымсырап ятамы, ә без әни белән икәү уяу. Әни әледән-әле укшый, мин шуны вакытында сизеп алып, тизрәк башын калкытырга тырышам. Һәм тагын чираттагы өянәкне көтеп ятам. Әнинең күзләре ачык, тик ул инде мине дә, аптырашып кереп-чыгып йөргән шәфкать туташларын да күрми сыман. Минем күз яшьләремне дә, аны әледән-әле өшкереп азаплануымны, догалар укуымны да сизми...

Эх, авыртуны да сизмәсен иде ул! Икенче көнне иртүк палатага килеп кергән икенче табиб, шундук чаң сугып, безне Арча больницасына җибәрде – 60–70 чакрым араны гел ыңгырашып барды әни. Арчадан, күпме ялынсак-ялварсак та, кире бордылар – тагын юл буе сызланып-авыртынып кайтты ул. Район больницасында реанимация аппаратына тоташтырганда да, шәфкать туташларының һәрбер хәрә-

кәтен тоеп, ыңгырашып ятты. Әнине бу өстәмә газапларга дучар итүебезне күрү шулкадәр, шулкадәр авыр иде. Хәзер дә менә уйлыйм-уйлыйм да, ни өчен чәчрәп чыгып: «Өйгә алып кайтып китәбез», – димәдем икән, дим? Медицина хезмәте күрсәтү дип аталган, үз тәртип-кагыйдәләре булган билгесез система алдында каушап калу идеме бу, табибларга чиксез ышанумы? Әни озакламый айныр, «уяныр», күзләрен ачар да: «Ай Аллам, тагын исән калдым бит, үлә-үлә дигәч тә, үлмим бит әле мин, кызым», – дип көлеп, тагын гадәттәгечә торып утырыр дип өметләнүме? Ничек кенә булмасын: «Больница булышмый инде аңа, азаплаудан мәгънә юк», – дигән сүзне без барыбер табиблардан көтәбез икән. Ә югыйсә адәм баласының савыгу-савыкмавы, бу дөньяда яшәве-яшәмәве, чынбарлыкта, табиблардан тамчы да тормый бит. Дәва – табиблардан, шифа – Ходайдан... Мин әнинең үләр алдыннан больницага бер дә, бер дә эләгергә теләмәвен белә идем бит югыйсә... Әмма шундый хәлиткеч мизгелләрдә үз өстебезгә җаваплылык алырга, күрәсең, бер дә әзер түгелбез... Әзер булырга кирәк икән... Мондый чакта янәшәңдә ни уйласа, шуны әйтердәй, сиңа дөрес киңәш бирердәй ышанычлы табибларның да булуы кирәк икән.

Әтинең туганнарын да үзенекедәй якын күрә иде.

Әниебез бер атна реанимациядә ятканнан соң, аңына килә алмыйча үлеп китте. Гаиләдәге олы бала – абыебыз атна буе көн саен реанимациядә аның караваты янында идәнгә тезләнгән килеш «Ясин» укыды. Әниебезнең, Аллага шөкер, үзе артыннан дога кылырлык балалары калды. Безгә дә шундый бәхетләр насыйп булсын...

...Әтисе үлгәч, бер танышым гаҗәеп дөрес сүзләр әйткән булган икән. «Кеше үлми икән ул», – дигән иде. Миңа да әни исәндер кебек. Аз гына арттарак, үткән заманда – безнең балачакта хәзер дә яшидер кебек ул. Көрән төстәге күәс чиләгән артлы урындыкка терәп куйган да, җиңнәрен сызганып ипи басадыр әни. Мин аны ак яулыгын артка чөеп бәйләгән, зәңгәр җирлеккә вак саргылт чәчәкләр төшкән күлмәге өстеннән алъяпкыч бәйләп куйган итеп күз алдына китерәм. Әнә кечкенә буйлы, түгәрәк гәүдәле «карачутыр» кызчык та шунда бөтерелә. Хәтеремдә бит бу мизгел... Безнең яраткан күрше әбиебез – Хафаза апа (без аңа «апа» дип дәшергә күнеккән) авырып тора иде ул чакта. Хафаза апаның үз балалары яшүсмер чакта ук үлгән, сеңлесенең кызы гаиләсе белән бик еракта яши.

– Әни, әни, ә Хафаза апа йөри алмый башласа? – дип сорыйм мин, әнинең әле бер, әле икенче ягына төшеп.

– Кызым, бар әле читкәрәк, камырга чүп төшерәсең бит, – ди әни. Шулай да, минем сорауны игътибарсыз калдырмый үзе, эшеннән бүленмичә генә, үзеннән-үзе аңлашылган бик гадәти нәрсәләр турында сүз баргандай җавап кайтара.

– Үзебезгә алып чыгасы булыр.

– Чынлапмыни? Алай да буламыни? Ул безнең туган түгел бит?

– Булмасани...

Дөрес, Хафаза апаны үзебезгә алып чыгарга туры килмәде, аны карарга сеңлесенең кызлары күченеп кайтты. Ләкин әнинең сүзләре күңелдә гаҗәпләнү катыш яктылык уятып калдырды: шулай эшләргә кирәк икән бит, мондый чакларда туган, туган түгел, тиеш, тиеш түгел дип торырга ярамый икән...

Тагын бер истәлек. Без әни белән әбине (әтинең әнисен) мунчага алып барырга әзерләнәбез. Идән уртасына калын одеял җәябез, әбине көч-хәл белән күтәреп алып, баш астына юка мендәрләр салып, шунда яткызабыз. Инде хәзер җайлап кына одеялның баш-башларыннан тотабыз да, күтә... Тик әби хәйран олы гәүдәле шул әле ул безнең. Әбине сак кына кире идәнгә куярга туры килә, әби үзе дә көлә, әни дә, без дә көләбез... Көлүен көләбез, әмма мунча да бит, урыс әйтмешли, «не отменяется». Ярдәмгә ир-ат – каралты-кура арасында йөргән әтине чакырырга туры килә... Соңгы юлга озатканчы, кул-аяклары хәрәкәтсез калып, ике еллап урын өстендә ятты әбиебез.

Безнең әни игелекле эшне авырсынып түгел, ничектер ихлас күңелдән эшли иде шул ул. Тормышы гел рәхәт дип булмаса да (кая рәхәт булсын инде хатынкызга – ир-атның эчә-эчә эшләве гадәти хәл, норма саналган совет заманында!), бик тиз «торып баса» белә иде әни. Туган җанлы иде.

Үләренә инде бер-ике генә ай калган булгандыр – мин кайткач, әни телефоннан әтинең еракта яшәүче туганнарына – абыйсының кызына шалтыраттырды. Шулкадәр җылы итеп, якын күреп хәлләрен сорашкач, чын күңеленнән әйтеп куйды:

– Без исән чагында кайтыгыз...

Әни туган-тумачага һәрвакыт ачык йөзле булды анысы, безнең өйдән (төп йорт бит!) кеше беркайчан өзелеп тормады, шулай да инде олыгайган, урын өстенә яткан әнидән бу чын, ихлас чакыруны ишетү миңа башта бик гаҗәп тоелды. Аннары инде күңел рәхәтлек белән тулды. И изге күңелле әниебез безнең, син менә шундый шул инде...

Кемнәр бар иде дә, кемнәр юк... Гомерләрнең бик тиз үтеп, буыннарның алышынып торуын күрәсеңтоясың да, күңелне моңсулык баса. Әнинең сүзләрен тагын бер кат ишеткәндәй буласың: «Без исән чагында кайтыгыз...»

Без исән чакта...

Гөлнара
САБИРОВА

Әби тәрбиясе алу – зур нәрсә. Килешерсез, әби белән үскән бала иманлырак та, тынычрак та, гаилә җанлырак та була. Аларның тормыш тәҗрибәсе, үгет-нәсыйхәтләре киләчәк өчен зур мая шул. Кайчак әбиләр әнидән дә якынрак була. «Әбием сабаклары» дигән яңа сәхифәбез дә юктан гына тумады. Ул – әбиләребезгә әйтергә өлгермәгән рәхмәт сүзләре дә, аларның безгә биргән сабакларын башкалар белән уртаклашу да...

АКЪӘБИ

«Әле дә Ходайның төне бар...»

Йокларга яткан саен бер сүз. Кечкенә әби һәр көнне шулай кабатлый, ә мин исә гел кояшлы көн генә булып торса, ничек рәхәт буласы бит, дип, аның сүзләренең мәгънәсен аңлый алмыйм. Әбиемнең әлеге сүзләренең асылына төшенер өчен, шактый тормыш күрергә кирәк булган икән. Хәзер үзем дә яткан саен күңелдән шул сүзләрне кабатлыйм. Аннары – догаларны. Анысы да әбидән.

Әтиемнең әнисе Рушания әби яшьли, без бала вакытта ук авырып үлеп китте. Аның турында хатирәләрем күп түгел. Ике әбине, аерып, Зур әби һәм Кечкенә әби дип йөртә идек. Рушания әби – Зур әби, таза, гәүдәле хатын, әтинең әнисе булгач, дәрәҗәсе дә зуррак булгандыр, күрәсең. Әнинең әнисе Зәкия, киресенчә, гәүдәсе белән дә кечкенә, үзе дә игътибар үзәгендә булырга яратмый иде.

Мин Кечкенә әби белән үстем. Әни сессиягә, укырга киткәндә дә аның белән кала идем. Ә инде 5-6 нчы сыйныфларда укыганда, гомумән, аның белән яши башладым (хәер, көндезләрен өйдә булам, кич аңа кунарга керә идем. Әби безнең күршедә үк яшәде). Шуңа күрә әби миңа аеруча якын, кадерле. 10 нчыга киткәч, әби миңа өемдә куна башларга кушты. «Син тиздән өеңнән чыгып китәсе кеше, кыз бала укырга киткән җиреннән кире кайтмый инде ул, әти-әниең янында бул», – диде. Әби һәрвакытта-гыча хаклы булып чыкты...

«Ильяс кызы диярләр... Алдыңны-артыңны карап йөр, кызымны син аздырдың, дип, әтиең миңа да сүз әйтәсе булмасын!» – монысы җәй көннәрендә кич чыкканда көн дә кабатлана торган сүзләр. 32 яшендә ирсез калып, гомерен ялгыз үткәргән әби өчен тәртип, кеше сүзе дигән төшенчәләр бик әһәмиятле иде. Күп сөйләп тә тормый үзе, бер-ике генә җөмлә әйтә, тик шундый иттереп әйтә, барысын да төшенәсең һәм кабатлап сорап тормыйсың.

Иртәләрен көн дә әби намаз укыганда уянам. Иң рәхәт мизгелләр шул. Әби авыз эченнән генә догаларны көйли, аннары кычкырып теләк тели: «Ил-көннәргә тынычлык, малларга бәрәкәт бир...» Кич яткач, миңа да «Аятел-көрси» укырга куша. Җиде күршеңә кадәр җитә, имеш. Мин күңелдән генә күршедәге җиде йорт, анда яшәүчеләрне барлап, дога сүзләрен кабатлыйм...

Бик күп укый иде әби. «Казан утлары», «Азат хатын», «Татарстан яшьләре»ннән беркайчан да өзелмәде. Гомер буе фермада сыер сауган хатынның үзе туплаган белеме



кайбер галимнәр белән бәхәсләшергә җитәрлек иде. Газета-журналлардагы кызыклы язмаларны җыеп куя, безгә дә укыта. Аның бер тапкыр да зарланганын, арыдым дип тик ятканын, авырыйм дип сызланганын хәтерләмим. Инде 80 нән узгач, әти белән әни, безнеке дә җитә дип, әбинең бакчасына бәрәңге утырттырмадылар. Әти анда печән чәчте. Әби исә, әни эштән кайтып җиткәнче дип, өй артында бер почмакта тагын бакча казып, бәрәңге утыртып куйган. «Бәрәңге өлгергәндә табак тотып сезгә йөрмим, үземнең бакчадан казып аласым килә!» – сүзе шул булды. Анысын да без кайткалаганчы утарга, төбенә өяргә тырыша: «Үзегезнең дә эшегез күп...» Беркайчан да беркемгә дә авырлык китермәскә тырышты ул. Үлеме дә шундый булды. Кечкенә әбиебез 86 яшендә, җомга көнне, иртәнге намазын укып, кайнарга куелган чәе кайнап та чыгарга өлгермичә, мәңгелек йортына күчende... Гел тели торган теләкләренең берсе шул иде: «Авырып кеше кулында калырга, балаларымны мәшәкатьләргә язмасаң иде. Җиңел үлемнәр бир, Ходаем». Теләге фәрештәләрнең «Амин!» дигән чагына туры килгән...

Беркайчан беркем белән дә сүзгә килмичә, әмма үз сүзен һәрвакыт әйтеп килгән Кечкенә әби – безнең өчен намус, тырышлык, үҗәтлек үрнәге. Ак әби иде әбиебез (әти исә «Әби әүлия иде» ди, киявеңнән шундый бәя алу үзе үк күп нәрсә турында сөйлидер ул). Аннан аласы үрнәк, ишетәсе нәсыйхәт шулхәтле күп булгандыр, исән чагында тагын да күбрәк сөйләшеп-аралашып калмаганга йөрәк әрни. Урыны оҗмах түрләрендә булсын иде...



ТҮЗ, ЙӨРӘК!..

Бик пөхтә, төгәл шагыйрьләр бар. Андыйлар шигырьләренең туган елын көненә, хәтта сәгатенә кадәр теркәп баралар. Беренчедән, үз иҗатыңа мондый игътибарның кирәклеген мин соңрак аңладым. Икенчедән, яңа шигырьләремнең датасын яза башласам да, китап чыгарганда бертөрлелекне саклап, билгеле булганнарын да төшереп калдырырга туры килде. Ә менә «Безнең күңел» дигән шигыремнең язылу вакыты гына түгел, язылу тарихы да бүгенгедәй хәтеремдә.

1982 ел, 5 октябрь. Төнге сәгать 12 тулып килә. Ирем, язучы Фаил Шәфигуллин иртән эшкә киткән җиреннән һаман кайтмый. Күршебез шагыйрь Зөлфәт янына да берничә тапкыр төшеп мендем (алар – 6 нчы, без 8 нче катта яшибез). Зөлфәт исә миннән көлә генә: «Кызлар янында, конечно... Барыбер синнән яхшыракны тапмаячак, кайта, көт!» – ди. Ә минем гомер булмаганча эчем поша. Юкса Фаилнең кайтмый калган чаклары булмады түгел бит инде.

Әтиләрен дүрт күз белән көтеп торучы кызларымны йоклатып, ике тәрәзә арасында йөрим. Урам якка караган тәрәзәдән нииндидер тишек табып, орчык җебе кебек сузылып, нәзек җил керә. Үтә бер шәфкатьсезлек белән өшетеп, җанымны бораулый. Шомлы да, сәер дә салкынлык... Үземә һич кенә дә урын тапмыйм. Ә йокы дигәнең тәмам качкан. Бераздан кәгазь, каләм алып, өстәл артына утырам:

Безнең күңел

Безнең күңел нигә моңлы икән,
Безнең күңел ничә кыллы икән? –
Онтыласы иде тын калып.
Гарасатка кереп югалмыйча,
Гөнаһларга гына уралмыйча,
Бәхет йөрсә икән юл ярып.

Безнең күңел нигә моңлы икән,
Безнең күңел ничә кыллы икән? –
Ду купканнар шашкын хисләрем.
Чыгымчылап чапкан ярсу
тайдай,
Дулкыннарга кунган моңсу айдай,
Ярсу яки моңсу кичләрем.

Безнең күңел нигә моңлы икән,
Безнең күңел ничә кыллы икән? –
Кушылырга сайрар кош кирәк.
Җаннан җанга йөри
моңнар күчеп,
Тик дөньясы гына әллә ничек —
Сабырлыклар бирсен,
түз, йөрәк!..

Безнең күңел ничә кыллы икән,
Безнең күңел нигә моңлы икән?..

Йөрәк тынгысыз. Нигә бу кадәр тынгысызлана? Күңел нигә шулкадәр зеңли? Башка нигә әллә нинди кирәкмәгән уйлар килә?.. Нинди сәер фаразлар бу? Белмим. Әмма язам:

Гарасатка кереп югалмыйча,
Гөнаһларга гына уралмыйча...

Юкса мин бит әле тулы канлы ир хатыны, томрап торган ике балам үсә. Күптән түгел генә шәһәр үзәгеннән җылы, иркен яңа фатир бирделәр. Өстәвенә, бакчабызда өй сала башладык. Нәкъ шушы октябрьнең 6 сыннан 10 сына кадәр сузылачак озын ялда Фаил үзенең баҗасы, кайнеше, дуслары белән өмә ясарга тиеш. Минем дә аларны ашатып-эчертү өчен ризыкларым әзерләнгән.

Кыскасы, уфтанырга да, моңаерга да, гарасат-бураннар турында уйланырга да тиеш түгел идем мин ул көнне.

Дулкыннарга кунган моңсу айдай,
Чыгымчылап чапкан ярсу тайдай,
Моңсу яки ярсу кичләрем...

Моңсу кич. Чынлап та, шул караңгы төндә ниндидер моңсулык баскан мине. Ә ярсып, күкрәк читлеген бәреп чыгардай булып типкән йөрәк: Бәхет йөрсә иде юл ярып! – дип үтенгән. Куркыныч бер тетрәнү белән җиде төн уртасында язган бу шигыремдә, ялгыз калачак авыр киләчәгемне сизенгән кебек, Аллаһыдан сабырлык сораганмын...

Тик дөньясы гына әллә ничек,
Сабырлыклар бирсен,
Түз йөрәк?..

Җаннан җанга йөри моңнар күчеп...

Әйе, ул моң, моңлы моңсулык, моңлы сагыш – миннән балаларыма да, туганнарыма да, әти-әниемә дә күчте. 4 яшьлек нарасыем өзелеп-өзелеп Яңа елны көтә башлады. Кыш бабайдан: «Кыш бабай, әтиемне өебезгә кайтар, зинһар!» – дип үтенә дә, кызыл бишмәт кигән дәү, көчле, гайрәтле, тылсымлы бабай – аның соравын, һичшиксез, канәгатьләндерәчәк дип өметләнде. Бәйрәмнәр үтеп, могҗиза булмагач: «Әни, көрәк белән барыйк та әтиемне казып алыйк. Мин үзем казыйм!..» – дип үрсәләнә. Ә күзләреннән аккан яшь елгасы, җыя барсаң, халык җырларында әйтелгәнчә, күл булыр иде, билләһи...

Озак та үтми «Безнең күңел» дип аталган бу шигырьгә композитор Илгиз Закиров, үзе кайдандыр күреп алып, мәгънәсенә бик тә тәңгәл килгән көй язган. Аны җырчы Миңгол Галиев өйрәнде. «Тик дөньясы гына әллә ничек» дигән сүзләре аркасында, җыр Татарстан радиосы каршындагы худсоветтан үтмәгән. Миңгол Галиев аны кабаттан, шәхси фаҗигасе кебек итеп: «Дөньям гына минә әллә ничек», дип яздырып тәкъдим итте. Җыр, худсоветтан үтеп, радио фондына теркәлде.

«Социалистик Татарстан» газетасының «Гаилә» битеннән дә, ноталары белән бергә җыелып, басмага әзерләнеп беткәч, шушы бер җөмлә өчен набордан төшеп калды ул. Ә бәлки кечкенә генә кереш сүзе ошамагандыр?.. «Сез яраткан җырлар» рубрикасыннан барырга тиешле әлеге җырга: «1982 елның 5 октябрендә туган шигырь бу. Ул төнне өч шигырь язылды. Өчесе дә моңсу, сагышлы. Табигатьтә ниндидер үзгәреш буласын сизгән киек кош сыман, күңел актарылды, җан елады ул кичтә. Минем тормышыма зур фаҗига китерәчәк, хәләл җефетем хәл эчендә яткан каһәрле төн булган ул. Күңел күзем белән шуны сизгәнмен икән, үзем дә белмичә, шул сызлануларны шигырьгә салып утырганмын. Ә аңым белән ул газапларны бер тәүлеккә соңрак кичердем», – дип алхәбәр язган булганмын...


Илгиз аны яңадан «Татарстан яшьләре» газетасына биргән. Шулай итеп, бу «Безнең күңел» дигән җыр, ноталары белән бергә, «Татарстан яшьләре»нең 1984 елгы 11 август санында дөнья күрде.

Вакытлар үтте. Сүзләренә көе ятып торган, күңелләрне айкап чыгара торган бу җырны, Миңгол Галиевтән тыш, Мирсәет Сөнгатуллин, Салават Фәтхетдинов, Мөнир Якупов, Гөлзадә һәм башка тагын бик күп җырчылар башкарды. Хәзер дә җырлыйлар.

Бу шигырьгә композитор Илдус Якуповның да, үзгә бер нәфислек, эчке бер тетрәнүне сиздереп язган мөлаем көе бар.

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА

Фото: Фаил Шәфигуллинның тууына – 50 ел уңаеннан оештырылган искә алу кичәсе. Яшел Үзән. 1989 ел.



Беркөнне интернеттан кызыклы мәгълүматлар чүпләп утырганда, «Ир белән хатын аерылышканда балага ничек зыян салмаска?» дигән мәкаләгә күзем төште. Дөресен әйтим, аны укып чыккач, өстемә кайнар су койган кебек булды. Тетрәнүемнең сәбәбе шуңа бәйле: әтием белән әнием аерылышкач, 6 яшем тулып килгән мәлдә ятимлек ачысын үз башымнан кайчандыр мин дә кичергән идем.

КИМСЕНҮ



Хәмидә ГАРИПОВА

Сигез ел бергә гомер иткән никахлы ире, аңа белгертмичә генә өр-яңа йортыбызны сатып, акчасын кесәсенә салган һәм сөяркәсен ияртеп, Үзбәкстанның Гөлстан дигән оҗмахка тиң матур төбәгенә качып чыгып киткән. Әнкәйгә бу вакытта нибары 28 яшь! Хәсрәтеннән, гарьлегеннән ничек җиңеләймәде икән, дип, әлегәчә шаккатам. Ул безне – берсеннән-берсе кечкенә өч баласын ияртеп, дәү әнинең иске өенә кайтып утырды. Ул чакта да түрәләр арасында бармагы үзенә кәкреләре очраган, күрәсең: законнарны әйләнеп узу юлын тапканнар бит, кул кулны югандыр инде. Югыйсә әткәй белән әнкәй бергә көч түгеп салган ул йорттан ир белән хатынга өлеш тигез чыгарылырга тиеш булгандыр. Без – балалар да урамда калганбыз лабаса.

Олы бала булганга күрә сыңар канатлы тормышның авырлыклары миңа күбрәк эләкте бугай. Югыйсә беренче классны тәмамлаган елны ук, тигез әти-әниле балалар рәхәтләнеп йоклап яткан чакта, таң белән торып, кәтмән тотып, чөгендер басуына чыгып китәр, әнкәй янәшәсенә буразнага басар идеммени?! Сыңар канатлы, китек күңелле, бөтен дөньясына рәнҗүле, хыянәте өчен әткәйгә кара үчле, чарасызлыктан, хәсрәтеннән үз-үзен белештермәс дәрәҗәгә җиткән әнкәй үзе дә ат урынына эшли, безне дә кызганып тормый иде. Ач-ялангач булмасак та, рәхәт тә күрмәдек. Авыр капчыклар да сөйрәдек, ат урынына җигелеп арба тарттык, җир казыдык, тирес түктек, мал карадык... Әнкәйнең нәрсәгә булса да ачуы чыкса, безне ташлап киткән әткәйне сүгәргә, хурларга тотына. «Сүземне тыңламасагыз, үги анагыз янына илтеп атам, ул сезнең баш түбәсенә кадак кагачак», – дип куркытканы да хәтердә. Ни галәмәт, шул чакта үземнең эчтән генә әткәйне яклыйсы килгәне истә калган. Әткәй белән әнкәйнең гаилә тормышы көйле булып чыкмаганга без – гөнаһсыз сабыйлар гаепле түгел бит инде. Ә әнкәйнең үз туксаны – туксан...

Мин мәктәптә бик әйбәт укыдым, әмма һәрчак үземне әтиле балалардан ким санадым һәм, моңа гарьләнеп, еш кына әнкәйдән качып елый идем. Әтиләрне күрше авыл мәктәбенә, толыпка төреп, ат чанасына утыртып илтеп куялар, барып алалар. Минем кебек әтисезләр, кар көрте ерып, җәяү атлый... Үсмер чагым. Әтиле сыйныфташларым 1 Май бәйрәме көнне клубка, «Зәлидә» бәйрәменә биергә китте.

Ә мин, яшьле күзләремне тутырып, аларга кызыгып карап калдым. Сыерыбызның ашарына беткән: миңа, арыш капчыгы кыстырып, урманга менәргә – ялан кулларымны кисә-кисә, яңарак кына кар астыннан чыккан камышларны җыярга кирәк...

Ул чакта йорт саен сигез-тугыз бала. Хатын-кызлар колхоз эшенә йөри. Үзләре эшкә киткәндә олырак балалары кечерәкләрен карап тора. Күп балалы гаиләләрдә тәрбияләнүчеләр бездән матуррак киенмәсә, тәмлерәк ашамаса да, аларның күңеле минекедәй китек түгел иде шул. 7-8 сигез яшьлек чагымда мине гел бер уй газаплый иде. Әнкәй күрмәгәндә, көзге каршына барып басам да, чандыр гәүдәле, озын сары чәчле, зәңгәр күзле, нечкә беләкле, салам сыйраклы кыяфәтемне җентекләп күздән кичереп, балалыгым белән аптырап карап торам. Башка балаларны аталары, кирәксезгә санап, ташлап китмәгән бит. Әллә без барыбыз бик ямьсез микән? Алай дисәң, күрше кызларының да миннән артык җире юк кебек. Нигә алайса аларның әтиләре бар, ә безнеке юк? Әнкәй дә сөйкемле, эшчән, җитмәсә, бик матур җырлый да.

Бервакыт әнкәй: «Атагыз эчте, өстемнән йөрде, сөяркәсе яныннан кайткач, миңа кул күтәрә иде. Шуңа күрә үзем силсәвиткә барып, аерылышырга гариза язып бирдем», – дип ычкындырды. Шул мәлдә күзләремә яшь бәреп чыкты. «Бөтен әтиләр дә эчә инде... Әнә күрше апа, ире исереп кайткач, алты баласын ияртеп, әбиләренә кереп кача. Әткәй айныганчы син дә дәү әниләрдә торып торасың калган!» дигәнемне әнкәй яратмады. Хәтта авызыма да сукты.

Әткәй сугышта катнашкан, яраланган, өченче группа инвалид буларак, аена 33 сум пенсия ала торган булган икән. Шуның өчтән берен безгә алимент итеп түли башлагач, акчага бик тилмереп яшәсәк тә, әнкәй отказ язды. Бу сәер гамәлен ул: «Аның икенче хатыны бала таба алмый. Сез – кыз балалар, киләчәктә кеше кешесе булачак затлар. Олыгайган көнендә япа-ялгыз калгач, атагыз сездән алимент юллап йөрсә нишләрсез? Булачак гаиләләрегездә абруегызны төшермәсен, сезгә кыенлык китермәсен өчен шулай эшләргә булдым», – дип аңлатты.

Мәктәптә укыганда да, институтта белем алганда да янәшәмдә тулы булмаган гаиләләрдә үскән яшьтәшләрем гел булды. Шуңа карамастан, күбесенең үз әтиләре белән ихластан аралашуына, һәрдаим аларның ярдәмен тоеп яшәүләренә бик кызыга идем. Ә безнең күперләр яндырылган... Институт тәмамлап, бер ел эшләгәч, әтиле егеткә кияүгә чыктым. Кайнатама «әти» дип әйтүләре шулчаклы рәхәт иде! Мин аларга эшләп ярарга тырыштым. Кирәк булса ут өертеп утын ярам, ирләрдән калышмыйча печән чабам, мал карарга миңа гына куш – яратып башкарам, өйдә бөтен эшне белеп эшлим... Әмма эшләп кенә ярап булсачы! Аның улына караганда ике мәртәбә күбрәк хезмәт хакы алсам да, кайнанамның бар белгән сүзе: «Минекен ашыйсың, хәерче!» – булды. Атлаган саен «атасыз бала» дип рәнҗетте. Әйтерсең, җилдән туганмын...

Яшермим, тормышның ачысын-төчесен күп күрдем, күз яшемне шактый түктердедәр. Иремнең читкә салулаган чакларын да белеп тордым. Ничек кенә булмасын, улларым үз аталары канаты астында, тигез гаиләдә үсәргә тиеш дип, барысына да сабырлык белән түздем. Аның белән егерме өч ел яшәп калдык. Авариягә очрап гарипләнеп калганнан соң, унтугыз ел буе бөтен авырлыкларны җилкәмә салып, тормыш арбасын үземә җигелеп тартырга туры килде. Иремне соңгы сулышына хәтле кыенсынмыйча тәрбияләдем. Яшермим, күз яше түккән чакларым да булды.
Тик бер нәрсәгә шат идем: балаларым ятимлек ачысын татымады. Аларга ир-атларга хас рухи ныклык, төпле киңәш бирергә үз аталары янәшәдә иде. Хатын-кыз ничек кенә тырышса да, хатын-кыз инде: дөньяны сизгер йөрәге, нечкә хисләре аша кабул итә.
Ир-атларда логика көчле, шунлыктан акыл белән эш итәләр. Ничаклы гына тырышмасын, ялгыз хатын янында үскән бала – ир баламы ул, кызмы – тулы канлы тормышка әзер түгел. Чөнки анда ир кешегә карата хөрмәт хисе, ныклык тәрбияләмиләр, ул үзен кешедән ким санап үсә, хәтта язмышына үчле була һәм... күп вакыт ата-анасы хатасын кабатлый.

Әйе, һәр җимерелгән гаиләдә – бала фаҗигасе.

Яшьли кыерсытылган бала, үскәч, бер мескенгә яки, киресенчә, кансыз бандитка әверелергә мөмкин. Ялгыз аналар, уллары балигъ булгач та, аларны итәк астыннан чыгармыйча, «мәми авыз» итеп тәрбиялиләр. Малае өйләнсә, андый әни киленне улыннан көнли, яшь гаиләгә тыкшына, аларның бәхетенә аяк чала... Аерылган ир дә, хатын да киләчәктә үз парын табып, яңа гаилә корырга, бәхетле булырга хокуклы, әлбәттә. Ике арада калып, чарасызлыктан бәргәләнгән, үзәге өзелгән бичара бала гына кызганыч...

Хатын-кыз элеккеге иреннән югарырак пост биләргә, акчаны күбрәк эшләргә, бала караучы, репетитор, гувернантка ялларга да мөмкин. Әмма сабыйга чит-ятлар тәрбиясе түгел, үз әтисенең тезендә утыру, аның үчтекиләп сөюе, җитәкләп урамга алып чыгуы, бергәләп футбол тибү кадерлерәк. Шул бәхетле мизгелләр хакына әтисенең җитешсезлекләрен күрмәмешкә салышырга, хәтта ачулануын, шукланса, сүз тыңламаса, йомшак җиренә берне шапылдатып алуын да гафу итәргә риза.

Бүгенге көндә кайсы гаиләгә карама, анда астыртын гражданнар сугышы бара. Бер-берсенә юл куясы, мәрхәмәтлерәк, сабыррак буласы урынга, газиз сабыйларының бәхетен җимерү, психикасын какшату, авыруга сабыштыру, холкын бозу хисабына булса да өстен чыгарга омтылу күзәтелә. Кызганыч, кайчанга чаклы барыр бу капма-каршылык?

Фото: www.pixabay



ХЕЛЬСИНКИ: ГАДИЛЕКТӘ – МАТУРЛЫК



Римма ГАЗИЗОВА

ЯНӘШӘ ТОРГАНЛЫКТАН, САНКТ-ПЕТЕРБУРГТА ЯШӘҮЧЕЛӘРГӘ ФИНЛЯНДИЯГӘ БАРЫР ӨЧЕН ШЕНГЕН ВИЗАСЫН АЛУНЫҢ БЕР КЫЕНЛЫГЫ ДА ЮК. ШУҢА КҮРӘ ДӘ АЛАР, РӘХӘТЛӘНЕП, ЯЛ КӨННӘРЕНДӘ ФИНЛЯНДИЯГӘ АЗЫК-ТӨЛЕК, ЙОРТ КИРӘК-ЯРАКЛАРЫ АЛЫРГА БАРЫП КАЙТА.



Урамнарда велосипедта йөрүчеләр (алар өчен махсус юллар бар) бик еш очрый.



Мине аеруча нык гаҗәпләндергәне – җирле халыкның беркая да ашыкмавы.

Финляндия, көт мине!

Санкт-Петербургта яши башлавымның дүртенче елы китте. Ә мин кул сузымы гына тоела башлаган фин иленә бер тапкыр да аяк басмаган әле... Меңәрләгән чакрымнарга сузылган урманнары, исәпсез-хисапсыз сауналары, әкияти Лапландиясе, Төньяк балкышы белән дан тоткан Финляндия һаман үзенә дәшә сыман. Ниһаять, бергә укый торган дусларым белән сөйләштек тә, Хельсинки белән танышып кайтырга булдык. Кирәкле документларны илтеп тапшырып, ике атна үтүгә, виза әзер иде инде. Ярты елга бирелгән әлеге виза белән Шенген биләмәсенә кергән илләргә сәяхәт итәргә мөмкин. Әмма Финляндиягә бару саны, башка илләргә чыгуга караганда, күбрәк булырга тиеш. Шулай ук иң беренче сәяхәтең дә нәкъ менә Финляндиягә булуы зарур. «Бу шартларны үтәгән очракта, фин шенгенын кабат алу проблема булмаячак», – дип аңлаттылар безгә.

Ярый, виза кулда, рюкзаклар җыелды. Уйларым белән инде күптән Хельсинки урамнары буйлап атлыйм кебек. Мотор тавышы гына киресен исбатлый... Финляндия чигенә кадәр – өч, Хельсинкига кадәр тагын өч сәгатьтән артык юл үттек. Алты сәгать ярым автобус тәрәзәсеннән карап бару озаграк, әлбәттә. Юлчылар белән җиңел машинада тизрәк һәм арзанрак бәягә барырга да мөмкин анысы. Әмма автобус белән ышанычлырак. Шуңа без бу вариантны сайладык.

Финляндия чиген үткәндә, паспорт тикшерүе уздык. Тикшерүчеләрнең бармак эзен алган чакта «палэц» дип әйтүләре шулкадәр кызык тоелды. Россиялеләр Финляндиягә еш йөргәч, алар инде рус телен дә аңлый, димәк. Контрольне бик тиз узып, җылы бинадан урамга чыктык. Фин иленең салкын һавасы үпкәләргә тулды. Суларга рәхәт булып китте...

Гадилектә – даһилык

Финляндия – бик салкын ил. (Елның кайсы фасылында барсаң да!) Өстәвенә, туктаусыз яңгырлар ява. Хельсинки өстендә куерган болытлар бу кечкенә шәһәргә сорылык өсти. Аның каравы, шәһәрдәге төрле төсле йортлар әлеге сорылыкны оныттыра. Биредә сез күккә ашкан биек биналарны күрмәссез. Шулай ук балконнар да сирәк очрый. Хельсинкига һич кенә дә купшылык эзләп килергә ярамый, чөнки сез аны биредә тапмаячаксыз. Йортлар җыйнак, гади. Санкт-Петербургтагы затлы сарайлардан соң, Хельсинкидагы архитектура аеруча тыйнак тоелды. Шул гадилеге белән җәлеп итте дә бугай инде ул мине. Хельсинкида булган тыныч ритм күңелем халәте белән тәңгәл килде. Без бер-беребезне таптык, ахрысы...

Хельсинки урамнарында кыйммәтле машиналарның сирәк булуына игътибар иттем. Питерда һәркем берничә миллионга алган машиналарда җилдерә, берсен-берсе уздыра-уздыра мактаныша, ә финнарда бу масаюны күрмәдем. Тыйнаклар, димәк. Тагын



■ Сенат мәйданы үзәгендә Россия императоры Александр II гә һәйкәл урнашкан. Ни өчен рус императорына? Сере бик гади: 1809 елда Финляндия Россиягә кушыла. Ә 1817 елның 6 декабрендә нәкъ менә Александр II Финляндияне автоном республика дип игълан итә, фин телен дәүләт теле буларак таный.

бер кызыклы факт – биредә трамвайларның тавышы бик әкрен. Россиядә бит аның килгәне әллә каян ишетелә, ә аларда трамвай андый көчле тавыш чыгармый, тыныч йөри. Гүя шәһәрдәге тынлыкны бозарга теләми.

Сауналар Финляндиядә милли символ булып санала.

Дөнья буйлап сәяхәт иткән, Рим, Париж, Мюнхен, Нью-Йорк, Гонконгларда булган турист өчен Хельсинки, бәлки, күңелсез һәм артык тонык тоелыр. Әмма дөнья ыгы-зыгысыннан алҗыган, купшылыктан туйган бер мизгелдә монда килсәгез, тәнегез генә түгел, җаныгыз да ял итәчәк. Ләкин Ватанга кире кайткач, кызу ритмга көйләнүе генә бераз авыррак булуы ихтимал, чөнки Финляндиядәге салмак агым йогышлы ул. Биредә вакыт шулкадәр акрын барган кебек: туктаусыз каядыр ашыккан дөньядан бу тынычлыкка килеп эләккәч, бераз сәеррәк тә әле башта.

Ничек туңмыйсыз сез, финнар?!

Монда елның 170 көнендә кояш чыкмый, диләр. Без яңгырга эләкмәдек, хәтта кояш та чыккалады, әмма... суык иде. Өстемдә җылы свитер, муенга шарф урадым, куртка киеп килдем... Әмма барыбер туңдым. Ә финнар үзләре исә юка гына пальтолардан йөри. Әйтерсең, салкынны бөтенләй тоймыйлар. Кайберләре, безне үртәгән сыман, изүләрен дә төймәләмәгән әле. Ничек туңмый соң алар?!

Хельсинкига барып кергәндә иртәнге сәгать алты иде. Бездә, гадәттә, иртән урамнарны себерәләр, ә Хельсинкида... юлларны шампунь салынган су белән юалар икән! «Стериль» шәһәргә килгәнбез», – дип көлештек... Гаҗәеп чиста ил ул Финляндия! Урамда бер чүп күрмәссең. Дөрес, кануннар да кырыс. Мәсәлән, шәхси йортлар янында хуҗалык кирәк-яраклары ятарга тиеш түгел. Моның өчен зур күләмдә штраф салып китәчәкләр.

Урамнарда йөргәндә финнарны ерактан ук танып аласың. Күбесе озын буйлы. 50 яшьтән узган ир-ат һәм хатын-кызлар да үзләрен карап, зәвык белән киенеп йөри. Чәчләренең төсе аксыл, алардан яктылык бөркелеп тора. Читтән караганда шулкадәр затлы булып күренә! Алар янәшәдән узып киткәч, артка борылып карыйсы, истә калдырасы килә үзләрен... Матурлык салоннарына, чәчтарашханәләргә күбрәк 50 яшьтән өлкәнрәкләр йөри. Гадәттә, без бит мондый җирләрдә яшьләрне күрергә күнеккән, ә Хельсинкида, киресенчә, өлкәннәр үзләрен бик нык карый, ә яшьләр тышкы кыяфәтләренә артык зур игътибар бирми дигән нәтиҗәгә килдем.

Әйтергә онытып торам. Финнарның сауна яратуы һәркемгә мәгълүм инде. Ә менә биредә һәр өч кешегә бер сауна туры килгәнен, бәлки, белми дә торгансыздыр. Сауналар биредә һәр җирдә: шәхси йортларда, отельләрдә, коттеджларда, хастаханәләрдә һәм хәтта заводларда да. Җирле халык өчен ул чистарыну, тәнне генә түгел, җанын ял иттерү урыны да.

Кесәң калын – тамагың тук

Безнең күзлектән караганда, Финляндия – яшәү өчен артык кыйммәт ил. Биредә бәяләр бик югары. Тамак ялгап аласың килсә, кесәңнең калын булуы кирәк. Мисал өчен, кафеларда бургерлар бездәгедән берничә мәртәбә кыйммәтрәк. Иң арзан комплекслы төшке аш өчен 700 сум тирәсе түләргә кирәк. Кибетләрдә дә бәяләрдән чәчләр үрә торды. 1 килограмм тавык түшкәсе – 500 сум!

Хельсинки – идеаль шәһәр

Хельсинкиның архитектурасы аерым игътибарга лаек. Шәһәр буйлап атлаганда классицизм, модерн, функционализм стильләренең үзара шулкадәр туры килеп, үзгә бер ансамбль барлыкка китереп утыруларын күрәсең. Чатта очраган даруханә яки кибет бинасы да бу матурлыкка үзенә бер ямь өсти сыман. Шәһәр урамнары белән шулай танышып йөреп кенә дә эстетик ләззәт алырга мөмкин. Әйткәнемчә, бу каланың бөтен матурлыгы – гадилегендә. Аны күрә белергә генә кирәк.

Хельсинкиның иң истәлекле урыны – Сенат мәйданы. Биредәге калкулыкта Кафедраль собор урнашкан. Ерактан ук күренеп тора ул. Якынрак килгәч, мәһабәт колонналары, Гайсә пәйгамбәр тормышындагы вакыйгаларны сурәтләүче барельефлары, соборның түбәсенә урнаштырылган цинктан коелган унике апостол сыны күзгә ташлана. Соборның эчке бизәлеше православ чиркәүләреннән аерылып тора. Гадилек, аклык хөкем сөрә, купшылыкның эзе дә юк.

Янәшәдә – университет бинасы. Каршы якта XIX гасырда яшәгән күренекле сәүдәгәрләрнең резиденцияләре күренә. Сенат мәйданын әйләндереп алган йортлар да бу гармонияне һич кенә дә бозмый, үзара тәңгәл килеп тора.

Хельсинкида чиркәүләр бик күп. Иң үзенчәлеклесе, әлбәттә, мәрмәр кыяда урнашкан лютеран чиркәве. Темппелиаукио чиркәвен кыяны


http://www.building.am

Темппелиаукио чиркәвен җир астында урнашса да, аның эчендә бик якты. Сере шунда – табигый яктылык чиркәүнең пыяла гөмбәзе аша үтеп керә.

уеп эшләгәннәр. Чиркәү кыяның тупас өслеге белән гаҗәп дәрәҗәдә туры килә. Менә шундый кызыклы архитектура корылмасы. Финляндиягә килеп, әлеге чиркәүне күрмичә китәргә һич ярамый.

Моңарчы күрмәгән яңа илдә бул да, милли музейга да барма, имеш. Барам, әлбәттә! Финляндиянең Милли музее гаҗәеп бинада урнашкан. Тышкы кыяфәте буенча ул урта гасырлардан калган скандинав сарайларын хәтерләтә.
Бу бинаны башкасы белән һич кенә дә бутап булмый. Декоратив ташлардан торган фундамет, роман стилендәге тәрәзәләр, биек конус сыман манара... Аңа күз ташлауга, әкияткә эләккәндәй буласың. Финляндиянең тарихы һәм мәдәнияте белән тирәнтен танышып, вакытыңны файдалы үткәрү өчен шәп җир.

Шәһәрнең истәлекле урыннары белән танышып йөргәндә күңелемдә бу шәһәрдә яшәп карау теләге уянды. Уңайлы, артык зур да түгел, чиста һәм тыныч... Яшәү өчен идеаль шәһәр! Шундый уйлар белән кинәнеп Хельсинки һавасын сулыйм. Күзәтәм һәм... тыңлыйм. Тыныч су өстендә баеп барган кояш нурларын. Балык сата торган базар өстендә очкан акчарлаклар тавышын. Иске парктагы талгын җилдә тибрәлгән өрәңгеләр шавын. Рәхәт... Хушлашмыйм, саубуллашып кына торам!

Финча балык ашы пешереп сыйлану өчен өйдән дә чыгасы юк!

P. S. Сәяхәтебезгә бу урында нокта куелмады әле – паром белән Швеция башкаласына юл алдык. Стокгольмда һәр почмак саен әкият яшеренгән сыман. Түбәләрдән, үзең дә сизмәстән, Карлсонның өен эзлисең... Гасырлар тарихын туплаган һәм заманча кыяфәтле әлеге шәһәр бер күрүдә әсир итә. Әмма бусы инде бөтенләй башка хикәя...

Фин ашлары



Калакукко – әлеге ризыктан башка финнарның бер генә бәйрәме дә узмый. Гади итеп әйтсәк, бу – балык пирогы. Камыр арасына сөләйман балыгы, пешкән йомырка, яшел тәмләткечләр тезәсең, өстенә йогырт яки каймак агызасың. Бик тәмле, әмма калорияле ризык.



Финча балык ашы – тәмле дә, өстәвенә, әзерләве дә ансат. Форель балыгы, бәрәңге, шәмәхә суган, бодай оны, сөт, лимон согы гына кирәк. Болар инде һәммәбезнең суыткычында табыла. Финча балык ашы пешереп сыйлану өчен өйдән дә чыгасы юк!



Перунапиирайта – бәрәңге боламыгына тары боткасын төреп әзерлиләр. Аны ак май белән майлап, өстенә укроп сибеп, духовкада пешереп алалар. Бу ризык ашказаны өчен бик җиңел, аны диетада утыручылар да ашый ала.



Пюттипанна – фин кухнясының тагын бер традицион ризыгы. Бәрәңге, кишер, суган, ысланган казылык, томат пастасы, тәмләткечләр кирәк. Тәртип буенча һәрберсе табага салынып, сүрән утта пешерелә. Табынга каймак белән чыгарыла.



Хернерокка – бәйрәм ризыгы түгел. Бу борчак ашын финнар гадәти көннәрдә яратып пешерәләр. Авыр эш белән шөгыльләнгәннән соң, ул организмга көч кертә дип саныйлар. Әйе, ул туклыклы, тәмле, әмма шулай ук артык калорияле ризык.
Фото: http://e-finland.ru

16+

СИҢА ГЫНА ТАРТА КҮҢЕЛ...



Хәбир ИБРАҺИМ (АХИР), язучы, шагыйрь, драматург, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, язучыларның А. Алиш, Ш. Маннур премияләре лауреаты; гаилә стажы – 29 ел; ике бала атасы.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар кирә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Ни генә булмасын, иң элек хатын-кызның тышкы кыяфәтенә, киеменә, йөрешенә игътибар итәсең. Пөхтә, матур киенгән кызлар, ханымнар һәрвакыт хөрмәт уята. Алардагы пөхтәлек, гүзәллек мәхәббәт хисен көчәйтә. (Тагын озын чәчле кызларга күз төшмичә калмый, билгеле. Су анасы – минем өчен эталон!)

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Барысын да – чөнки ул хатын-кыз! Гомумән, хатын-кызларга үпкәләргә ярамый, аларга үпкәләп йөрү – язык гамәл. Нинди генә очракта да ир булып калырга кирәк. Яшермим, яшь чагымда үпкәләгән, хәтта рәнҗегән чакларым да булгалады. Еллар узган саен, мин ул «чир»дән арына бардым. Күп очракта хатын-кызны түгел, үземне гаепләргә өйрәндем.

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Яратмавын... Үзеңне яратмаганын сизәсең дә, югаласың. Югалу – ул инде шулай ук гафу итмәү дигән сүз. Ләкин мәхәббәттән качып булмый, диләр бит. Күп очракта, чынлап та, кача да алмыйсың – яңадан әйләнеп кайтасың. Әлбәттә инде, синең өчен бик тә якын кеше булса, сине кире кабул итсә, онытмаса, гафу итсә...

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Икесе дә якын. Мин моны язучы буларак әйтәм. Тик ир-атны илһамландыручы алиһәләр нигәдер өйдә утырмый, кайдадыр йөри кебек. Нинди генә чибәр, акыллы булса да, өйдәге хатын алиһә булудан туктый. Ул партнерга әверелә. Тормыш матавыклары хисләрне җимерә, чөнки бергәләп көнкүрешне алып барырга, көн саен туып торган проблемаларны хәл итәргә кирәк. Тегесе кирәк, монысы кирәк, тегесе җитми, монысы җитми... Матур итеп киенсә, бизәнсә дә, хатының инде барыбер алиһә була алмый, чөнки ул... хатын, закунлы хатын. Әмма өйдә тынычлык, комфорт тудыра алган хатын ул һәрчак зур хөрмәткә лаек. Күрәсең, хатыннан иң элек шул нәрсә таләп ителә, шул көтелә.

5 Ир кеше өчен хатыны аңа дус та була аламы?

– Яшь чакта «дус» дип әйтеп булмый әле, ә менә азрак олыгая башлагач – әйе. Хатын шул тиклем якын кешегә әйләнә, аңар хәтта орыныргa да базмый башлыйсың. Монысы шаярту инде, билгеле... Бер түбә астында яшәгәч, тормышны бергә алып баргач, дус булып яшәмичә дә булмый. Дуслык – тормыш китереп куйган мәшәкатьләрне җиңеп чыгарга ярдәм итә.

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Хәтерлим... Мин аңа беренче күрүдә үк гашыйк булдым. Шул төнне үк яраттым. Икенче көн иртән инде тәкъдим ясадым. Ә ул каршы килмәде... Танышу, бер-береңне табу, кавышу – барысы да язмыш инде ул. Мине ул көнне башка кыз белән таныштырырга тиешләр иде. Олы апамның танышы, бухгалтер кыз, диделәр. Ләкин аның янына барырга чыккач, ниндидер йомыш белән апамның башка бер танышларына керергә кирәк булды. Киләчәктә «әби» дип дәшәчәк кешемнең фатирына кергәнебезне кайдан белим?! Шунда мин аның бердәнбер кызы белән таныштым да инде. Әйткәнемчә, бер күрүдә ошаттым. Шуннан соң апага: «Мин теге бухгалтер кызың янына барып тормыйм инде, апа, шушы кызга гына өйләнәм!» – дидем. Апа башта бик аптырады, аннан минем белән килеште.

Минем хатыным гади, аңлаешлы, җирдә нык басып тора – күктән йолдыз чүпләми. Өйдә минем үзем кебек тагын бер хыялый яшәсә, тормышны алып барырга авыр булыр иде кебек. Дөрес, кайвакыт янәшәдә андый хыялый затны да күрәсе килә, ләкин бу бары тик хыял гына булып кала... Өйләнү, әйткәнемчә, язмыш инде ул, ә язмыштан берничек тә качып булмый. Шуңа күрә дөрес өйләнмәдем яки дөрес кияүгә чыкмадым, дип зарланудан ни файда?

7 **Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый, диләр. Шулаймы?**

– Инкарь итә алмыйм, мөгаен, шулайдыр. Менә минем хатыным әниемә охшамаган дип әйтер идем, кайбер охшашлыклар да бар бит! Әнием аш-су әзерләүгә бик оста иде – хатыным бу яктан аны да уздыра. Әнием сабыр, тыйнак кеше иде, барына канәгать була белде – хатынымның да тормышка таләпләре зур түгел. Әнием беркайчан тавыш-гауганы яратмады – хатыным да, кайчакта бераз кызып алса да, тиз тына, үч сакламый, миңа булган үпкәләрен тиз оныта. Шуңа күрә дә без аның белән утыз елга якын инде бергә яшибез.

8 **Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?**

– Тормыш ул шундый нәрсә: бүген ире күп табарга мөмкин, иртәгә – хатыны... Җәмгатем миннән акчаны күбрәк таба дип борчылган ирләрне аңламыйм. Кем генә тапса да, иң мөһиме – акчаның өйгә, балаларга кайтуы, читкә китмәве. Дөресен әйткәндә, акча табуы кемгә дә җиңел түгел хәзер.

9 **Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?**

– Әгәр дә ул кыз сиңа ошый икән, аның беренче булып сүз кушуы икеләтә бәхет ләбаса! Шулай да табигате буенча хатын-кыз тыйнак, сабыр булырга тиеш дип санала, активлык иң элек ир-атлардан көтелә. Ләкин бөтен кеше дә бертөсле була алмый бит. Яшь чагымда, мәсәлән, мин үзем дә артык кыюсыз идем, кыз бала буй җитмәс бөек сер булып тоела иде. Хәзер үзгәрдем, чөнки ул минем өчен сер булудан туктады.

10 **Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?**

– Хатын-кыз колак белән тыңлый, шуңа күрә сөйләшә белү, «сайрый» белүдер. Ләкин буең, кыяфәтең, аз гына матурлыгың булмаса, күпме генә сайрасаң да, аларны үзеңә каратуы читен булыр иде. Без, ирләр, хатын-кызның матурлыгына караган кебек, алар да безнең тышкы кыяфәтебезгә игътибар итмичә калмый. Ир кеше көчлеме-түгелме, аягында нык басып торамы-юкмы – моңа да битараф түгелләр. Акча таба беләме, ышанычлымы, ир белән хатын-кыз буларак, бер-берегезгә туры киләсезме-юкмы – болар да соңгы урында түгел.

11 **Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?**

– Иҗат кешесе булгач – иҗади ягыма. Язучылык эшенең никадәр авыр, катлаулы һөнәр булуын аңласын иде. Мин бит дәүләт эшендә эшлим, иҗатка кич кайткач яки ял көннәрендә генә тотынам. Тик бер генә хатын-кыз да иҗат эшен эшкә санамый, аны хобби дип кенә уйлый. Иҗатның бөтен җелегеңне суырганын аңларга теләми ул. Ходай тарафыннан бирелгән сәләт һәм бәхет – катарсис гына түгел, җәза да бит ул иҗат.

12 **Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?**

– Мине куркытмый... Күп кенә туташ һәм ханымнар үз чибәрлекләрен күрә белми, үзләрен чибәр дип санамый. Тик, кызганыч, әгәр дә чибәр хатын-кыз үзенең чибәрлеген аңласа, ул күп очракта уйный, кылана, сайлана башлый. Ә сайлануның кайда алып барганын барыбыз да яхшы беләбез: ялгызлар арасында чибәр ханымнар, туташлар шактый. Чибәрлек төс-кыяфәттә генә түгел, күңелдә, җанда да булсын иде дә бит... Җирдә фәрештәләр аз шул.

13 **Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.**

– Хатын-кызларга багышлап мин шундый шигырь язган идем:

Кызыксыну уяталмас көн кичергән җылы ояң,
Кызык миңа синең гүзәл әчке дөньяң.
Ул бүленгән меңәрләгән, йөзәрләгән кисәкләргә,
Шуңар күрә мөмкин түгел аны үлчәп-исәпләргә.
Шуңар күрә сине эзли, сиңа гына тарта күңел,
Беләм ләкин бу дөньяда
сине (хатын-кызны) аңлау мөмкин түгел.

Андый очраклар күп булды. Язып, сөйләп тормыйм. Алар – минем әсәрләремдә.

14 **Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный. Мондый очракта нишлисез? Үзегезнең хаклы булуыгызны исбатларга тырышып карыйсызмы, әллә инде юл куясызмы?**

– Юл куймыйча ярамый... Хаклы булсаң да, кайчакта үзеңне хаксыз итеп танырга мәҗбүр буласың. Алла сакласын, юк кына нәрсәдән дә зур тавыш-гауга чыгуы бар. Җәмгыятьтә болай да кушылудан бигрәк, аерылышулар күбрәк хәзер. Холыкларыбыз туры килмәде, дип, яшьләр, әнә, җиңел генә аерылыша да куя. Шул ук вакытта балалар хакына, йә булмаса, әти-әнигә борчу салмыйк, дип яшәүчеләр дә күп. Бәлкем, шулай дөресрәктер дә.

15 **Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән.**

– Хатын – повар минем, аш-суга бик оста ул. Шуңа күрә мин кайтышка өйдә ашарга пешмәгән очракларны хәтерләмим. Ул яктан мин бәхетле. Хатын-кызның юньләп ашарга пешерә белмәгәне дә шактый аның. Бу очракта аларны сүгеп тә, әрләп тә ашарга пешерергә өйрәтеп булмый, бары тик тешеңне кысып түзәргә генә кала. Хәер, без, ирләр, үзебез дә алтын түгел бит инде: кимчелекләребез, җитешмәгән якларыбыз аларныкыннан да күбрәк...

16 **Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан.**

– Мин үзем тиз җыенам. Көттергәч, ачу чыга, билгеле. Тик түзәргә туры килә – түзми кая барасың?! Теләсә кайсы гаиләнең нигезендә, ятрутудан кала, түземлек, сабырлык ятадыр. Шулар булмаса, гаилә дә юк – ул бик тиз таркала.



ПАРАЗИТЛАРДАН САКЛАНАБЫЗ

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар гигиена турында аңламый, кайда нәрсә күрәләр – шуны тоталар, авызларына кабалар, кулларын юмыйлар. Паразит суалчаннар шуңа күрә аларның организмын үз итә дә инде. Җәй көне паразитлар бигрәк тә азына. Баланы алардан ничек сакларга, нәрсәгә игътибар итәргә соң? Бу хакта медицина фәннәре кандидаты, Казан дәүләт медицина университеты доценты Фәйрүзә ГЫЙЛЬМУЛЛИНА сөйләде.

Бездә иң киң таралган паразитлар – бер күзәнәкле лямблия. Ул 3-6 яшьлек балаларда еш күзәтелә. Иң киң таралган гельминтлар (суалчаннар) – бабасыр һәм аскарида (йомры суалчан). Бабасыр да 95-96 процент очракта мәктәпкәчә яшьтәге балаларда була. Аскарида, токсокара (эт аскаридасы) туфрактан иярә. Аларның күкәйләре җирдә берничә ел сакланалар. Кыш көне кар астында да исән чыгалар.

Лямблия организмга кайнамаган су эчкәндә, су коенганда һәм юылмаган ризыктан эләгә. Бабасыр эчәклектә яши. Ул, кеше йоклаганда, арт юлның сырлы өлешенә күкәй сала. Бу вакытта арт юл бик нык кычыта. Бала арт юлын кашыганда, бабасырның күкәйләре тырнакка иярә һәм сабый бармагын авызына капканда эчкә керә. Ул күкәйләр киемгә, урын-җиренә, уенчыкларга, йорт җиһазларына эләгеп, озак вакыт сакланырга һәм башка кешеләргә күчәргә сәләтле.

Аскарида җәй көне еш очрый. Бу вакытта бакчада яшел тәмләткечләр, яшелчә, җиләк-җимеш өлгерә. Аларны юмыйча ашаганда паразит белән зарарлану куркынычы арта. Чөнки аның күкәйләре, кешенең эчәклегеннән чыккач, туфракта өлгерә. Ә кеше эченә кергәч, 20-30 см зурлыктагы паразит булып үсә. Кайбер балалар ком яки туфрак ашарга ярата, суалчан күкәйләре организмга шулай да эләгергә мөмкин.

Паразитлар үзен сиздермәскә, анализлар биргәндә очраклы рәвештә генә ачыкланырга мөмкин. Шулай да баланың үз-үзен тотышына карап, анда паразит булу ихтималын үзеңә дә чамаларга була. Организмга паразитлар кергәндә баланың аппетиты югала, эче авырта, тәрәте бозыла, хәлсезлек борчый, башы авырта. Шулай ук бала көйсезләнә, авырлыгы артмый. Тәнгә тимгелләр чыгу, тән һәм күз кычыту ихтимал. Паразитлар эчәклектәге углевод, аксым, май, микроэлементлар һәм башкаларны үзләштерә һәм, әлбәттә, токсиннар бүлеп чыгара. Шуңа күрә кешене интоксикация да борчый.

Бу билгеләр күзәтелгәндә, балалар табибына мөрәҗәгать итәргә яисә инфекционистка күренергә кирәк. Күп паразитлар эчәктә яши. Шуңа да беренче чиратта тәрәткә анализ ясату шарт. Аны берничә тапкыр тикшертәләр, чөнки паразитлар күкәйләрен көн саен салмый. Анализның беренче мәртәбә уңай булуы әле организмда паразит юк дигән сүз түгел. Башка төрле анализларны, мәсәлән, кан анализын да тапшырырга була. Шулардан чыгып, табиб дәвалау ысулын билгели.

Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы елга ике тапкыр (язын һәм көзен) паразитлар киң таралган җылы якларда профилактика курслары уздырырга тәкъдим итә. Бармакларын авызга кабарга, тырнак кимерергә яраткан, ком яки туфракны авызына капкан балаларга педиатр антигельминт терапиясе узарга киңәш итә, дарулар билгеләнә. Тик бу препаратлар барлык балаларга да килешеп бетми. Шуңа күрә аларны үз белдегең белән кулланырга ярамый, организмга зыяны булуы бар. Фәкать табиб билгеләгән препаратларны гына кулланырга кирәк.

Балада паразит табыла икән, гаиләдәге башка кешеләргә дә тикшерену үтәргә кирәк.

Киңәш

Паразитлардан саклану өчен нинди киңәшләрне истә тотарга кирәк:

- кулларны юып йөрергә, урамнан кергән баланың кулын һичшиксез сабынлап юдырырга;
- кайнамаган су эчмәскә;
- гигиена кагыйдәләрен үтәргә;
- тырнакларны кисеп йөрергә;
- яшелчә, җиләк-җимешләрне, яшел тәмләткечләрне юмыйча ашамаска.

Киңәш

Бала организмында паразит табылса, билгеле бер туклану диетасы сакларга кирәк: бик баллы, артык майлы, кыздырылган, ысланган ризыклар, полуфабрикатлар ашамау хәерле. Халык медицинасыннан кабак, канәфер, җитен орлыклары, әче әрем, гөлбадран кулланырга була. Тик башта табиб белән киңәшләшү кирәк, үләннәр барлык балаларга да килешмәскә мөмкин.

Паразитлардан котылганнан соң, эчәклек микрофлорасын да торгызырга кирәк. Моның өчен табиб препаратлар язып бирергә мөмкин. Рационга оеган сөт ризыкларын (катык, кефир) кертергә була. Витаминнар да эчә башларга мөмкин. Дөрес туклану режимын җайга салу, хроник ашказаны-эчәк авыруларын вакытында дәвалау зарур. Организмга яңадан паразитлар кермәсен өчен, профилактика чараларын үтәргә кирәк.

ТАБИГАТЬ ДӘВАЛЫЙ

**Паразитлардан арынырга булышучы үләннәр күп ул. Белеп җыйсаң, белеп кул
лансаң, табигать – иң яхшы табиб. Хәзер нәкъ менә үләннәр җыя торган вакыт.**



Ак әрем

Июнь-июль айларында яфракларын, йомшак сабак очларын җыялар. Дөрес киптерелгән әрем көмеш сыман төстә, көчле исле була.
2 аш кашыгы әремгә 200 мл кайнап суынган су коеп, 15 минут «су мунчасы»нда кайнаталар, аннары 45 минут суытып, сөзәләр. Сыгынтыга кабат су өстәп, 200 мл күләменә җиткерәләр. Ашарга 30 минут кала, көнгә өч тапкыр 1/4 стакан эчәләр. Агулы үлән, йөкле ханымнарга аны эчү тыела.



Гөлбадран

Су буйларында, юл читләрендә, калкурак урыннарда биек булып үсә торган каты сабаклы үсемлек. Чәчәкләре сабак очындагы сары төймәләрне хәтерләтә. Дару буларак, чәчәкләрен җыялар.
1 аш кашыгы гөлбадранга 1 стакан кайнап суынган су салып, 15 минут «су мунчасы»нда төнәтеп, суыталар, аннары, сөзеп, ашар алдыннан көнгә өч тапкыр берәр аш кашыгы эчәләр. Шулай ук агулы үлән, дозаны арттыру хәтәр.



Кабак төше

300 г чистартылган кабак төшен төеп яки иттарткычтан чыгарып, 50-60 г су кушалар. Дәвалана башларга ике көн кала, клизмалар ясап, эчәклекне чистартырга кирәк. Дәваланасы көнне, йокыдан уянуга, 300 г кабак төшен азлап-азлап ашап бетерәсе. Өч сәгатьтән эч йомшарткыч дару эчеп, ярты сәгатьтән клизма куярга кирәк. Организмны бик авыр чыга торган суалчаннардан да арындыра.



Канәфер

Аш тәмләткеч сыйфатында кулланылган канәфер чынлыкта бик көчле дару да. Паразитлардан арыну өчен аның төнәтмәсен кулланалар.
1 г канәфер порошогына (кофетарткыч аша чыгарып, үзегез дә ясый аласыз) 100 мл кайнап торган су коеп, 1 сәгать төнәтәләр. Шушыны өчкә бүлеп, ашарга 20 минут кала, өч тапкыр эчәләр.



Фото: www.pixabay

Чабыр үләне

Коры, комлы җирләрдә, тау битләрендә җиргә ятып үсә.
Чәчәк ату чоры – майдан сентябрьгә кадәр. Июнь-июль айларында җыялар.
2 аш кашыгы кипкән үләнгә 200 мл кайнап суынган су салып, 15 минут «су мунчасы»нда төнәтәләр, суытып сөзгәннән соң, ашар алдыннан көнгә ике-өч тапкыр берәр аш кашыгы эчәләр.



КОШ ТЕЛЕ

Җырчы Эльмира КӘЛИМУЛЛИНА хакында «чын татар кызы», «тыйнак, мөлаем», диләр. Чын татар кызы булмыйча соң! Балачагы авылда, әби-бабай янында үтсен дә... Мәһиҗиһан әбисе белән Ләлә дәү әнисеннән кул эшләренә, аш-су әзерләү серләренә өйрәнеп үскән кыз ла ул! Яраткан әбекәе – авылның атаклы аш-су остасы булган. Ул пешергән чәкчәк, кош телләре никах, туй табыннарын бизәгән. Чираттагы осталык дәресенә Эльмираны чакыруыбыз да юкка гына түгел. Аның аш-суга осталыгы турында ишеткән идек инде. Әбекәе өйрәткәнчә кош теле пешерергә тәкъдим итте ул.



Кирәк:

- 4 йомырка;
- 1 чәй кашыгы шикәр комы;
- 2 аш кашыгы шикәр оны (сахарная пудра);
- он;
- 1 литр үсемлек мае (сыйфатлырагын алырга тырышыгыз);
- бер чеметем генә тоз.

Эш барышы:

■ камыр өчен 2 йомырка сытабыз (әбием башта йомыркаларны юа иде, ди Эльмира). Ә калган ике йомырканың фәкать сарысын гына алабыз.

■ Йомыркага бер чеметем тоз, 1 чәй кашыгы шикәр комы салып, чәнечке яки тимерчыбык туглагыч белән яхшылап туглыйбыз.

■ Камыр үзлерәк булсын өчен, онны кулланыр алдыннан гына илибез. Аны азлап-азлап кына салып, камыр басабыз. Он белән бергә тулыр-тулмас 2 аш кашыгы шикәр оны да салына. Камыр йомшак, ләкин уклау белән җәярлек булырга тиеш.

■ Камырны өч өлешкә бүлеп, токмач камыры кебек юка гына итеп җәябез.

■ Җәелгән камырны кырлы-кырлы



Фото: Ксения Богданова

кискеч белән 2,5 см тасмаларга бүләбез (үткен пычак та ярый). Һәр тасманы 4 см озынлыгында кыйгач шакмаклап кисәбез.

■ Үсемлек маен калын төпле чуен савытка салып, кыздырырга куябыз. Майның барысын берьюлы салып бетермәскә дә мөмкин. Ләкин ул бик аз да булмасын, кош телләре майда йөзеп пешәргә тиеш.

■ Май чыжлый башлагач, өч-дүрт шакмак камырны салып, башта бер ягын, аннан икенче ягын әйләндереп кыздырабыз. Алтынсу төскә кергәч, тишекле чүмеч белән сөзеп алып, майдан арындыру өчен, тәлинкәгә тезеп торабыз.

■ Суынган кош телләрен матур вазага тезеп, өстеннән шикәр оны сибәбез (кечкенә иләк белән сибүе уңай).

Мастер-класс «Беседка» иҗат студиясендә уздырылды.



РЕКЛАМА

Гүзәл Шаһигәрәевадан

ТӘМЛЕ СЫР



Кирәк:

- 1 л сөт;
- 400 г 20 процентлы кибет каймагы;
- 3 йомырка;
- 1 аш кашыгы тоз.

Эш барышы:

■ Сөткә 1 аш кашыгы тоз салып, кайнатырга куябыз.

■ Ул кайнаган арада икенче бер савытта кибет каймагы белән йомыркаларны бик яхшылап туглыйбыз.

■ Сөт кайнап чыккач, аз-азлап кына йомыркалы каймакны кушабыз, гел болгатып торабыз.

■ Сөт эремчекләнә башлагач, уттан алып, вак тишекле иләктән сөзәбез. Иләккә берничә кат марля да куярга була.

■ 3 сәгатьтән сыр әзер. Бик йомшак, тәмле була ул, «Адыгейский» сырга охшаганрак.

■ Хәзер аш тәмләткеч үләннәр чоры җитә, сырга туралган яшел укроп та кушарга була.

PRESSA

ҖИДЕ КАТ УЙЛА, БЕР КАТ КИС



«Кирәк әйбереңне эзләп, бер кибеттән икенчесенә чабасы булмасын иде. Кич белән өеңдә, яраткан диваныңа утырып, тынычта, рәхәттә генә сайлыйсы иде аны», – дип, бер тапкыр булса да хыялланмаган кеше юктыр ул. Ә әйбер сайлауның кайберәүләр хыялланган мондый ысулы бар – товарны дистанцион юл белән сатып алу дип атала ул.
Бу очракта сатып алучы белән сатучы арасында туган мөнәсәбәтләрнең хокукый ягы турында Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе Казан территориаль органының үсеш һәм эчке базарны координацияләү бүлеге җитәкчесе, юристлар берләшмәсе әгъзасы Марсель ШАҺИДУЛЛИН сөйли.

Интернет-кибетләр белән бәйле әлеге мөнәсәбәтләр Россия Федерациясенең «Кулланучыларның хокукларын саклау турында»гы законы (№ 2300-1 (26.1 маддә), 07.02.1992 ел) һәм товарларны дистанцион юл белән сату кагыйдәләре турында Россия Федерациясе хөкүмәте кабул иткән карар буенча регламентлаштырыла, ягъни, тәртипкә салына.

Товарны дистанцион ысул белән сату түбәндәгечә эшләнә: сатып алучы башта каталог, буклет, проспект, фотосурәтләр, төрле элемтә чаралары (телевизион тапшыру, радио элемтәсе һәм башкалар) ярдәмендә сатучы тәкъдим иткән товар, аны тасвирлаган текст белән таныша; үзе сайлаган товарны кайтарту буенча фирма белән килешү төзи.

Интернет-кибеттән товар алганда сатып алучы сатучы белән читтән торып кына аралаша, шуңа күрә ул мөрәҗәгать иткән фирма ышанычлы булырга тиеш.

Үзебезнең шәһәрдә урнашкан кибеткә барып, аннан нидер сатып алганда, без кибетнең исемен дә, аның төгәл адресын да яхшы беләбез. Кулыбыздагы чекка карап, сатучының исем-фамилиясен дә ачыклый алабыз. Хокукларыбыз бозылган очракта, ул сатучыны табып, аңардан нидер таләп тә итә алабыз. Әмма барлык интернет-кибетләр дә, кызганычка каршы, үз сайтларында юридик адресларын да, сездән заказ алган сатучының исем-фамилиясен дә төгәл күрсәтми. Димәк, сатып алучы буларак үз хокукларыңны якларга туры килгән очракта, кыенлыклар туарга мөмкин.

Әгәр фирма ышанычлы икән, ул бернәрсәне дә яшермәячәк: закон буенча сатып алучы белергә тиешле бар мәгълүматны сайтында урнаштырачак. Товарның үзенчәлекләре, бәясе, кайтарту шартлары, гарантия вакыты, түләү тәртибе, килешү кайчанга кадәр көчендә булачак – кагыйдә буенча, ике арада сату-алу турында килешү төзелгәнче, фирма сатып алучыга боларның барысы хакындагы мәгълүмат белән танышырга тәкъдим итәргә тиеш.

Товарны дистанцион юл белән сатып алганда төрле аңлашылмаучанлыклар килеп чыкмасын өчен, интернет-кибетне дөрес сайлагыз. Барысына да игътибар итегез: башка сатып алучылар калдырган фикерләргә, түләү, товарны китереп җиткерү ысулларына. Әгәр товарны сатучы фирма турында мәгълүмат бик аз яки бөтенләй юк икән – үзегезгә кирәк әйберне башка җирдән эзләгез. Сатучы як ышаныч уятмый дип санийсыз икән – товар өчен алдан түләү шарты белән килешмәскә кирәк. Товар кайткач кына түли торган башка берәр интернет-кибет табарга тырышыгыз.

Интернет аша сатарга ярамаган товарлар барлыгын да онытмагыз. Бу исемлеккә исерткеч эчемлекләр, кайбер дару төрләре һәм башкалар керә.

Өстенлекләре

- Товар сатыла торган сайтны үзегезгә җайлы вакытта һәм күпме телисез, шуның кадәр карый аласыз.
- Күңелегезгә ошаган товарга заказ бирү өчен сайтка язарга да, телефоннан шалтыратырга да мөмкин. Заказ өчен ничек түләргә икәнен дә үзегез хәл итәсез: терминал аша да була, банк картасы белән дә.
- Дистанцион сәүдә белән шөгыльләнүче фирмалар, гадәттә, товарның сатып алучы кулына ничек барып ирешүе турында да алдан кайгырталар: заказны алу урыннарын уңайлы җирләрдә оештыралар. Кайбер компанияләр аны почта бүлекләренә җибәрә; икенчеләр, күпмедер өстәп түләү бәрабәренә, өйгә үк китереп бирә.
- Фирма сайтындагы товар, аларның сезнең шәһәрдәге кибетләре ассортиментыннан шактый аерыла – ул күпкә баерак.
- Күптән эшләүче фирмаларда еш кына төрле акцияләр булып тора: бәйрәмнәр алдыннан, сезон ахырында ташламалар ясыйлар, яңа килеп кушылган яки даими клиентларына бүләкләр бирәләр һәм башкалар.

Кимчелекләре

- Товар чынбарлыкта сайтка куелган рәсемнән күпкә кайтышрак булырга мөмкин. Кием-салымны алдан киеп карау мөмкинлеге дә юк.
- Сайлаган әйбер сиңа күпмедер вакыт узгач кына килеп җитә. Көтәргә яратмаучылар өчен бу, әлбәттә, зур минус. Өстәвенә, сайлаган товар складта булмаса, алдан билгеләнгән вакыттан тагын да озаграк көтәсе була.
- Үзеңә туры килгән әйберне сайлап алу авыр. Ярамаган очракта, алыштыру мәшәкатьле.



Яшел чалбар, шәмәхә блузка һәм кызыл шарф. Ачык һәм җете төсләр яратам дип, чама хисен онытып җибәрергә ярамый шул. Тутый кошка охшап калмас өчен, берничә гади генә кагыйдәне истә тотарга кирәк.

ЯКТЫ «ТАП»ЛАР КИРӘК

Иң мөһиме – төс

Киемне ачып җибәрү өчен җете төстәге аксессуарлар кулланырга уйласагыз, ул дөрестән дә җете һәм чиста төс булсын. Саз төсендәге шарф берничек тә яшел төстә түгел, һәм мондый аксессуар бер генә киемне дә ачып җибәрә алмый. Зәңгәр икән, ул чип-чиста зәңгәр төстә булсын, ә болганчык суны хәтерләтмәсен.

Берәү җитә

Киемдә ачык «тап»лар ничәү булырга тиеш дип саныйсыз? Фәкать берәү генә! Бөтен нәрсәгә дә берьюлы игътибарны җәлеп иттерү урынсыз. Бик матур ачык җете төстәге шарф яки сумка, беләзек яки аяк киеме... ул нәрсә дә була ала. Ләкин кием ансамблендә андый ачык «тап» берәү генә булсын!

Бер-берсенә якын төсләр

Җете төсле киемнәрне бик яратсагыз, гади генә бер кагыйдәне онытмагыз: төсләр үзара ярашырга, бер үк гаммада булырга тиеш. «Салкын» төстәге киемгә «җылы» төсле аксессуар такмыйлар. Шул очракта образыгыз зәвыклы күренер. Белеп торыгыз: кара, ак һәм әфлисун төсеннән кала, теләсә кайсы төснең «салкын» да, «җылы» да төсмерләре була. Киемдә артык җете төсләрне күп куллану кешене олыгайтып күрсәтүен дә истән чыгармагыз.

Иң җете төс – кара төс

Ачык төстәге аксессуарлар кара кием белән бик шәп яраша. Ничек кенә сәер яңгырамасын, кара төс үзе дә җете төс. Җете аксессуарларны кара кием белән яраштырып куллана белү – яхшы зәвык билгесе.

Ничек сайларга

- Муенсалар, чылбырлар күлмәк уемына, итәк озынлыгына, киемнең төсенә һәм тукымасына карап сайлана.
- «V» кисемле яка уемына кулонлы чылбыр яки шундый ук формадагы колье килешә. Яка уемы тирәнрәк булган саен, муенса да озыная, ул уемның уртасына кадәр төшеп торсын яки чак кына озынрак булсын.
- Түгәрәк уемлы киемгә озын муенсалар, чылбырлар бигүк килешми. Бу очракта муенга терәлеп үк торган яки яка уемына ук төшеп җитмәгән муенсалар матур. Күлмәк кыскарак булган саен, муенсаның сәйләннәре ваграк була.
- «Лодочка» кисемле күлмәккә озын чылбыр килешә (күлмәкнең аркасы ачык булган очракта). Күлмәкнең арткы ягы ябык булса, зур булмаган кулонлы нечкә кыска чылбыр матур. Күлмәк өстеннән жакет кияргә кирәк булса, ташлар белән бизәлгән озын муенса да әйбәт. Ташның төсе киемдәге берәр элемент белән ярашырга тиеш.
- Шакмаклы уемга дөрес геометрик формалы муенса килешә. Мәсәлән: түгәрәк, турыпочмаклы, шакмаклы колье. Муенсаның озынлыгы уемга ук төшеп җитәрлек булмасын.
- Киемнең яка уемы асимметрияле булса, ниндидер катлаулы формада тегелсә, муенса тагарга кирәкми. Бу очракта зур алкалар тагу отышлырак.
- Аксессуарларны сайлаганда киемнең нинди тукымадан тегелгән булуын да истә тотарга кирәк. Калын тукымадан тегелгән киемнәргә эре муенсалар туры килә, җәйге нәфис күлмәкләр белән кию өчен вак сәйләннәрдән тезелгән муенса, нечкә чылбыр матур.
- Бәйләнгән киемнәрне эре ташлы калын чылбыр, агач муенса бизәп җибәрә. Водолазкалар белән күләмле, озын муенса матур була.

PRESSA



Үзебез дә ашамый тора алмаган кебек, бакчабыздагы үсемлекләр дә тукландырып торуны сорый. Үсү чорында алар бер төрле ашламага мохтаҗ булса, өлгерү чорында икенче төрлесе кирәк. Үсемлекләр өчен аеруча кирәкле элементлар өчәү: азот, фосфор, калий.

ҮСЕМЛЕКЛӘР ТЕЛЕН ӨЙРӘНӘБЕЗ

Фосфор

Тамыр системасы көчле һәм нык булсын өчен, үсемлекләргә фосфор кирәк.

Фосфор җитешмәсә, үсемлекләрнең үсеше акрыная, яфраклары бертөрле зәңгәр-яшькелт төскә керә, аскы яфракларда бакыр төсендәге яки шәмәхә-кара таплар барлыкка килә, яфрак сабаклары кызара.

Һәрнәрсәнең чамасы булган кебек, фосфорның да артыгы кирәкми. Әгәр дә туфракта бу элемент кирәгеннән артып китсә, яңа барлыкка килгән яфраклар нечкәрә, аларның эчке тармаклары күренеп тора башлый, очлары көя.

Фосфорлы ашламалар: суперфосфат, фосфор оны. Бу ашламаларны үсемлекләр чәчәк атарга керешкән чорда кертергә кирәк.

Азот

Туфрак азотка ярлы булса, күзәнәкләрдә аксым молекулалары барлыкка килә алмый, фотосинтез процессы сүлпәнәя.

Әгәр дә үсемлекләр акрын үссә, аскы яфраклары корыса, калган яфраклары ачык яшел төскә кереп, вагайса, үсемлек вакытыннан алда чәчәк ата башласа, димәк, аңа азот җитми.

Азотлы ашламалар: аммиак селитрасы, мочевина һәм карбамид, аммоний сульфаты, тирес яки тирес сыекчасы.

Бу ашламаларны язын һәм җәй башында – үсемлекләр буйга үскән вакытта кертергә кирәк. Артык күп азот шулай ук файдалы түгел, ул җимешләрнең өлгерүен тоткарлый, өстәвенә, үсемлекнең күзәнәгендә тупланып, организмга зыян да салырга мөмкин.

Азотны иң күп кулланучылар: бәрәңге, кәбестә, помидор, кыяр, суган, чөгендер, алмагач, карлыган, бакча җиләге.

Калий

Калий үсемлекләрдә аксым алмашы өчен кирәк. Калий җитмәсә, алар углекислоталы газны үзләштерә алмый, үсемлекләр төрле чирләргә бик тиз бирешә.

Чәчәк атучы үсемлекләр калийга аеруча мохтаҗ.

Калий җитешмәсә, үсемлекләр чәчәк атмый, яңа чыккан яфраклар вагая, караңгы яшел төскә керә, очлары һәм читләре корый, бик актив төстә ян тармаклар үсә башлый. Сабаклар нечкәрә, тиз сынучанга әйләнә. Калий җитешмәгәндә күзәнәкләрдә аммиак туплана, бу исә үсемлекнең төрле гөмбә чирләренә каршы иммунитетын киметә.

Киресенчә, туфрак калийга кирәгеннән артык бай булса, яңа яфраклар вагая, яфрак җепселләре беленеп тора, очлары кызарып чыга, аскы яфраклар җыерчыклана, аларда көрән таплар барлыкка килә. Калий артык булганда, тамыр очлары да корый.

Калийлы ашламалар: хлорлы калий (моны туфракка фәкать көз көне генә кертергә ярый), күкертле калий, калий селитрасы, калийлы магнезия, агач көле.

Калий көнбагыш, бәрәңге, тамыразык культураларга бигрәк тә кирәк.

Ашламаларны туфракка аерым-аерым түгел, бергә дә кертергә була. Андый ашламалар катлаулы ашлама дип атала. Иң популярлары: аммофос (составында азот һәм фосфор), азофоска (азот, фосфор һәм калийлы).


Кучкар. Шактый катлаулы, мәшәкатьле, вакыйгаларга бай ай булырга охшаган. Эшегезнең нәтиҗәсен озак көтәргә туры килер. Алай да ай ахырына таба хәл бераз үзгәреп, сезгә дә иркен суларга мөмкинлек туар.


Үгезбозау. Перспективалы һәм уңышлы ай. Кызыклы вакыйгалар да көтелә. Иң зур уңышларыгыз эшегез белән бәйле. Бу айда башланган дуслык нык булыр, озакка барыр.


Игезәкләр. Бик көчле энергия агымын тоярсыз. Тормышыгызга ниндидер кызыклы яңалык һәм җиңеллек килеп керер. Күптәнге хыялларыгызны чын итәр өчен уңайлы форсат чыгар.


Кысла. Тормышыгызның хисләргә бай, романтик чорына керәсез. Ниндидер яңа хоббиегыз барлыкка килеп, киләчәктә яхшы гына табыш китерә башларга мөмкин. Иҗади сәләтегез ачылуы ихтимал.


Арыслан. Ял кирәк, дигәнгә көлеп кенә карамагыз. Ял тәнгә генә түгел, җанга да мөһим. Моңарчы чишелеше юк кебек тоелган катлаулы мәсьәләләрне планеталарның уңай йогынтысы тәэсирендә җиңел генә хәл итеп куя алырсыз.


Сөмбелә. Үзегездә моңарчы булмаган көч тоярсыз. Гомерегезнең бу чорын файдалы эшләргә сарыф итәргә тырышыгыз, кирәкмәгәнгә көчегезне әрәм итмәгез. Планнарга берникадәр үзгәрешләр кертергә туры килүе бар.


Бизмән. Айның беренче яртысы идеяләрне тормышка ашыру өчен шәп вакыт. Бу чорда планеталар тормышның бар өлкәсенә дә уңай йогынты ясарлык итеп урнашкан. Шәхси тормышта да, эштә дә, акча ягыннан да проблемалар булмас.


Чаян. Үзегезгә – ышаныч, шәхесегезгә куйган бәягез артыр. Ай башы ниндидер вакыйга белән истә калыр. Игътибар үзегендә булырсыз. Каядыр чакыру алырсыз: бу эшлекле сәфәр дә, күптән күрешмәгән туганыгызга кунакка бару да булырга мөмкин.


Укчы. Тормышыгыз аттракционны хәтерләтә. Үргә менүләр дә, түбән төшүләр дә булыр. Көтелмәгән вакыйгалар, очрашулар, гел бертөсле генә аккан тормышыгызда үзгәрешләр – бу айда барысы да булыр.


Кәҗәмөгез. Быелның иң нәтиҗәле ае дисәң дә була. Эштә дә, шәхси тормышта да көтелмәгән уңыш елмаер. Коллективта хөрмәт казанырсыз. Моңарчы күрелмәгән потенциалыгыз ачылыр.


Сукояр. Яңа мөмкинлекләр һәм шәхси үсеш ае. Айның беренче яртысы очрашулар, эшлекле сәфәрләр белән узар. Күңелегезне күтәрә торган күңелле вакыйгалар көтелә. Уңышка тизрәк ирешәм дип, вакыйгаларны ашыктырмагыз.


Балык. Ай башында берникадәр киеренкелек күзәтелер. Тынычлык яратучы «балык»лар ыгы-зыгыны авыррак кичерә. Четерекле мәсьәләне хәл иткәндә эчке тавышыгызны тыңлагыз, ул ялгышмас.

ИЮНЬ дә кабынган йолдызлар

Татарстан



Гөлсем Исәнгулова (10.06.1938) – **Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты.**

Башкортстанның Мәләвез районы, Дәүләткол авылында туа. 7 яшьлек ятим кызны (әтисе сугышта хәбәрсез югала, әнисе нахакка утыртылган 17 яшьлек кызын коткарырга киткән җиреннән эзсез гаип була) әнисенең абыйсы Сынтимер үзенә ала. Соңрак Уфадагы балалар йортына элгә. Уфаның опера-балет театры алар яшәгән бинага якын гына. Җае чыкса, шунда йөгерә булачак актриса. Артист Рәфкать Фәйзи Мәскәүдә театр училищесына татар яшьләре җыюларын әйтмәсә, мөгаен, Гөлсем Исәнгулова дигән актрисаны белмәс тә идек. Аны тамашачыга А. Муисның «Кануннан тыш» спектаклендә Корри роле таныта. «Ташкыннар»да – Зәмзәмбану (Т. Гыйззәт), «Миркәй белән Айсылу»да – Айсылу (Н. Исәнбәт), «Ай тотылган төндә» – Шәфәкъ, «Кол Гали»дә – Энҗебикә (Н. Фәттах)... бу ул башкарган рольләрнең бары берничәсе генә.

Россия



Ольга Прокофьева (20.06.1963) – **Россиянең атказанган артисты.**

Одинцово шәһәрендә туа. Мәктәпне тәмамлаган елны театр институтына укырга керә алмый – баллары җитми. Бер ел телевидениедә бухгалтер булып эшли, аннан теләгенә ирешә – ГИТИСка укырга керә, Андрей Гончаров һәм Марк Захаровлар курсында укый. Институтны тәмамлаган елны Гончаров аны Маяковский театрына, ә Захаров «Ленком»га чакыра. Ул «Маяковский»ны сайлый һәм бүгенгәчә шушы театрда эшли.

Беренче зур ролен 1991 елда «Униженные и оскорбленные» фильмында уйный. 2004 елдан «Моя прекрасная няня» сериалында – Жанна Аркадьевна ролендә. «Россия-1» каналында «Субботний вечер» тапшыруын әзерли.

Чит илләр



Кэти Бэйтс (28.06.1948) – **актриса, режиссер, «Оскар», «Эмми», ике «Алтын глобус» премияләре лауреаты.**

АКШта Мемфис шәһәрендә туа. Мәктәпне тәмамлап, Даллас шәһәрендә «Көньяк методик университет»та белем ала. 1970 елны Нью-Йоркка күченә. Тагын бер елдан аны «Отрыв» фильмында уйнарга чакыралар. 1973 елдан театрда эшли. Танылу аңа 1990 елда Роб Райнерның «Мизери» фильмында Энни Уилкс ролен башкарганнан соң гына килә. Бу роле өчен ул «Оскар» һәм «Алтын глобус» премияләренә лаек була. Шул ук елны аны «Жареные зеленые помидоры» фильмында уйнарга чакыралар. Актриса әле дә эш белән мәшгуль, узган ел «Вражда» сериалында катнаша.

Фото: https://kamalteatr.ru
https://www.vokrug.tv/

PRESSA





ШАМОТНЫҢ БӘЛЛҮР ЧЫҢЫ

Керамика, балчыктан төрле әйберләр ясау шәрык сәнгатендә төп урынны алып тора. Күп гасырлар элек үк инде мәчет манаралары осталарның кулдан ясалган керамик плиткалары белән бизәлгән, алар чыннан да тирә-якка якты нур чәчеп торган.

Балчыктан төрле әйберләр ясау ирләр эше саналган. Сәнгать әсәрләре генә иҗат итеп калмыйча, киң таралган балчык савытларны да ирләр ясаган. Изгеләрдән-изге бу эшкә хатын-кызларны якын да җибәрмәгәннәр.

Нәзирә Кузиева – керамикадан югары сәнгать әсәрләре ясауның чын остасы. Сәнгать юнәлешендә югары белем алгач, Нәзирә рәсем сәнгате буенча китми, аны ниндидер башка юнәлеш – сәнгатьнең тоеп, кулга тотып була торган үзгә һәм катлаулы төре үзенә җәлеп итә. Студент чагында ук ул керамика белән мавыга башлый. «Йомшак, ничек теләсәң, шулай әвәләнә торган балчык җылысы минем җанда музыка тудыра. Керамист эшендә иң кызыгы – формасыз балчык массасын кулга алуга, останың тырышлыгы, җылы энергетикасы, бай хыялы аны сәнгать әсәре дәрәҗәсендәге матур әйбергә әйләндерә. Аңа сезнең мәхәббәт тә көчә. Бу үзе могҗиза түгелмени?» – ди ул.

Нәзирә ханымның фатиры – үзенә бер сәнгать салоны. Шунда ук остаханә урнашкан. Диварлары – балалары ясаган рәсемнәр, профессиональ рәссамнар картиналары белән бизәлгән. Балчыктан ясалган искиткеч эшләнмәләр таң калдыра, мондый гаҗәеп матурлыкны минем әле моңарчы беркайда күргәнем юк иде. Әтиәнисенең фотолары... Нәзирәнең әнисе Рауза Нигъмәт кызы Хәлимова 1924 елда Бохарада туган, ул – танылган татар зыялылары нәселеннән.

Нәзирә Кузиева – харизмалы, мөлаем, үзенә һәм әйләнә-тирәдәгеләренә карата бик таләпчән иҗатчы. Үз стиле, үз йөзе бар. Аның эшләре – исеме билгеле музейлар һәм картиналар галереялары җыелмалары арасында.

Һәрнәрсәдән гүзәллек эзләүче, кабатланмас керамик формалар тудыручы үзенчәлекле рәссамның иҗаты да ярату, якты уйлар белән өртелгән. Үзенә бер җиңеллек, гаҗәеп сыгылмалылык, образлылык, детальләрнең нәфислеге күзгә ташлана. Шул ук вакытта ул иҗатны көнкүреш бөтенлеге, оригинальлек, экспрессивлык, эзләнүләр һәм экспериментлар дип тә карап була.

Бохарада туып-үссә дә, милләте татар аның. Кеше үзе туган җиргә тамырлары белән бәйләнгән була. Шуңа күрә эшләрендә Үзбәкстан һәм Татарстан мотивлары еш чагыла.

– Мин шамотны яратып кулланам. Утка чыдам бу төр балчык борынгы заманнарда ук су, ярма саклый торган савытлар ясау өчен файдаланылган.

Үзбәкстанда узган Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәрендә Президент Рөстәм Миңнеханов та Нәзирә Кузиева эшләре белән кызыксынды. Шамоттан эшләнгән Сөембикә аеруча игътибарын җәлеп итте.

Омар Хәйям дә балчыкның гаҗәеп көче турында шактый язган. Шәрыкта шундый риваять яши. Үлгәннән соң җан чыгып китә, ә гәүдә җиргә тапшырыла. Яхшы кешенең энергиясе дә башкача була икән. Ул җир астында тупланып, вакытлар үткәч, балчык аша осталар иҗатына әйләнеп кайта, ди. Балчыктан ясалган бер үк төрле чүлмәкләр менә ни өчен төрлесе төрле авазлар чыгара: берсе зыңлый, икенчесе чыңлый...


Рәмзия КАШАПОВА




















НӘЗИРӘ КУЗИЕВА

Язып һәм телевизор от!









1
Язып
25.06.2018 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә 3 басмасына язып *(акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласың)*

2
Җибәр
язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр *(телефон номерыңны күрсәтергә онытма)*: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3
От
Телевизор, фотоаппарат һ.б. бүләкләр!

Акцияне үткәрү вакыты: 16.05.2018–20.09.2018

Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында
Оештыручысы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте
Белешмәләр өчен телефон: (843) 222-09-84 өстәмә номер – 1261

16+
Реклама